ISSN 2618-9623

Туган җир

Родной край

Төбәк тарихы буенча журнал

Краеведческий журнал

4*2018

ТУГАН ТУФРАККА
БАСКАН ЭЗ
СУЫНМЫЙ
ISSN 2618-9623
Туган җир
Родной край
Төбәк тарихы буенча журнал
Краеведческий журнал
1*2018
Туган җир
Родной край
Төбәк тарихы буенча журнал
Краеведческий журнал
2*2018
ISSN 2618-9623
Туган җир
Родной край
Төбәк тарихы буенча журнал
Краеведческий журнал
3*2018

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте

ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

4*2018

Казан – 2018

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

4*2018

Казань – 2018

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

Баш мөхәррир:
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

Главный редактор:
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

Баш мөхәррир урынбасары:
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

Заместитель главного редактора:
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

Редакцион коллегия:
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гыйләҗев Искәндәр
Габдрафиков Илдар
Закиров Ренат
Измайлов Искәндәр
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зәйтүнә
Шәйдуллин Рафаил

Редколлегия:
Аблязов Камил
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ренат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаил
Тычинских Зайтуна
Шайдуллин Рафаиль

Редакцион-нәшер итү төркеме
Җаваплы сәркәтип:
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
Чыгарылыш өчен җаваплы
Дәүләтшина Гөлнара Фарикъ кызы

Редакционно-издательская группа
Ответственный секретарь:
Сагидуллина Мунира Халимовна
Ответственный за выпуск
Давлетшина Гульнара Фариковна

Басманың адресы:
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: Monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

Адрес издания:
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

Туган җир: Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край:Краеведческий журнал]. №4.Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2018.

Эчтәлек

Ел йомгаклары..10

Киләчәккә юл

Алсу Исмәгыйлева.
Васил Шәйхразиев «Кем соң син, татар булмасаң?!» 12

Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

Д.М. Исхаков.
Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз. Икенче язма: «Идегәй» дастанының серләре. 19

Р.Ф. Гатауллин.
Милли тәңгәллекне торгызуның икътисади нигезләре...........................30

Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр

А.А. Борһанов.
Иске-Казан тарихи-мәдәни һәм табигый комплексы һәйкәлләре. Урмат авыл җирлеге һәм Камай шәһәрлеге объектларын өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләре (дәвамы). 39

И.Е. Алексеев.
«Койрык очындагысы...»...55

Н.Г. Гариф.
Төрки-татар исемнәре һәм атамаларының килеп чыгышы турында. 74

О.В. Степанов, А.И. Бугарчев.
«Шонгат» топонимлы тәңкәләр...83

О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова.
Новосибирск өлкәсе татар авыллары (дәвамы). 86

Ф.З. Яхин.
Коръән сүзенең Идел буена беренче китерелүе. 92

Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы

Р.С. Сәетов.
Бүләр (Бараж) шәҗәрәсе. 99

Р.И. Фәтхиев.
Тәтешле тамырлары гасырлар катламында. 117

Г.Ф. Шәйхи.
Касыймовлар авылы. 122

Р.Х. Әмирханов.
Җиде буынны барлаганданиләр белеп була. 126

У.Х. Бурнашев.
Бурнашевлар нәселе..131

Ф.Ә. Бәйрәмова.
Чыңгыз Айтматовның татар тамырлары. 137

Р.З. Салиев.
Ләйлә Әхмәтова(Әхмәрова) әти-әнисенең билгесез тормыш битләре турында. 145

Д.Н. Таҗи.
Кыям Җәгъфәров: автобиографик истәлекләр (дәвамы)......................154

Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы

Ф.З. Яхин.
«Мәликә китабы» тарихы (дәвамы). 169

Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

Вакыйгалар хроникасы..182

Сәет Вахидиның туган якларында. 186

Яңа Чишмә җирлегендә очрашулар...191

Татарстан галимнәре Урал артында. 195

Красноярск шәһәреннән хат. 198

Стратегларга бирем...206

Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

Яңа китап: Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы. «Гөләйза». 209

Тәтешлем – оҗмахым. 211

Шәхесләребез

Р.Р. Минһаҗев.
Себер су астына китмәсен дисәк. 215

Татар рухы

Р.В. Айсин.
Дуслык һәм фикерләр тантанасы йөзеннән..221

Ф.М. Нәбиуллин.
Халыклар гаиләсе – зур гаиләне саклап калу нигезләре. 222

К.А. Тангалычев.
Туган тел: белү яки оныту. 232

Ибраһим Мараш.
Идел буенда Матуридилек һәм Мәрҗани. 238

Юбилярлар турында сүз

Себер этнографы Ф.Т. Вәлиевнең тормышы һәм фәнни эшчәнлеге чорлары. 247
Тормышның иң гүзәл мизгеле...252

Хушлашу

Олы укытучы һәм тынгы белмәс төбәк тарихын өйрәнүче. 254

Милли мәзәкләр, анекдотлар

Татар мәзәге. 258
2018 елда журналда басылган язмалар исемлеге...............................259
2019 елга планлаштырылган басмалар 271
Авторлар буенча белешмә...272
Авторлар өчен мәгълүмат 276

Содержание

Итоги года. 10

Путь в будущее

Алсу Исмагилова

Васил Шайхразиев: «Кто же ты, если не татарин?!»..............................12

Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

Д.М. Исхаков.

Наша национальная история, запрятанная в эпических произведениях народа: Вторая публикация. Тайны дастана «Идегәй» (продолжение) ...19

Р.Ф. Гатауллин.

Экономические основы воспроизводства национальной идентичности....30

Научные публикации по краеведению

А.А. Бурханов.

Памятники Иске-Казанского историко-культурного и природного комплекса (продолжение)...39

И.Е. Алексеев.

«Та, которая на конце хвоста...». 55

Н.Г. Гариф.

О происхождении тюрко-татарских имен и названий. 74

О.В. Степанов, А.И. Бугарчев.

О монетах с топонимом «Шонгат»..83

О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова.

Татарские села Новосибирской области (продолжение). 86

Ф.З. Яхин.

Первое упоминание слов Корана в Поволжье...92

Краеведение в научно-популярных публикациях

Р.С. Саетов.

Родословная Буляр (Барадж)...99

Р.И. Фатхиев.

Корни Татышлов в глуби веков..117

Г.Ф. Шайхи.

Село Касимовых. 122

Р.Х. Амирханов.

Что можно узнать при выявлении семи поколений...............................126

У.Х. Бурнашев.
Династия Бурнашевых. 131

Ф.А. Байрамова.
Татарские корни Чингиза Айтматова. 137

Р.З. Салиев.
Лейла Ахметова (Ахмерова) о неизвестных страницах жизни отца и матери. 145

Д.Н. Тажи.
Киям Жагфаров: автобиографические воспоминания (продолжение). 154

Наше историко-краеведческое наследие

Ф.З. Яхин.
История «Книги Малики» (продолжение). 169

Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

Хроника событий 182

На родине Саида Вахиди. 186

Встречи на Новошешминской земле. 191

Ученые Татарстана в Зауралье. 195

Письмо из Красноярска. 198

Задание стратегам. 206

Информация о краеведческих трудах. Рецензии

Новая книга: Байрамова Фаузия Аухадиевна. «Гуляйза» 209

Мой Татышлинский рай. 211

Известные личности

Р.Р. Мингазов.
Чтобы Сибирь не оказалась под водой. 215

Татарский дух

Р.В. Айсин.
В знак дружбы и торжества мысли. 221

Ф.М. Набиуллин.
Основы сохранения большой семьи – семьи народов. 222

К.А. Тангалычев.
Родной язык: знать или забыть. 232

Ибрахим Мараш.
Матуридийство и Марджани в Поволжье. 238

Слово о юбилярах

Вехи жизни и научной деятельности сибирского этнографа Ф. Т. Валеева. 247

Самая прекрасная пора в жизни. 252

Некрологи

Большой педагог и неутомимый краевед. 254

Национальные шутки, анекдоты

Татарская шутка. 258

Список материалов, опубликованных в 2018 году 259

Публикации, запланированные на 2019 год 271

Сведения об авторах 272

Информация для авторов 276

РЕДАКЦИЯДӘН

ОТ РЕДАКЦИИ

ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Мөхтәрәм төбәк тарихын сөючеләр!

Менә безнең журналыбыз чыга башлауга бер ел вакыт үтеп тә китте. Барыбызның да уртак тырышлыгы белән 2018-нче елда басмабызда мең биттән артыграк төрле жанрдагы мәкаләләр һәм тарихи материаллар басылып чыгып, халыкка җиткерелде. Һичшиксез, бу уңыш гомуми тырышлык җимеше.

«Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире буларак әйтә алам – эш дәверендә авторларыбызның уңай якларыннан башка җитешсезлекләре дә ачык күренде. Иң зурысы – профессиональ дәрәҗәнең җитәрлек булмаганлыгы. Кемдер төбәк тарихын ничек тә язып була дип уйлый икән, ул ялгыша, чөнки җирле тарих ул милли тарихыбызның гаять әһәмиятле өлеше, аны үстерү һәм баету чыганагы. Онытмыйк: төбәк тарихы тирән итеп һәм фәнни яктан эшкәртелеп язылса, милли тарихыбыз да бай һәм кызыклы булачак.

Билгеле, редакциядән торган кимчелекләр өстендә дә нык эшләргә кирәк әле. Дөрес, без дә тәҗрибә туплап, алга таба үзебезнең вазыйфаларыбызны яңача үтәрбез дип уйлыйм. Ләкин, сезнең яктан да редакция тарафыннан куелган техник таләпләрне төгәл башкарырга кирәк булачак (игътибар итегез, алар киләсе ел өчен бераз үзгәртелде).

Иллюстрацияләр турында да нык кына уйланырга кирәк, чөнки алар сыйфатлы булырга тиешләр, моны истән чыгармыйк.

Озак кына уйланганнан соң, журналыбызның эчке структурасын да бераз үзгәртергә кирәк дип таптык (мәсьәлән, яңа рубрикалардан «Шәхесләребез» һәм «Татар стратегиясе-2050» дигән бүлекләр кертергә дигән фикерләр әйтелде). Әле бу турыда ел ахырына кадәр булачак Редакцион советта да сүз булыр. Сездән дә рубрикалар буенча тәкъдимнәр көтәбез.

Иң шатлыклысы шул – хәзер басмабызның авторлар коллективы барлыкка килде һәм редакция портфеленә шактый гына яңа мәкаләләр керде, араларында бик тә кызыклы эчтәлеклеләре дә, дискуссион мате-

риаллар да бар. Димәк, алдагы елда журналыбызның сыйфатын күтәрә алачакбыз. Киләчәк елга планлаштырылган, инде редакциягә килеп кергән язмалар исемлеге бу номерда китерелә, аның белән кызыксына аласыз.

Милләт өчен эшләүче басма буларак әле халыкка барып җитәргә тырышырга да кирәк бит. Әйе, журналның һәр номеры БТК сайтына куела бара. Бу – яхшы. Әмма истән чыгармыйк: интернетта күбрәк яшьләр утыра, ә безгә өлкән буынга да барып җитәргә кирәк. Әлегә төрле төбәкләрдә журналыбызга презентацияләр ясау юлы белән бардык. Бу гына җитми – якын арада укытучыларны (беренче чиратта тарих, татар телен өйрәтүчеләрне) җыеп Казанда бер кичә үткәрергә кирәк дип уйлыйбыз, шулай ук БТК бинасында без атна саен эшли торган клуб та оештырырга кирәк булыр. Ул клубта (шартлы исеме – «Ирек мәйданы») татар тарихы буенча лекция – бәхәсләр, китап күзәтүләр булыр дип көтелә. БТК җитәкчелеге инде бу фикерне хуплады, эш үзебездән тора. Беренче шундый очрашу агымдагы елның декабрь аена планлаштырыла һәм сүз тарих белән милли аң арасындагы бәйлелек турында булачак (сөйләшү камерага төшерелеп, БТК сайтына да куелыр).

Күрәсез, дуслар, эш планнары зур һәм кызыклы. Шулай да, көндәлек мәсьәләләр турында сөйләшкәндә безгә каршыбызда торган киләсе елның төп ике проблемасын онытмаска иде: 2019-нчы ел – Татарстан җөмһүриятенең йөз еллыгын үткәрүгә хәзерлекнең иң әһәмиятле чоры; икенче бурыч – «Татар халкын үстерү стратегиясеен» башкарып чыгуда актив катнашу. Ышанабыз – безнең авторларыбыз бу юнәлешләрне күз алдында тотып та язмалар хәзерләп җибәрерләр дип.

Нәрсә генә булса да, онытмыйк: Татардан киез басып булмый, чөнки халкыбыз кылдан яратылган.

Аллаһның ярдәме ташламасын барыгызны да. Яңа еллар белән!

Дамир Исхаков, мөхәррир.

ВАСИЛ ШӘЙХРАЗИЕВ: «КЕМ СОҢ СИН, ТАТАР БУЛМАСАҢ?!»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2018 елгы юлламасында Бөтендөнья татар конгрессы алдында бурычлар билгеләде. Аерым алганда, татар халкының үсеш стратегиясен кабул итү максаты куелды. Бу стратегиянең нәрсәдән гыйбарәт булачагы һәм ничек тормышка ашыралачагы турында Татарстан премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев белән сөйләштек.

– Васил Гаязович, Президент үзенең еллык юлламасында татар халкының үсеш стратегиясен кабул итү бурычын куйды. Без беләбез: сез Милли Шура рәисе булып билгеләгәннән бирле стратегияне булдыру һәм аны тормышка ашыру юнәлешендә эш алып барасыз. Һәм бер ел элек без, сезнең белән әңгәмә вакытында, бу мәсьәлә буенча да сөйләшкән идек. Бу юнәлештә хәзер эш ничек бара? Татар халкының үсеш стратегиясен билгеләү эше ничек оештырылачак?

– Әйе, 2017 елда, Милли Шура рәисе итеп сайлаганнан соң, иң беренче итеп, Башкарма комитет каршында «Безгә стратегия кирәк» дигән бурыч куйган идем. Башта без аны Башкарма комитет эше буенча стратегия дип уйладык. Ә быел инде, Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов үзенең юлламасында, бөтен татар халкының үсеш стратегиясе кирәклеге турында әйтте. Бу эшне ул Бөтендөнья татар конгрессына йөкләде.

Бу документ Президентыбыз куйган бурычларга нигезләнеп төзеләчәк. Шуңа карап, үзебезнең эшне башлап җибәрдек.

«Стратегиядә дөньядагы 10 миллион татарның һәрберсенең мәнфәгатьләрен исәпкә алырга кирәк»

Стратегия Татарстанның 100 еллыгына да төбәлгән булырга тиеш, материалны 1990-нчы еллар башыннан тупларга, аның өчен дөнья буйлап сибелгән татарларның мәнфәгатьләрен дә карарга кирәк. Дөньяда 10 миллионлап татар яши дип уйласак, әлеге документ аларның һәрберсенә барып җитәргә тиеш.

Монда социологик аспект, халыкның фикере, галимнәр эше, шәхесләрнең тәкъдимнәре, Татарстан, Рәсәй, дөнья күләмендәге вәзгыять исәпкә алыначак. Без түгәрәк өстәлләрдә бу хакта сүз алып барабыз инде. Җәмәгатьчелек тә стратегия төзүдә катнашырга теләк белдерә һәм киңәшләр кереп тора. Без бөтен материалны, тәкъдимнәрне, фикерләрне бергә конгресс карамагында туплыйбыз. Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайтында бер бит ачтык, һәм стратегиягә булган бөтен сораулар, тәкъдимнәр, утырышлар, түгәрәк өстәлләрдән язмаларны шунда урнаштырып барабыз. Бу юнәлештә эш башланды инде. Монда барлык тәкъдимнәр дә кабул ителә, теләгән һәркем рәхим итсен.

Без җитәкчеләргә, халкыбызга мөрәҗәгать итәбез: килегез, күрсәтегез, фикерләшегез, тәкъдимнәр җиткерегез. Әйдәгез, стратегияне бергә язый! Без бер команда – зур, ун миллионлык команда булып, бергәләп тормышка ашырыйк бу бик әһәмиятле проектны.

Татар халкының үсеш стратегиясен без өч чорга бүләбез. Беренчесе – кыска вакыт өчен, ягъни 2020-нче елга кадәр булган вакыт. Ул Татарстан-

ның 100 еллыгына кадәргә чор, Универсиада үткәрү булсынмы ул, сабантуйлар, чемпионатлармы, башка чараларымы, шул вакыйганы карап эш итәргә тиешбез. Чараларны үткәргәндә без һәрвакыт Татарстанга, татар халкына йогынтысын, файдасын уйлыйбыз. Күп кенә әйберләрне шушы уңайдан язып калдырырга кирәк. Бу беренче юнәлеш.

Икенчесе – уртача вакытка, 2030 елларга кадәр, хисапланган планнар булырга тиеш. Чөнки 2020–2030 еллар аралыгында – ун ел вакыт бар. Ун ел ул тарих күзлегеннән күп түгел кебек, нибары ике бишьеллык. Ләкин бүгенге интернет, технологияләр заманында ун ел безнең өчен зур бер дәвер. Вакыт агымы хәзер тиз бара – кичә әле хыялланган әйбер бүген иртә белән тормышка ашып та куя.

Һәм өченчесе – озакка, 2050 елга кадәрге күзаллау.

Стратегиянең төп максаты – татар халкын берләштерү. Күпләр, аның шигаре – «Без татарлар!» булырга тиеш, диләр. Син татарча сөйләшә беләсеңме, яза беләсеңме, укый беләсеңме, уйлый, фикер йөртә беләсеңме – син татар. Татарча сөйләшә алмыйсың, ләкин рухың белән татар икән – син барыбер татар!

Монда дини юнәлешләрне дә исәпкә алырга кирәк. Безнең татарлар арасында мөселманнар да, мөселман булмаганнар, атеистлар да бар. Татар халкының үсеш стратегиясе диндәгеләрне дә, диндә булмаганнарны да берләштерергә тиеш. Шуңа күрә без татарны туплауны төрле яклап карарга тиешбез.

Һәм тагын шунысын да әйтергә кирәк – стратегияне Татарстанда яшәүчеләр өчен генә түгел, Рәсәйдә, дөньяның төрле почмакларында яшәүче татарлар өчен дә билгеләргә кирәк. Ләкин төрле җирдә төрле вәзгыять булганлыгын, төрле мөмкинлекләр барын исәпкә алу мөһим. Татарстанда хәл уңай: безнең ике дәүләт теле турында республика законыбыз бар, монда төпләп, ныклап эшләргә генә кирәк. Читтә яшәүче татарлар Казанны тарихи башкалабыз, Татарстанны Ватан дип саный, шуңа күрә бөтен әйбер монда булырга тиеш, диләр. Рәсәй күләмендә төрле субъектларда татарга карата төрле мөнәсәбәт булырга мөмкин, ләкин Рәсәй законы бар һәм ул бер, шуңа таянырга кирәк. Дөнья күләмендә, чит илләрдә дә хәлләр төрлечә, ләкин күп кенә илләрдә татарларны һәрвакыт хуплыйлар.

«Хәзер без стратегиянең каркасын әзерлибез»

Хәзер без, тәкъдимнәр, фикерләр туплап, стратегиянең каркасын әзерлибез.

Әлбәттә, аның төп нигезе – тел. Тел белүдә гаилә үзәктә булырга тиеш. Әгәр дә ана телен гаиләңдә кулланып татарча сөйләшеп, балаңа тел өйрәтсәң, алга таба җиңелрәк була. Бу бит хакыйкать.

Аннан соң– дәүләт эшли башлый, чөнки безгә татар телле балалар бакчалары, мәктәпләр, милли университет кирәк, ана телендә китаплар чыгарып, мультфильмнар төшерү дә булырга тиеш. Телевидениедә, радиода ана телендә төрле тапшырулар булу әһәмиятле, һичшиксез, монда дәүләт катнашы кирәк.

Бу очракта министрлыкларның әһәмиятен дә искәртик. Әйтик, мәдәният министрлыгы бар. Әгәр безнең композиторларыбыз, артистларыбыз, биючеләребез, концертларыбыз, театрларыбыз булмаса, мәдәниятне халыкка ничек җиткерергә соң? Халык мәдәният министрлыгы үткәргән проектларны күзәтеп, мәдәни үрнәкләрне, фольклорны балаларына, оныкларына тапшыра килә. Халыкның андый мөмкинлеге булу гаять әһәмиятле. Халкыбызга милли киемнәрне дә, милли ризыкларны – үзебезнең бәлешләрне, гөбәдияләрне, өчпочмакларны да танытырга кирәк. Спортны да онытырга ярамый: көрәш, ат чабышлары, кул көрәштерү бар – алар бит бездән чыккан спорт төрләре.

Димәк, таяну нокталары барлыкка килә: гаилә, дәүләт һәм җәмгыять.

«Без һавадагы чыпчыкларга пушкадан атабызмы, әллә һәр сум халыкка файда китерәме?»

Әлбәттә, монда финанс мәсьәләсе дә калкып чыга. Күп кенә чараларны үткәрү һәм телне саклап калу өчен дә, алга барыр өчен дә финанс кирәк. Без китаплар да язабыз, кинолар да төшерәбез. Бу финансларны барлап, алар дөрес сарыф ителәме икәнлеген дә аңларга кирәк. Ягъни һавадагы чыпчыкларга пушкалар белән атабызмы яки безнең бюджеттан барган һәр сумыбыз халыкның телен, рухын сакларга һәм нығытырга ярдәм итәме? Әгәр дә инде шушыларны тикшергәннән соң безгә финанслар җитми дигән фикергә киләбез икән, алга таба бу мәсьәләне дә чишү кирәк булачак.

«Бу документны киләсе елга Республика көненә кадәр кабул итү мөһим»

Без бу документны киләсе елга республика көненә кадәр кабул итәргә тиешбез. Аның калынлыгы турында хәзер күп сүзләр йөри: кемдер аны бер генә битле булырга тиеш дип исәпли, кемдер 500 битле булсын ди. Тәкъдим-киңәшләр җыелгач, без оптималь күләмен дә билгеләрбез.

Һәм иң мөһиме – моңарчы минем аны әйткән юк әле, сер итеп кенә әйтәм – аның исеме, атамасы нинди булырга тиешлеге. Исеменә карап җисеме дә билгеләнә бит. Шуңа күрә без халык арасында конкурс та игълан итәрбез әле. Татар халкының йөрәгенә үтеп керә торган кыска гына җөмләле шигарь дә булырга мөмкин аның нигезендә. Халык безгә бу өлкәдә ярдәм итәр, дип уйлыйбыз.

– Без һәрвакытта да ачык. Шуңа яшьләр дә, олылар да, урта буын булсын, хатын-кызлар, егетләр булсын, һәркем дә тәкъдимнәрен җиткерә ала, без көтеп калабыз аларны.

«Пессимист булу безгә ярдәм итмәячәк»

– Васил Гаязович, сез бу вазифага керешкәннән соң, күп вакытыгызны һәр төбәктәге диярлек татарлар белән очрашуга сарыф иттегез, чит илләргә дә чыгып татарлар белән очраштыгыз. Һәм сезнең шәхси фикерегезне беләсе килә. Ярый, бу стратегияне булдырдык та ди. Аны тормышка ашыру өчен татар халкында потенциал бармы соң? Сез ничек уйлыйсыз?

– Потенциал бар. Моның буенча баш ватып, вакытны юкка үткәреп сөйләшеп утырырга да кирәкми. Безнең халык рухи яктан нык, көчле.

ЮНЕСКО мәгълүматларына күз салсак, көннән-көн ничәмә-ничә телнең югалганын белеп була. Әмма пессимист булу безгә ярдәм итмәячәк. Алай ярамый да.

Миңа кайчак сорау бирәләр: «Ә татар теле миңа нәрсә бирә?», – дип. Иң гади җавап – бу синең әниең теле! Әниең сине дөньяга китергән, син нинди мәгънәсез сорау бирәсең?! Бу ана теле, аналарны сайламыйлар бит! Менә шулай тора-бара, әкренләп аңлатырбыз. Аллаһ бирса, минем уйлавымча, бу халкыбызга файдалы бер документ булачак. Аңа тотынып без алга барачакбыз, эшләребезне корачакбыз.

Ә инде татарлар янына сәфәр кылуларга килгәндә, бер сүз өстәр идем. Мин вазифам буенча Татарстанның премьер-министры урынбасары. Бүген Татарстан Рәсәй күләмендә иң алда баручы регионнарның берсе. Безнең Татарстанга, җитәкчеләребезгә бөтен өлкәләрдә дә бик уңай, хөрмәт белән карыйлар. Һәм күп кенә җирләрдә мин иң беренче төбәк җитәкчесе белән очрашам. Үзем белән төбәктәге татар автономиясе җитәкчеләрен алып керәм. Беренчедән, бу татар оешмалары өчен үзенә күрә бер имтихан. Мин карап торам: аларның авторитетлары бармы, алар үзләре торган җирдә хакимият белән ничек эшлиләр, нинди сораулар күтәрәләр, эшләрлекме алар, кабул итәләрме аларны. Эшләми торган җитәкчеләр өчен бу авыр сынау булып чыга. Мин әйтәм: «Ничек инде алай? Сезне белмиләр дә, кабул да итмиләр, тыңламыйлар да. Ә сез биздә йөрисез», – дим. Икенчедән, мин җитәкчеләргә Татарстан белән өлкәләр арасындагы килешүләр турында аңлатам. Шулар аркылы эшләү мөмкинлекләрен барлыйбыз.

«Кемдер аңлап эшли, кемдер милли проектларның әһәмиятен аңлап бетерми»

– Бу стратегия нигезендә нинди дә булса проектлар эшләнәчәк дип аңлыйм. Чөнки ул стратегияне тормышка ашыру өчен проект-

лар кирәк. Бүгенге көндә татар конгрессы күп кенә проектларны инде башкара. Мәсәлән, «Татарча диктант» үтте һәм «Татар кызы» конкурсы үтәчәк. Татарча диктант, белүебезчә, быел аеруча масштаблы узды. Ә инде «Татар кызы» проекты сез Милли Шурага килгәннән соң бөтенләй яңа дәрәҗәгә күтәрелеп, халыкара статус алды, ул Казанның иң зур биналарының берсендә чын бәйрәм рәвешендә узачак, сез бу турыда катгый таләпләр куйдыгыз. Шушы ике проектның үсеше турында да сөйләшәсе килә. Быел сез бу проектларның барышыннан канәгатьме?

– Команда бик матур эшли. Ләкин бу бит дөнья масштабында: кемдер бик актив эшли, кемдер эшләми, кемдер әле эшкә кереп китә алмаган. Мәсәлән, татарча диктант һәрбер өлкәдә, шәһәрдә, автономиядә, безнең төп милли үзәкләрдә үтәргә тиеш иде. Кайберәүләр исә: «Безгә ул кызык түгел», – ди. Кайберәүләр бу проектның әһәмиятен йөрәкләре аша үткәрмәгәннәр. Ә кемдер инде беренче көннән үк йөгереп эшли. Татарча диктант татар халкы өчен кирәк! Без бу эшне бурычы итеп күрәбез. Былтыр татарча диктанттан соң мин һәрбер автономия җитәкчесенә язып җибәрдем: «Киләсе елга без татарча диктанты икенче форматта үткәрәбез. Сыйфаты ягыннан һәм сан ягыннан ул дәрәҗәле булырга тиеш. Шуңа күрә әзер булып торыгыз, эшләгез, әзерләгез», – дидем.

Татарча диктант елдан-ел зуррак күләмдә үтәргә тиеш. Әгәр дә без ун миллион татар икән, һәркем анда катнашсын. Менә шул вакытта «Мин канәгать», – дип әйтә алачакмын. Башта билгесенә карамабыз, башта санны арттырырга кирәк. Аннары, шул санга җиткәч, сыйфатына да карарбыз. Безгә «икеле» кирәк түгел, «өчле» дәүләт билгесе булса да, безне матурламый. Безгә «дүрт» белән «бишле» кирәк.

«Татар кызы»да безнең өчен бик мөһим проект. Без һәрвакыт ике гыйбарәгә таянабыз. Беренчесе – «Оҗмах әниләрнең аяк астында». Икенчесе – «татар тәрбиясе» дигән төшенчә. Татар кызлары, киленнәре, хатыннары, әниләре һәрвакытта да чиста, пөхтә, гаиләле, мәхәббәтле. Шушы бәйге аша үзебезнең милли тәрбиябезне күрсәтәсебез килә. Татар кызларының тәрбияле, акыллы, чибәр, гүзәл, телне, гореф-гадәтләрне, йолаларны белә һәм һәркемне хөрмәтли, җыр-моңнарын аңлый торган кызлар икәннәрен күрсәтәсе килә.

Быел «Татар кызы» бәйгесенең форматы бераз үзгәрде. Ел саен финалга 12 генә кыз чыга иде, быел 14 кыз булачак. 14 енең дә беренче урын алырга мөмкинлекләре бар. Мин берничә өлкәдә зона бәйгеләрен дә карадым.

Бу бәйгене дөнья күләмендә үткәрә башлаганнан бирле, без инде стратегиябезең бер пунктын үти барабыз. Чөнки үзебезнең татар кызларына

тәрбия бирәбез. Татарча диктант та стратегиянең тагын бер пункты. Бу диктантта кайнашканда син татарча яза, укый, фикерле, аңлый белергә, хата ясамаска тиешсең. Бу – көчле мотивация.

– Бу арада гына тагын нинди проектларга өстенлек бирәчәксез? Нинди проектларның потенциалы хәзер үк бар дип саныйсыз?

– Хәзер массакүләм чаралар белән эшне киңәйтү юнәлешендә эш алып барабыз. Әле күптән түгел генә татарча яза торган чараларның мөхәррирләре белән очрашып, аларга бурычлар куйдык. Ноябрь азакларында бөтен өлкәләрдән татарлар тормышын яктыртучы массакүләм мәгълүмат чараларында эшләүчеләрне җыеп, киңәшмә уздырырга телибез. Кемдер фейсбукта утыра, кемдер инстаграмда, кемдер сайт алып бара, кемнеңдер гәзитләре-журналлары эшли. Без шуларны, бер төркем итеп, конгресс белән бергәләп, эшне зур пирамида рәвешендә төзисебез килә. Безнең иң төп хыялларыбызның берсе – татар кешесе, кайда гына яшәмәсен, иртә белән уянудан башлап иң беренче безнең сайтка кереп, татар дөньясында нәрсә булды икән дип кызыксынсын, укысын иде, дигән теләк.

Алсу Исмәгыйлева
Intertat.tatar (үзгәртелгән вариант)

Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЕРЕНГӘН МИЛЛИ ТАРИХЫБЫЗ

Д.М. Исхаков

Икенче язма: «Идегәй» дастанының серләре

«Идегәй» дастаны бик билгеле, күп төрки халыкларда (алтайлыларда, башкортларда, казахларда, каракалпакларда, нугайларда, төркмәннәрдә, үзбәкләрдә һәм төрле төркем – Себер, Кырым, Идел-Урал буе татарларында) киң таралган эпик әсәр. Аның төрле милли версияләре күләме һәм эчтәлеге ягыннан да бер-берсеннән аерыла. Аларның һәрберсендә үзенә генә хас үзенчәлекләр сакланган, алар артында исә еш кына билгеле тарихи вакыйгалар һәм конкрет җирлек тора, ләкин ул җирлек белән бәйле вакыйгалар агымы теге яки бу дәрәҗәдә төгәллекле һәм аерым тарихи мәсьәләләрне чагылдыру ягыннан бер төрле генә бармаска мөмкин. Нәкъ менә шушы милли үзенчәлекләр аркылы ул дастан эчендә сакланган төбәк тарихына бәйләнгән вакыйгалар һәм сюжетларны барларга мөмкин дә. Билгеле, аннан башка ул эпик әсәрдә гомуми, барлык милли версияләр өчен дә уртак булган яклар да бар. Моның төп сәбәбе – дастанның бөтен вариантларында да үзәктә бер үк шәхеснең – Идегәйнең торуы (хәлбуки, кайбер очракларда, мәсьәлән, башкортларда, эпик әсәрнең төп герое булып Идегәй түгел, ә аның улы Нуретдин-Морадым тора).

Аңлашыладыр, безне беренче чиратта бу дастанның татарлар арасында таралган версияләре кызыксындырачак, чөнки алар Кырым – Идел – Урал –Себер яклары, ягъни, татарлар халык булып формалашкан төбәкләрнең тарихы, белән бәйләнгәннәр. Әмма, ул версияләрдә чагылган кайбер гомуми тарихи информация дә безнең игътибардан читтә калырга тиеш түгел, чөнки алардагы мәгълүматлар урта гасыр татар тарихын тулаем күзаллау өчен бик әһәмиятле, эпоста бит төп вакыйгалар гаять киң яссылыкта яшәгән Алтын Урда эчендә баралар. Дөресрәге,

шушы дәүләтнең таркала башлау дәвере тарихын чагылдыралар. Юкка гына дастанның татар версиясе мондый юллар белән тәмамланмый:

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы

Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аҗдаркан
Башлы-башлы ил булды,

Алтын Урда таралды.

Язмабызга кереш буларак тагы ике мәсьәләгә кыскача гына булса да тукталып китү кирәк.

Беренче мәсьәлә – эпосның төп герое булган Идегәй шәхесе турында. Билгеле булганча, Идегәй – тарихи шәхес һәм аның үлгән елы да билгеле – 1419 ел. Аның туган елы турында төгәл мәгълүмат юк, 1359 ел булса кирәк. Чыганакларда ул беренче мәртәбә 1376-нчы елны искә алына. Моңа кадәр Күк Урда ханы Урус (ул Алтын Урданың сул канаты ханы булган) янында хезмәт иткән Идегәй, нindидер сәбәп аркасында, аның белән конфликтка кереп, Тимур (Аксак-Тимер) белән союзда Алтын Урда тәхете өчен көрәшкән Туктамыш ханга хезмәткә күчә. Кабиләсе буенча ул мангыт (төгәлрәге – ак-мангыт) кабиләсе вәкиле булган [Трепавлов: 2001. С. 62–64] Идегәйнең тарала башлаган Алтын Урда дәүләтенең социаль-политик структурасындагы урынын кайбер тарихи чыганаклар бик төгәл билгелиләр. Мәсьәлән, гарәп елъязмачысы ад-Дзехабиның (1348/1349 елны үлгән) дәвамчысы булган бер билгесез елъязмачы Идегәйнең үлеме турында хәбәрдә, әйтә: «... Сарай һәм Дәште-Кыпчак белән идарә иткән бөек әмир Идики вафат булды....; ул икенче әмир генә иде, чөнки аннан башка Тегинэ исемле тагы бер әмир бар иде. Анда [ягъни, Алтын Урдада – Д. И.] өлкән әмирләр уң канат һәм сул канат әмирләре булалар. Уң канат әмире урынын Тегинэ алып тора. Сул канат әмире урынында Идегәй утыра иде...» [Золотая Орда в источниках: 2003, Т. I. С. 244]. Димәк, Идегәй Алтын Урдада сул канатта булган кабиләләр һәм җирләр белән идарә иткән. Аның сәяси статусы – бәкләр бәге (гарәпчә – әмир – әл-умара, русча – князь князей). Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, аның атасы да (Балтычак/Балынчак бәк) сул канат ханы Тимур-Мәлик б.Уруста шул ук статуста булган [Трепавлов: 2001. С. 83]. Ә бу исә Идегәйнең затлы татарлар нәселеннән булуы турында сөйли. Дастан вариантларында Идегәйнең атасы булып саналган тагын бер шәхес – Котлыкыя

би (аның турында карагыз: [Трепавлов: 2001. С. 64]). Безнең фикер буенча, бу исем Идегәйнең нәсел шәҗәрәсенә хатын-кызлар ягыннан кергән. Аның турында эпоста Туктамыш хан тарафыннан әйтелә:

Һай син татар, һай татар,
Мангыттан азган чал татар, – дип [Идегәй: 1988. 21 б.].

Тулаем алганда, Идегәйнең Чыңгыз хан дәверендә үк билгеле булган мангыт кабиләсенең бәкләре нәселеннән булганлыгы бәхәссез. Дөрес, бу кабиләнең борынгы чорының тарихында әле бүген дә ачылмаган ак таплар кала бирә һәм шуларның берсе – ул кабиләнең чын монгол кабиләсе булуында шөбһә. Чынлап та, әйтелгән кабиләнең исеменең бер варианты – мең (меңнәр) булып, ул исем Җучиның 1207 елны Алтайны Еке Монгол олысына кушып йөргән чорындагы бер төрки кабилә исеменә якын. Сүз Алтайда яшәгән мингат (монда этнонимның тамыры – минг/мең, ә ат/ут – монгол телендә күпчелекне белдерүче формант) кабиләсе турында бара (карагыз: [История и культура татар Западной Сибири: 2015. С.125]).

Икенче мәсьәлә – татарларда табылган «Идегәй» дастанының вариантлары һәм аның җыелма әсәр буларак бастырылып чыгарылган милли версиясе турында. Бүгенге көнгә татарлар арасында табылган шушы дастанның 20-гә якын варианты билгеле [Надиров: 1988. 6 б.]. Аннан башка, ул эпосның Себердә фольклорчы Н.Хәмит язып алган һәм эшкәрткән [Татар эпосы: 2004. 334–337 бб.], соңыннан басылган тексты, Н.Исәнбәт Урал буйларында табып алган һәм шулай ук ул эшкәртеп нәшер иткән [Татар халых дастаны: 1940] версиясе бар, соңгы дәвердә шул ук нигездә басылып чыккан «классик» дип исемләнергә хаклы дастанның тагын бер варианты бар [Идегәй: 1988]. Әмма, барлык бу очракларда да, җыйнама текстны төзегәндә ул эшне башкаручыларның текстка үз якларыннан керткән «өстәмәләр» һәм «төзәтүләр» мәсьәләсе кала. Ул турыда үз вакытында бик йомшак кына итеп Н.Исәнбәт болай дип әйткән: «... сәнгать реставраторлыгы булу ягыннан», бу җыйнама текстны басмага әзерләү эше «бер кадәр иҗади эш итеп каралырга тиеш». Менә шушы «реставратор» үзлегеннән керткән өлешне без әле төп аутентик өлештән аерып алу мөмкинлекләреннән ерак торабыз. Сәбәбе бик гади – халыктан язып алынган төрле версияләр бергә җыйналып басылмаган килеш кала бирә. Бу шартларда безгә басылып чыккан вариантлар белән эш итәргә туры киләчәк. Алдан ук кисәтәбез – югарыда күрсәтелгән сәбәптән ул басылган текстларга бераз саграк карарга кирәк. Дөресен генә әйткәндә, «Идегәй» эпосына барлык мили версияләрен чагыштырып өйрәнгәндә генә – ә мондый фәнни хезмәт дөньяда әлегә юк – төп, аутентик булган эпос эчтәлегенең, ягъни аның инвариант өлешен, чамалап булыр иде.

Ләкин, әйтелгәнчә, төрки халыклар фольклорын өйрәнүче фәннең мондый дәрәҗәгә әле күтәрелгәне юк. Шуңа күрә, безнең түбәндә китерелүче тарихи күзәтүләребез берникадәр чикләнгән дип каралырга тиешләр.

«Идегәй» дастаны күпкырлы эчтәлекле һәм бик четрекле заманны чагылдырган әсәр булганлыктан, бу язмаларыбызда без аның барлык ачылмаган якларын да анализлый алмабыз, андагы кайбер тарихи яктан әһәмиятле сюжетларын тикшереп, барлап чыксак та, безнең бурыч үтәлгән булыр дип уйлыйбыз.

Нәрсә ул, «ал тәхет»?

Тикшерелә торган дастанда берничә урында хан утыра торган «ал тәхет» искә алына.

Әйтик, эпосның сюжет җепләре әле башланган урыннарда ук Алтын Урда ханы булган Туктамыш (1380–1397/98) турында мондый юллар китерелә:

> ...Туктамыш хан килгәндә
> Ал тәхеткә менгәндә,
> Ал тәхетнең аркасы
> Алтын егач тутый кош
> Сайрап телгә килгәндә [Идегәй: 1988. 39 б].

Дастан текстыннан күренгәнчә, бу тәхет «хан сараенда» торган тәхет булган.

Алга таба, шул ук тәхет Аксак Тимер Сарай шәһәрен алуны тасвирлаганда күренә. Төгәлрәге, сүз шушы яулап алучы Сарайда булганда аның янына Идегәйнең Болгардан килүе турында сөйләнгән эпизодта әйтелгән тәхетне искә алу турында бара. Идегәй Аксак-Тимерне сорагач, аның якыннарының берсе Идегәйгә әйтә:

> Шаһ Тимерне сорасаң,
> Шаһ Тимердәй олы хан
> Алтын агач тутый кош
> Ал тәхетне алдырып
> ....
> Сәмәркандка юнәлде, – дип [Идегәй: 1988. 170 б].

Өченче тапкыр шул ук тәхет, инде ул алдарак Сәмәркандка алып кителде дип күрсәтелсә дә, Сарайда, төгәлрәге, хан сараенда, тагы пәйда була. Бу очракта Идегәйнең улы Нуретдин (Норадын/Ир Норадын/Морадым) Сарайга хан булырга теләп килү белән бәйле рәвештә ул тәхет турында әйтелә:

Алтын сарай, хансарай,
Хан сарае ак ишек,
Ир Норадын килгәндә,
Ал тәхеткә менгәндә,
Ал тәхетнең аркасы
Алтын егач тутый кош
Сайрап телгә килгәндә [Идегәй: 1988. 219 б].

Соңгы тапкыр ул тәхет Туктамыш ханның улы Кадыйрбирде (ә бу реаль тарихи шәхес) инде үлгән ханның биләренең берсенә – Киң Җанбайга, сорау бирү эпизодында искә алына:

Туктамышның бие идең,
Бүген кемгә би булдың?
Алтын ташлы тәхетенә
Бүген кем углын мендердең? [Идегәй: 1988. 280 б].

Күренә ки, без тикшерә торган дастанда Алтын Урда ханнарының сарайларында (хан сарае, алтын сарай) торган аерым бер тәхет искә алына. Аның эпоста ике төрле билгеләмәсе бар: «ал тәхет» һәм «алтын ташлы тәхет». Мәгънәви яктан бу ике төшенчә чынлыкта бер-берсенә якын, чөнки татар телендә «ал» сүзе төсне генә түгел (игътибар, рус телендәге «алый» сүзе дә шуннан), ә «әйбәт, яхшы, матур, гүзәл» дигәнне дә аңлата (карагыз: «Безнең эшләр ал да гөл»). Шуның өстенә, үз чиратында «алтын» төшенчәсенең туры мәгънәсеннән тыш башка бер мәгънәсе дә бар – ул «яхшы, матур/гүзәл, кыйммәтле»не аңлата ала (мәсьәлән: «алтын бала», «алтын кеше», «алтын куллы» һ.б.). «Идегәй» дастанында «алтын ташлы тәхет» төшенчәсенең дә шундыйрак мәгънәсе бар дип уйлыйбыз. Шуңа күрә дә, дастандагы «ал тәхетне» без «алтын тәхет» белән бер ук корылма дип карый алабыз. Аның шулай икәнлеге бу тәхетнең «Алтын сарай» (хансарай) эчендә торуыннан да килеп чыга. Безнең фикеребезчә, «ал тәхет» ул «алтын тәхет» төшенчәсенең кыскартылган варианты гына. Бу фикерне башкача нигезләргә дә була: әсәрдә күрсәтелгән тәхет «кызыл» (ал) алтын белән капланган булса (русча – «червоное золото»), бу бигрәк тә шулай.

Бу рәвешчә фикер йөртсәң, безнең каршыда Алтын Урдада власть символы булган «алтын(ал) тәхет» пәйда була. Димәк, сүз «Түләк һәм Сусылу» дастаныннан күренгән шул ук тәхет урыны турында бара «Идегәй» дастанында. Әмма, соңгы эпоста аның бик кызыклы яңа бер элементы килеп чыга – ул да булса шушы тәхетнең арка ягында кошларча тавыш чыгара ала торган «алтын тутый кош» булуы. Икенчедән, дастанда ул «ал тәхетнең» Сәмәркандка алып кителүе турында әйтелсә дә, аның элекке урынында ка-

луы күренә. Димәк, бу «алтын тәхет» элекке урынына – Сарай шәһәренә, «беркетелгән» булган. Аның шулай «беркетелгән» булуы чынлыкта шушы «тәхет урынының» Чыңгызыйлар династиясенә бәйле булуы аркылы гына аңлатыла ала. Чынлап та, тарихи чыганакларда Сарай шәһәренә, ягъни, Алтын Урданың сәяси үзәгенә, бәйле рәвештә искә алына торган, русча «Саинов стул» (монда «Саин» – Бату хан дигәнне аңлата) дип йөртелгән тәхет урыны билгеле. Ул югарыдагы «ал/алтын тәхет» була түгелме?! Ә инде Туктамыш ханның улы Кадыйрбирде, би/бәк булган Киң Җанбайдан (аның кабиләсе – кенегес) син ул тәхеткә кемне мендердең соң дип сораганда, инде без алдагы язмада тикшергән карачы – бәкләрнең ханнарны шушы тәхеткә күтәрүләре турында әйтелә. Чынлап та, XIV–XV йөзләрнең чикләрендә Алтын Урдада солдат булып хезмәт иткән баварияле И. Шильтбергер күрсәткәнчә, «Алтын Татариядә» ханны тәхеткә утырту йоласы мондый булган: «... корольне (ханны – Д. И.) ... ак киезгә утыртып өч мәртәбә күтәргәннәр. Аннан соң аны палатка тирәли [күтәреп] йөртәләр һәм тәхеткә утырталар, алтын кылыч бирәләр. Шуннан соң ул аларның гадәтләре буенча ант итә» [Шильтбергер: 1984. С.44].

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк: «Идегәй» дастанын укыганда без «ал тәхет» төшенчәсен күргәч сүзнең Алтын Урдадагы власть үзәге турында барганлыгын аңларга тиешбез. Димәк, әле дастан формалашкан дәвердә төрки-татарлар арасында бу тарихи символның элекке мәгънәсен аңлау булган.

«Дәүләт кошы» нәрсә ул?

Бу бүлекнең башына куелган дастандагы «дәүләт кошы» дигән юллар артында нәрсә торганлыгын төшенү өчен безгә «Идегәй» эпосының төп сюжетын искә төшерергә кирәк булыр.

Дастанның башланып китүе Шаһ Тимердән, ягъни, Аксак-Тимердән (эпос аны бик төгәл рәвештә «бырлас [кабиләсенең] әмире» дип билгели), Туктамыш ханга килгән хат белән бәйләнә. Ул хатта Аксак-Тимер авызыннан чыккан мондый юллар булганлыгы әйтелә:

Җаектан ашу Ак Түбә,
Иделдән ашу Күк Түбә,
Күк Түбәдә ак сарай;
Анда утырган Туктамыш –
Ул Туктамыш син булсаң,
Сине баккан мин булсам,
Тугрына кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Аны миңа тапшыргыл [Идегәй: 1988. 12 б.].

Дастанга комментарийлар бирүчеләр фикере буенча, «тугры» – кош кундыра торган агач (башка вариантлары – «тур/тургач») [Идегәй: 1988. 12 б.], шуңа күрә «Төкле Аяк» дип исемләнгән җан иясе – ул кош. Менә шул даны бик еракларга таралган кошны таләп итә Аксак-Тимер Туктамыш ханнан. Мондый дорфа хатка җавап биргәндә ачуы чыккан Туктамыш, үзенең Чыңгыз хан нәселеннән булуын, ә Шаһ Тимернең әмир генә икәнлеген искә төшереп, хатта әйтә [Идегәй: 1988. 13 б.]:

Кара лачын Төкле Аяк,

Сиңа булмас, Шаһ Тимер, – дип.

Димәк, дастанда сүз Кара лачын турында бара һәм ул алга таба ау кошлары белән бәйләп карала, ә ул кошларны караучы буларак Котлыкыя би (Идегәйнең дастандагы атасы) атала. Шуннан соң бу Кара лачыннан (= Төкле Аяктан) туган ике кош баласын Туктамыш сынап карарга уйлый һәм шул вакытта аларның даны таралган ау кошыннан тумаган икәнлеген аңлап, Котлыкыяга әйтә [Идегәй: 1988. 17 б.]:

Ау лачыным караган
Котлыкыя син булсаң,
Салган ике йомыркасын
Оядан алган да син икән! – дип.

Алай гына да түгел, ул Котлыкыяны шушы лачынның балаларын Аксак-Тимергә бирүдә гаепли, аның алтынга (акчага) сатылып, Шаһ Тимер ягына чыгуы турында әйтә. Хан каршында үзен акларга тырышкан Котлыкыяны әрләгән Туктамыш аңа болай дип белдерә:

Куш канатлы алтын таҗ,
Күз урынында гәүһәр каш,
Чыңгыздан килгән дәүләт кош
Бу башымда түгелме? [Идегәй: 1988. 18 б.].

Шулай итеп, Кара лачын токымыннан булган «Төкле Аяк» исемле реаль ау кошы урынына дастанда кинәттән генә ике канатлы (куш канатлы) алтын таҗ пәйда булып (тасвирлауга караганда, аның хәтта гәүһәрдән эшләнгән күзе- кашы да булганлыгы белдерелә), аңа гаять әһәмиятле мәгънә бирелә – хан башындагы шушы таҗ «Чыңгыздан килгән» ниндидер «дәүләт кошы» белән тәңгәлләштерелә.

Без күрсәтелгән кош образын, төгәлрәге – «дәүләт кошы» образын, Чыңгыз ханнан килүче «алтын таҗны» истә калдырыйк та, дастанны алга таба күзәтик, чөнки Туктамыш хан Котлыкыя бидән аның ни өчен сатылганлыгын белергә тели. Җавап итеп ханга Котлыкыя ике гаеп ташлый: бердән, сәүдә элемтәләре кимеп, бигә байлык килмәү, икенчедән, аның

үз илен Идел аркылы ике тапкыр күчереп, уңайсыз җиргә китереп утыртуын. Ахырдан ул әйтә:

Йорттан йортым күчкәне –
Бездән ырыс киткәне,
Куштан кошың күчкәне –
Сездән дәүләт киткәне [Идегәй: 1988. 20–21 бб.].

Ягъни, Котлыкая бинең фикеренчә, аның йортының – биләмәсенең, бер җирдән икенче җиргә күчүе бәхетнең (ырысның) китүенә тәңгәл, а оядан (куштан) кошның күчүе ханнан дәүләтнең китүенә тигез. Котлыкыя би үзенең хыянәтен таный һәм аннан җәза алырга әзер икәнлеген белдерә [Идегәй: 1988. 21 б.]:

Бер башымны ике итеп,
Ике ханга баш орсам,
Ул да булса, ханиям,
Йорттан абруй киткәне,
Чабучы булсаң, баш – менә!
Түгүче булсаң, кан – менә!

Каршында җәза алырга тезләнгән Котлыкыяга хан әйтә [Шунда ук]:

Син дә кичә би булдың,
Бүген килеп, син дә бер
Үлем белән тиң булдың –
Токымыңны ораен!, – дип.

Шушы сүзләрдән соң Туктамыш үз биләренә Котлыкыяны һәм аның бөтен токымын юк итәргә боера. Шулай итеп, дастанның баш өлеше төгәлләнә, алга таба бу өлештә күренгән «Төкле Аяк» исемле кош башка искә алынмый, «дәүләт кошы» кыяфәтле «алтын таҗ» да бүтән дастанда пәйда булмый.

Ләкин бер сорау кала: нинди «дәүләт кошы» турында сүз бара соң дастанда һәм ни өчен Кара лачын нәселеннән булган ау кошы Туктамыш хан өчен әһәмиятле булган?

Куелган сорауга җавап эзләгәндә, безгә эпик дөнья белән эш иткәнебезне онытырга ярамый. Әмма, дастанда искә алынган ике төр кош (ау кошы – Кара лачын һәм «дәүләт кошы» – куш канатлы, кашлы/күзле алтын таҗга «сеңгән» кош кыяфәтле сын) арасында нindидер, әлегә безгә билгеле булмаган, бәйлелек бар кебек. Ул бәйлелекне сүтә башлар өчен безгә яңадан «Түләк белән Сусылу» дастанында искә алынган «алтын тәхет» куелган Балкан тау өстендә очып йөргән «миңезлик кошка» (нәселе – ак шонкар) әйләнеп кайту кирәк. Исегезгә төшерәбез: ул кошның

билгеләмә өлешенең мәгънәсенә «акча, тәңкә» төшенчәсе дә керә, ягъни, «акчага сугылган кош» [сурәте] күз алдында тотыла. Шулай булгач, монда да «дәүләт кошы» килеп чыга түгелме? Безнең уйлавыбызча, андый нәтиҗәгә чынлап та килергә мөмкин, ләкин аңа кадәр бу мәсьәләнең кайбер нюансларын тикшерү кирәк (түбәндә китереләчәк мәгълүматлар буенча махсус рәвештә карагыз: [Исхаков: 2013]).

Иң башлап, «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренә мөрәҗәгать итик. Билгеле булганча, анда Чыңгыз ханның бәкләренең кабилә билгеләреннән (оран, агач, кош, тамга) тыш аның үзенең дә аерым шундый ук атрибутлары китерелә. Менә алар: оран – йан каба (jan qaba), агач – чинар, кош – ике баш кара кош, тамга – кош баш[ы]. Мәсьәләнең кызыклы ягы шунда – үз вакытында Чыңгыз ханның бабалары чыккан кыйат кабиләсенең бу чыганакта китерелгән билгеләре башка төрле: оран – аруйан (aruǰan), агач – карагай, кош – шонкар, тамга – ашамай (ačamay) [Ivanics, Usmanov: 2002. PP. 56, 59]. Мондый аерманы ике төрле аңлатырга мөмкин: 1) Чыңгыз ханның нәселе кыйат кабиләсенең аерым бер тармагыннан – бурджигин исемле ырудан булу сәбәпле – бәлки, бу тармакның билгеләре башка төрле булгандыр; 2) Күрсәтелгән нәсел Бөек Монгол империясендә иң югары дәрәҗәгә күтәрелгәч һәм кабиләләрдән өстен урын алгач, аның токымының билгеләре дә үзгәргән булырга мөмкин. Чыннан да, кайбер фактлар шундыйрак нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, табигатьтә бит ике башлы кошлар юк, димәк бу атрибут – ясалма. Шулай булгач, Чыңгыз хан нәселенең башка билгеләре дә уйлап чыгарылган булырга мөмкин.

Ничек кенә булмасын, «Дәфтәре Чыңгыз-намәдә» бирелгән Чыңгыз ханның кошының атамасы – «кара кош» инде китерелгән «Идегәй» дастанындагы Туктамыш ханның кошының исемен хәтерләтә («кара лачын»). Әмма, мәсьәлә алай гади генә түгел, шуңа күрә орнитология фәненә дә мөрәҗәгать итәргә кирәк аны чишү өчен. Эш шунда ки, татарларда билгеле «каракошны», орнитологлар карчыгалар гаиләсенә кертсәләр дә, ул тагы бер исем йөртә – «кара бөркет» дигән. Ә ул төр кошлар шул ук карчыгалар гаиләсенә карыйлар. Шул ук вакытта лачын – ул башка отрядка-лачыннар отрядына (Falconidae) карый. Димәк, татарларда каракош һәм бөркет – карчыгалар гаиләсенә карый торган кошлар. Шулай булгач, Туктамыш ханның «кара лачыны» Чыңгыз ханның «кара кошы» белән бөтенләй ук тәңгәл килми. Дөрес, «кара» дигән төс билгесе монда уртак.

Шулай да, Чыңгыз хан нәселенең борыңгы кабиләсе билгесе булган «шоңкар» дигән кошның лачыннар гаиләсенә керүен дә истә тотарга кирәк. Бу очракта Туктамыш ханның «кара лачынын» без бөтенләй тикшерүдән төшереп калдыра алмыйбыз. Мондый рәвешле фикер йөртсәк,

алдагы нәтиҗә килеп чыга: төрле исемдәге кошларны барлаганда ике мәдәни традиция күренә – монгол традициясе лачыннар рәтенә керүче шонкар белән эш итсә, төрки традиция бөркетләр һәм карчыгалар рәтенә керүче каракошны алга чыгара. Ахрысы, «Идегәй» дастанында без ике мәдәни традициянең үзара кушылуын күрәбез. Әмма, бу очракта да бер проблема чишелмичә кала: борыңгы монгол традициясендә Чыңгыз хан нәселенең кошы ак төстә (ак шонкар), ә «Дәфтәре Чыңгыз-намәдә» аның кошы кара төсле буларак (Кара кош, каракош) билгеле. Монда ике аңлатма мөмкин: яисә бу шушы төр кошларның ике төрле исеме генә, яисә бу очракта ике төрле этномәдәни (монгол һәм төрки) традиция чагылышы белән очрашабыз. Әгәр дә соңгысы дөрес булса, «Идегәй» дастанында шушы ике традициянең үзара синтезы күзәтелә – «кара лачын» әле лачыннар рәтенә керә, ләкин төсе буенча ул инде «каракошка», ягъни бөркетләр һәм карчыгаларга якыная.

Әйтелгәнгә өстәп тагы бер мәсьәләгә тукталу кирәк – Чыңгыз ханның тамгасына. Инде күрсәтелгәнчә, ул татар тарихи традициясендә «кош баш» дип йөртелгән. Һәм бу юкка гына түгел – әгәр дә Бату хан нәселенең («Бату йортының») акчаларын тикшерсәң, анда кошка охшаган (ике якка караган томшыклары да чамалана аерым очракларда) рәсем бар. Менә алар: , . Ә инде Үзбәк һәм Җанибәк ханнар дәверендә шул ук урында акчаларда ап-ачык рәвештә ике башлы кош сүрәтләнә. Нәкъ менә шул инде ул «ике баш каракош» (русларның гербларындагы «двуглавый орел» да шуннан дип уйлыйбыз). Фәнни әдәбиятта Алтын Урда акчаларында мондый рәсемнәрнең барлыкка килүен төрлечә аңлатсалар да (мәсьәлән, Византия йогынтысы дип), аны шушы дәүләткә нигез салган Чыңгызыйларның борыңгы кабилә символы дип карарга да мөмкин. Ягъни, ике башлы кош – каракош, ак шонкардан, Чыңгызхан кабиләсенең сульдэ/онгонынннан үсеп чыккан булырга мөмкин. Тамгалары да шул кош рәсеме белән бәйле булган булырга тиеш (ләкин онытмыйк – кош һәм тамга – икесе ике җисем). Шушы рәвешле фикер йөрткәндә, «Идегәй» дастанындагы Туктамыш ханның кошы мәсьәләсе бөтенләй башка мәгънә ала.

Беренчедән, «алтын тажга» беркетелгән пар канатлы кош сыны иске монгол традициясе белән килүче Чыңгыз хан нәселенең сульдэ кошы белән бәйле дәүләт символы дәрәҗәсенә күтәрелгән билге булып чыга (акчаларга да сугылгач, ул инде герб урынына йөргән). Ә бу кош – ыру-кабилә, нәселнең рухы, димәк, язмышы (бәхете – ырысы) белән дә бәйле. Дастандагы реаль «кара лачын», ау кошы буларак күрсәтелсә дә, символик тотем кошын чагылдырса кирәк. Димәк, Котлыкыя би ул «дәүләт кошының» балаларын чит җирләргә җибәреп, үзенең хөкемдарына – Тук-

тамыш ханга гына хыянәт итми, ә Алтын Урда дәүләтенә, аның сәяси элитасы булган Чыңгызыйлар нәселенә хыянәт ясый.

Шуңа күрә дә дастандагы ике рәт кошларны без бергә карарга тиешбез, чөнки сүз анда чынлыкта бер үк әйбер турында – әйтелгән дәүләтнең язмышы турында бара һәм монда символик мәгънә белән реаль чынбарлык бер-берсенә тарихи рәвештә бәйләнгәннәр. Димәк, эпостагы кошлар мәсьәләсендә тирән мәгънә бар.

(Дәвамы бар)

Әдәбият

Золотая Орда в источниках. Т.I. Арабские и персидские сочинения. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, в переводах В. Г. Тизенгаузена. Ч. I. Извлечения из сочинений арабских. Ч. II. Извлечения из сочинений персидских. Сост., ввод. ст. и коммент. Р. П. Храпачевского. М., 2003.

Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

Татар халык дастаны «Идегәй». Н. Исәнбәт җыйнамасы. // Совет әдәбияты. 1940. №11. – 39–76 бб; №12. – 34–82 бб.

История и культура татар Западной Сибири. Монография. – Казань: Ин-т истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015.

Исхаков Д. М. В поисках истоков и смысла изображения двуглавых птиц (орлов) на золотоордынских монетах // Нумизматика Золотой Орды. Golden Horde Numismatics. 2013. № 3. С. 120 – 127.

Надиров И. «Идегәй» дастаны» // «Идегәй». Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 5 – 10 бб.

Татар эпосы. Дастаннар. / Төз., кереш сүз һәм искәрм. язучы, сүзлек әзерләүче Ф. Г. Әхмәтова-Урманче. – Казан: «Раннур» нәшр., 2004.

Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. – М.: Изд. фирма «Вост. лит-ры» РАН, 2001.

Шильтбергер И. Путешествие по Европе, Азии и Африке с 1394 года по 1427 год. Пер. с немецкого Ф.К. Бруна. Изд., ред. и прим. академика АН Азерб. ССР З.М. Буниятова. – Баку: Изд-во «Элм», 1984.

Ivanics Maria, Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis – Legende (Däftär-i Čingiz-nāmä). I. (Vorwort, Einfűhrung, Transkription, Wőrterbuch, Faksimiles). Studia Uralo-Altaica 44. Szeged, 2002.

ЭКОНОМИЧЕСКИЕ ОСНОВЫ ВОСПРОИЗВОДСТВА НАЦИОНАЛЬНОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ *

Р.Ф.Гатауллин

На фоне расширяющейся дискуссии о судьбе татарской нации и национальных меньшинств страны особую актуальность приобретает в целом анализ экономических и институциональных основ воспроизводства этносов. Как странно это не звучит, такой анализ в экономической науке до сих пор отсутствует, как и изучение правовой, духовно-нравственной и культурной основы воспроизводства этносов (о последнем аспекте относительно татарской науки в свое время весьма глубокие рассуждения оставил Г.Исхаки).

В последние годы в экономической науке появилось понятие этноэкономики. Что это такое? На этот вопрос сегодня однозначный ответ отсутствует. В.Н.Овчинников и Ю.С.Колесников под этноэкономикой понимают типичный хозяйственный уклад традиционной экономики [Овчинников, Колесниченков: 2006. С.118–123]. Сюда, прежде всего, относятся преимущественно аграрные формы хозяйственной деятельности, кустарные промыслы и надомный труд. Есть подход к определению этноэкономики как формы предпринимательства в традиционных видах трудовой деятельности автохтонного населения региона [Узденова, 2006; Ахметов: 2018.; Ахметов, Якшимбетова: 2018]. В отличие от двух уже названных подходов, когда этноэкономика выводится из специфики сферы приложения труда, существует попытка связать эту категорию со спецификой экономических отношений. М.О.Шандыров [Шандыров: 2003] этноэкономику определяет как сферу формирующихся в процессе производственно-хозяйственного бытия этноса экономических отношений. Есть понятие этноэкономики как системы, закрепляющей устойчивость культуры различных народов [Иншаков: 2008. С.8–20]. В этом случае функция этноэкономики видится в обеспечении эффективности использования человеческого капитала этносов в целях усиления экономического потенциала хозяйственной системы региона.

Төрки кабиләләрнең бер тармагы, Төньяк Алтай биләмәләрендә яшәүче кыпчаклар, тарихи язмаларда безнең эрага чаклы I меңьеллыкта ук искә алына. Соңрак, VIII гасырда, кыпчаклар Кимәк каһанлыгын төзүдә катнаша. IX гасыр уртасында кыпчаклар тарихында зур социаль-экономик һәм сәяси үзгәрешләр килеп чыга. Шул сәбәпле алар X-XI гасырларда Идел елгасының түбән өлеше белән Днепр арасындагы җирләргә күченәләр. Аларга чаклы бу җирләрдә бәҗәнәкләр белән башка төркиләр (төрки тарихи һ.б.) яши. Кыпчаклар басымы астында аларның бер өлеше чигенә, икенче өлеше кыпчаклар берләшмәсенә кушыла. Кыпчаклар яшәгән җирләр фарсы язмаларында «Дәште Кыпчак», урыс елъязмаларында «Половецкая степь» буларак искә алынган.

Менә шушы урында, исемнәр охшашлыгына бәйле, бер тарихи вакыйганы искә алып узабыз.

Чыганакта монгол-татар явы башлыгы Батый искә алына *(*Батый, Җучи хан угылы – Алтын Урда ханы *(1237–?)* [ПСРЛ. Т.XII: 1965. С. 199]). Аларга каршы, урыс кенәзлекләре белән берлектә кыпчак кабиләләре дә чыга. Кыпчакларның башлыгы да Батый исемле *(*Батый – «князь Половецкий» *(1225)* [ПСРЛ. Т.X: 1965. С. 90]).

Кыпчак даласына татар явы килүен ишеткәч, кыпчаклар урыс кенәзләренә килеп, *«татарлар элек тә безнең җирләребезне басып*

алды, берләшеп каршы чыкмасак, сез дә безнең хәлдә калырсыз», – диләр. Кыпчаклар белән урыс кенәзләре берләшүен ишеткәч, татарлар урыс кенәзләренә илче җибәреп, *«без сезгә каршы түгел, үзебезнең колларыбызга каршы килдек, кыпчаклар элеккедән безнең атларыбызны көттеләр»,* – дип, дәгъваләрен җиткерәләр. Урыс кенәзләре татарларның илчеләрен кыйнап җибәрләр. Кыпчаклар белән урыслар Калка елгасы буенда татарлар тарафыннан җиңелүгә дучар булалар. Бу вакыйгалардан соң кыпчаклар Алтын Урда дәүләтенә керә һәм соңрак татар халкының бер компоненты буларак формалаша.

Ельязмада кыпчак кнәзе буларак Башкорт исеме дә чагылыш таба *(*Башкорт – «князь Половецкий» *(1154)* [ПСРЛ. Т.IX: 1945. С. 213]; (1185). [ПСРЛ. Т. XI: 1965. С. 11]). Башкорт атамасы чыгышының төрки кабилә башлыгы исеменә бәйле булуы да мөмкин.

Татар халкының вакыт агышында төрле дәүләтләр төзегәнлеге, тотканлыгы кеше исемнәрендә бик еш чагылыш таба*:* Дәүләтъяр, Исән Дәүләтбәхете, Дәүләтбирде, Төзер Дәүләткилде, Дәүләт-Гәрәй, Дәүләт-Солтан, Дәүләт-Хуҗа, Дәүләт Хаҗи, Ак-дәүләт, Дәүләт-нур, Дәүләт-Чура, Дәүләт, Дәү-ил, Дәү-өй...

Исемнәр төзелешендә иерархик титул һәм дини дәрәҗәләр аталышы зур роль уйный: Хан, Солтан, Карачъ-Карачы, Бай-бәй-бәк, Морза-Мирза, Углан, Чура, Сәет, Шәех, Хаҗи, Хафиз, Мәүлә, Мулла һ.б. Алар кушма тамырлы кеше исемнәрендә беренче һәм икенче компонент буларак та, яисә үзара катнашудан да барлыкка килә: Сәет-бәк, Бай-морза, Морза-хан, Бикчура; Бай – Байбулат, Баймөхәммәд, Байдәүләт, Байсуфый, Байтирәк, Баем, Байбер, Байбичә, Байдар, Байгатаулла, Баймак, Байбәк, Байхуҗа, Байчура Иделбай; Кол – Колгали, Колчура, Колсәет, Колмөхәммәд, Колшәриф, Колсарый, Колдәрвиш, Аккол, Тәңрекол, Колбирде, Җанкол, Ходайкол, Байкол, Кол Булмас; Чура – Акчура, Исәнчура, Җыенчура, Тиңчура, Чуракай, Бичура, Өнсәчура, Шаһчура, Чурагазый, Җанчура, Бикчура, Ябчура, Дәүләтчура; Хуҗа – Ак Хуҗа, Әхмәт Хуҗа, Аманхуҗа, Имамхуҗа, Байхуҗа, Сабыр Хуҗа, Хуҗаҗан, Хуҗашәех, Төбәкхуҗа, Күбәкхуҗа, Дәүләтхуҗа, *Асылхуҗа, Хуҗагали,* Бахты (Бәхетле) Хуҗа һ.б.

Төрки-татар атамаларында «Гәрәй» кушымтасы кергән исемнәр еш очрый. Бу бигрәк тә югары катлам кешеләренә (хан, солтаннарга) нисбәтле чагылыш таба: Мөхәммәдгәрәй, Баһадиргәрәй, Хаҗигәрәй, Үтәмеш Гәрәй һ.б. Әлеге атама сирәк кенә булса да гади кеше исемнәрендә дә чагылыш таба.

Төрки-татарлар арасында ислам дине таралышы исемнәрнең чыгышына тәэсир иткән. Исемнәрдә ислам диненә бәйле ай атамалары

(Рәҗәб, Шәгъбан, Рамазан...), Аллаһыга (Аллаһкүәт, Аллаһкол, Аллаһяр, Аллаһбирде, Аллагашөкер), аның аша Пәйгамбәрләргә (Йосыф, Якуб, Гайсә, Мөхәммәд) буйсыну, сыгыну, аларны зурларга омтылыш урын ала. Ходайбирде, Тәңребирде, Тәңреколы кебек алмаш атамалар ясалышы да дәвам итә.

Язма чыганакларда төрки-татар хатын-кызларының исемнәре сирәгрәк искә алына. Әмма булганнары да аларның гаҗәеп рәвештә әһәмиятле, матур яңгырашлы, мәгънәле булулары белән әсир итә. Хатын-кыз исемнәре: Байбиче – Байбичә – (1554) [ПСРЛ. Т.XX-2: 1914. С. 178]; Горшадна – Гәүһәршад – *«Казанская царевна»* (1531) [ПСРЛ. Т.XX-1: 1910. С. 531]; Алтынчачь – Алтынчәч – (1561) [ПСРЛ. Т.XIII-2: 1965. С. 333]. Чыганакларны күрсәтмичә генә әлеге исемлекне дәвам итәсе килә: Җанәкә, Яртуган, Гөл-Бостан (Хатын), Бикәч, Биби Зәгыйфә, Тәвәкәл, Дәүләт-Солтан, Татлы-би, Гөлбаһар, Күрекле-бикә, Ширин бикә, Сөенбикә, Ак-бикәч, Бахшанда бикәч, Мөхсинә бикә, Малһурух, Мәрүана, Җанаш, Бужуныл, Нази Мөлек хатун, Ай-кыз бикәч, Гөләби Йөз-бикә, Гәүһәр бикә, Көләчхан, Нәүрүз-Солтан, Нурсолтан, Рәҗәб-Солтан, Фатыйма Солтан, Биби (Аднаби) Ай-бикәч, Каракыз, Ханзадә, Толымбикә һәм башка исемнәр.

Тарихи чорларда төрки-татарларның бер өлеше урыслышуга юл тоткан. Бу процесс күп очракта мәҗбүри төс алган. Әлеге шәхесләрнең беренчел исемнәре билгесез булса да, чыганакта искә алынган шәхесләрнең татарлыгын белгертүче ясалма исем, фамилия, кушамат яисә башка төр атамалар аерымлана. Мәсәлән: Новокрещенов, Новосельские, Новосильцов, Новосилец кебек исем-фамилияләр арасына төрки-татар исемнәре яшерелгән. Исемнәрдәге үзгәрешләр күп очракта чукындыру сәясәтенә бәйле барлыкка килгән. Мәсәлән: Петр *(«до крещения Кудайколъ»)* – Ходайкол, *«Татарский царевич»* (1506, 1510) [ПСРЛ. XX-1: 1915. С. 488, 497]; Петр *(«до крещения Ярышты»)* – Ярышты, *«Татарский царевич»* (1506, 1510) [ПСРЛ. XX-1: 1910. С. 488, 497]; Семенъ Бикбулатовичъ *(«до крещения Саин Булатъ»)* – Сөен Булат – Казан ханзадәсе, Касыйм ханы, *«в. кн. Тверской»* [ПСРЛ. Т. XIV.1: 1918. С. 24, 25, 47, 68]; Бахты-Хожа *(«в крещении Анания»)* – Бәхетле Хуҗа – *«постельничий Тохтамыша»* (1391) [ПСРЛ. Т. XI: 1965. С. 125] һ.б.

Татар тарихына ачыклык кертүче тарихи чыганакларның шактые урыс елъязмаларыннан тора. Шул сәбәпле бер иш исемнәрдә, өстәмә вариант буларак, татарча исемнәрнең яңгырашы да сакланган: Мәсәлән: Одой (Адай, Атай, Ходай) – Одоевский; Обух (Абых) – Обухов (фамилия) һ.б.

Чыганакларда яңгыраш тапкан төрки-татар исемнәренең зур өлешен кушаматлар тәшкил итә. Татар исемнәре бер яктан кушамат буларак кыскарып үзгәреш кичерсә, икенче яктан әлеге кушаматлар гарәп һәм урыс теленең яңгыраш үзенчәлекләренә бәйле бозылган. Кайбер очракларда аларның мәгънәсенә тулаем төшенү, ачыклау мөмкинчелеге дә калмый.

Кушаматлар: Мамай (Мәмеш, Мәмәд, Махмед) – Мөхәммәд, Камай – Камалетдин, Колай – Коләхмәт, Малей – Мәли (Малик) Шемай, Шамса – Шәмәй – Шәмси (Шәмсетдин) һ.б.

Бу уңайдан бер мисал. Татарча тулы исеме Баһаветдин, кушамат буларак: Баһау, Багыш, Баһдан буларак аталган. Урысча язылышта: тулы исем Боговитинович (Боговитиновъ), кушамат буларак: Богушъ, Бугушъ, Боуш, Богодан, Богдан дип йөртелгән.

Чыганакларда, кеше исеме буларак, аларга бирелгән кушаматлар да очрый: Кылый Гали, Тупас, Чуан Төмән, Йомык, Алабаш, Елый Бирде, Караҗан, Аксак Тимер, Тәбәнәк, Аңнамас, Артык. Мәсәлән, Мамайның (Олы Урда ханы) икенче исеме буларак язмаларда «Тетякъ» (Титәк, Тинтәк) атамасы күрсәтелә. Моны кушамат буларак та кабул итәргә мөмкин. Бәлки, башка мәгънәсе дә бардыр.

Төрки-татар исем-атамаларын өйрәнгәндә укучының игътибарын урыслашкан татарларның исемнәренә дә юнәлтәбез. Урыслашкан татарларның, бигрәк тә югары катламда торучыларның, исемнәре фамилияләренә күчеп, гасырлар кичкән. Иерархик баскычның түбәнге өлешендә торган, хезмәтче төрки-татарларның исемнәре бер-ике буын арасында юкка чыккан.

Шунысы игътибарга лаек, елъязмаларда искә алынган урыс әсирләренең исемнәре күп очракта үзгәрмәгән, кушамат буларак та сакланган (әйтик, Малай). Чувашлар (бу очракта ясаклы татарлар мәгънәсендә бирелә) әсирлектәге урыслар белән бергә искә алына. Алар халыкның түбән катламы буларак саналган. Шул сәбәпле исемнәре аталышында да азмы-күпме үзенчәлек сизелә.

Безнең тарафтан XIV-XVI гасырның беренче яртысы арасында урыслашкан 500 гә якын (А.Х. Халиков та ул турыда язган иде) татар фамилияле шәхесләр ачыкланды. Татар исем-атамалы шәхесләр урыс кенәзлекләре иерархик баскычының зур өлешен алып торалар [Вернадский: 2004]. Татар исем-фамилияләренең бер өлеше, кыскарып, үзгәреш кичергән: Болгак (Булгак – Булгаковы), Урмат (Урмацкие), Нурма (Нурмөхәммәд) (Нормацкие), Шәрәф (Шарапъ), Исәнгали (Исленьев), Гәрәй (Кирей), Ширәмәт, (Шереметевы), Ширәй, Ширин, (Ширяевы) һ.б.

Тарихи чыганакларда географик атамалар: шәһәр, авыл, кыр-дала, елга, урман, тау-калкулык һ.б.) искә алынган. Бер иш атамаларның уры-

нын ачыклау һәм исемнәрне төгәл билгеләү кыенлыклар да тудыра. Төрки атамаларны урысча язылышында ә-а-е; г-к-х; , җ-е-з; я-җ; җ-з; з-с; аг-г-к; ас-с; о-а-у-ү (мәсәлән: Алабуга-Елабуга, Урда-Орда, Олыс-Улус, Утар-Отар, Елантауы-Зилантова) һ.б. хәрефләр үзара алышып, яисә югалып атамаларның дөрес әйтелеше һәм мәгънәсе югала (Карасу елгасы – Корсунь, Тын елгасы – Дон, Ерык утравы – Ирихов остров, Гильдеево – Җанкилде, Шеланга – Чыршылы елга, Зөя – Свияга, Тәмте – Теньки, Җиде күл – Едигол (Семиозерка)...

Төрки-татар атамалары елъязмаларда урысчага тәрҗемә хәлендә дә бирелә: Хан болыны – Царский луг, Хан капкасы – Царевы (Царския) ворота, Ханавыл – Царицыно, Царёв луг – Хан болыны, Царёво озеро – Хан күле, Царёвы тавруи – Хан кыры, Биектау – Высокая Гора, Кунак (Сәүдә) утравы – Гостиный островъ, Чуртан күле – Щучье озеро, Мунча (Исле, Черек, Кара) күле – Банное (Поганое, Гнилое, Черное) озеро һ.б. Шул сәбәпле без әлеге исем атамаларның борынгы атамасын тәрҗемәи хәлдә кабул итәбез.

Югарыда билгеләп узганча, чыганакларда торак урыннары – шәһәр, авыл, ям һәм башка төр урыннар да искә алына. Авыл атамаларының күпчелек өлеше кеше исеменә барып тоташа: Карамыш, Тугаш, Дәвеш, Чураш, Апас, Балтач, Чытыш, Шәмәрдән, Килдеураз, Чыпчык, Шәле, Ишим, Тулыш, Уразбакты, Урак, Алабуга, Кырлай, Сасмак, Чур-иле. Аларның бер өлеше кыскарып, төрләнеп, урыс графикасына «кысылып», танымаслык хәлгә дә килгән. Мисал буларак урыс атамасына яраклаштырылган Самосырово – Шәмәсер, Гилдеева – Җанкилде, Аметьево – Әхмәт (Казан шәһәре биләмәсе), Янбат – Җанбулат (Саба районы) һ.б. авылларны күрсәтергә була. Тарихи язмалар буенча ханнар, бәк-мирзалар һәм башка идарәчеләрнең исем-шәрифләренә бәйле авыл-утарлары атамалары да сакланып калган: Мәхмүтәк, Шаһгали, Ядегәр, Кошчак, Карамыш авыллары, Көрәеш бистәсе (Көрәеш мирза), Әхмәт, Кадыш (княз) бистәләре һ.б.

Авыллар атамасы башка төр очракларга бәйле дә кушылган. Мәсәлән, һөнәрчелеккә бәйле рәвештә: Балыкчы, Уракчы, Балтачы, Бакырчы, Остачы. Кабилә атамалары буларак та: Сабакүл, Тәмте, Чаллы, Бөрсет, Сөн, Аты. Әһәмиятле вакыйгага бәйлеләр дә очрый: Яңа Сала, Бүләк (Билек?), Җиләкле алан. Елга атамасына бәйлеләр: Бәтке, Гамбәрчәк, Ыргыз, Каеп һ.б.

Тарихи чыганакларда искә алынган төрки-татар атамаларның зур өлеше бүгенге чорда урыс атамаларына алыштырылган. Мәсәлән: Аккирмән – Белгород-Днестровский, Карасу – Елецъ, Саркыл – Белая Вежа, Җаек – Урал, Богородское – Сәфәргали, Каратун – Красновидова һ.б.

Әдәбият

Росстат 2010, Приказ № 74 и приложение № 2. http://www.perepis-2010.ru/documents/acts/.

Полное собрание русских летописей (ПСРЛ). ПСРЛ. Т.IX. Ч-1. Летописный сборник, именуемый Патриаршей или Никоновской летописью. – СПб., 1862. – 256 с.; ПСРЛ. Т.X. Летописный сборник, именуемый Патриаршей или Никоновской летописью. – СПб., 1885. – 244 с.; ПСРЛ. Т.XI. Летописный сборник, именуемый Патриаршей или Никоновской летописью. – СПб., 1897. – 254 с.; ПСРЛ. Т.XII. Летописный сборник, именуемый Патриаршей или Никоновской летописью. – СПб., 1901. – 266 с.; ПСРЛ. Т. XIII. Патриаршая или Никоновская летопись. 1 пол. – СПб., 1904. – 303 с.; ПСРЛ. Т. XIII. Патриаршая или Никоновская летопись (Царственная книга). 2 пол. – СПб., 1906. – С. 303-533. – 8л. илюстр.; ПСРЛ. Т.XIV. Ч. 1. Повесть о честном житии. – СПб., 1918. – 285 с.; ПСРЛ. Т.XIV. Ч.2. Указатель к Никоновской летописи. – СПб., 1918. – 285 с.; ПСРЛ. Т. IX. Летописный сборник, именуемый Патриаршею или Никоновскою летописью. – М.: Наука, 1965. – 269 с.; ПСРЛ. Т. XX. Ч. 1. Львовская летопись. – СПб., 1910. – 542 с.; ПСРЛ. Т. XX. Ч. 2. Львовская летопись. – СПб., 1914. – 270 с.;

Вернадский Г.В. Монголы и Русь. М.: ЛЕАН, Аграф, 2004.

О МОНЕТАХ С ТОПОНИМОМ «ШОНГАТ»

О.В. Степанов, А.И. Бугарчёв

Аннотация: *В статье публикуются новые находки медных монет, несущих название места чеканки «Шонгат». Авторы в первую очередь обращают внимание на метрологию данных уникальных пулов, общее количество которых на сегодняшний день известно всего 13 экземпляров. Выявлено, что расчётный вес пулов «Шонгат» – 2,0±0,1 г, что соответствует весу пулов Нового Сарая 763/ 1361-1362 гг.*

Ключевые слова: *пул, «Шонгат», Большеатрясское селище, XIV в.*

Как известно, последние монеты, чеканившиеся в XIV в. в Булгарском вилайете, имеют дату 740 г.х. (1339–1340) [Петров, Бугарчёв: 2012. С. 176, № 15]. Долгое время считалось, что монетный двор (далее – МД) Булгар до начала реформы Шадибека (802–810/ 1399–1407) не работал. Однако в последние годы было установлено, что 1360–1390-гг. в Булгаре надчеканивались и перечеканивались джучидские медные монеты [Мухаметшин, Фёдорова: 2016. С. 20–23]. Кроме того, большое количество пулов типов «лев и солнце», «двуглавый орёл», «розетка» и с именем Хызр-хана, выпускавшиеся в 1336–1361 гг., встречаются на многих археологических памятниках Татарстана, например, Булгарском городище [Янина: 1962], Иске-Казанском археологическом комплексе [Бугарчёв, Степанов: 2017], Джукетау [Лебедев, Бугарчёв, Гумаюнов: 2008] и других.

Исследуя монетный комплекс Селитренного городища, в статье 2002 г., В.П. Лебедев и В.Б. Клоков высказали гипотезу: «пулы с цветочной розеткой и указанным местом чеканки – Сарай ал-Джадид – могли выпускаться на разных монетных дворах» [Клоков, Лебедев: 2002. С. 149]. Продолжая эту мысль, есть основания говорить о том, что перечисленные типы пулов 737–762 гг.х. (1336–1361 гг.) выпускались в том числе на монетных дворах, находящихся на территории современного Татарстана.

Кроме предположений, известен факт чеканки пулов на МД, условно называемом «Шонгат». По мнению впервые сообщивших о монетах «Шонгата» С.В. Гумаюнова и И.В. Евстратова, данные пулы чеканились в 1360–1370 гг. на территории Большеатрясского селища, находящегося в Тетюшском районе Татарстана [Гумаюнов, Евстратов: 2003. С. 79–81]. Всего публикаторам были известны 9 экземпляров пулов «Шонгата».

Метрология была приведена в интернет-базе данных ZENO. Прорисовка подобного пула приводится в статье Д.Г. Мухаметшина [Мухаметшин: 2006. С. 372, Рис. 6, 5].

Новые пулы "Шонгата"

Два пула «Шонгата» были найдены в Иске-Казани [Бугарчёв, Степанов: 2017. № 170–171]. Их вес 1,50 и 1,52 г.

Осенью 2017 г. около села Большие Атряси Тетюшского района Татарстана были найдены ещё две медные монеты, которые были определены как пулы «Шонгата». Их вес 2,00 г и 1,52 г. Таким образом, на сегодняшний день известно о 13 монетах с топонимом «Шонгат».

Суммарно их метрология выглядит следующим образом (с округлением до 0,1 г): 1,5 г – 3 экз., 1,8 г – 2 экз., 1,9 г – 1 экз., 2,0 г – 4 экз., 2,1 г – 2 экз., 2,3 г – 1 экз. Исходя из этого, вычисляется расчётный вес – 2,0±0,1 г, средний вес 1,88 г. Для сравнения приведём метрологию пулов Килдибека 763 г.х., найденных в деревне Сахаровка (Алексеевский район Татарстана, учтено 28 пулов) – расчётный вес 2,1±0,1 г, средний вес 2,16 г [Степанов, Бугарчёв: 2017. С. 30]. Как мы видим, в весовом значении пулы «Шонгата» соответствовали пулам 763/1361–1362 гг.

Таким образом, монетная чеканка, как минимум – медная, в Булгарском регионе не прекратилась. Пулы прежних выпусков перечеканивались и надчеканивались, также появился их новый тип с характерным индивидуальным оформлением – пул «Шонгата». Указанные мероприятия проходили на булгарских монетных дворах на протяжении полувека во второй половине XIV в.

Литература

1. Бугарчёв А.И., Степанов О.В. Надчеканенные пулы XIV в. из Иске-Казани // Археология евразийских степей, № 6. / Гл. ред. А.Г. Ситдиков. 2017. С. 79–83.

2. Гумаюнов С. В., Евстратов И. В. Шонгат – неизвестный монетный двор Золотой Орды // Одиннадцатая Всероссийская нумизматическая конференция. СПб.: Изд-во Государственного Эрмитажа, 2003. С. 79–81.

3. Клоков В. Б., Лебедев В. П. Монетный комплекс с Селитренного городища (Золотая Орда, город Сарай) // Древности Поволжья и других регионов. Вып. IV. Нумизматический сборник. Т. 3 / Гл. ред. П. Н. Петров. М.: Информэлектро, 2002. С. 73-165.

4. Лебедев В. П., Бугарчёв А. И., Гумаюнов С. В. Монетное обращение Джукетау по нумизматическим данным // Труды Международных нумизматических конференций. Монеты и денежное обращение в монгольских государствах XIII–XV вв. Болгар 2005, Волгоград 2006 / Под редакцией П. Н. Петрова. М.: Нумизматическая литература, 2008. С. 39-49.

5. Мухаметшин Д.Г. Нумизматические материалы второй половины XIV–нач. XVI вв. К вопросу о казанской чеканке // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала / Отв. ред. Ф. Ш. Хузин. Казань: РИЦ «Школа», 2006. С. 359-375.

6. Мухаметшин Д. Г., Фёдорова Е. А. Нумизматический материал из Болгар по итогам раскопок 2014 г. // Нумизматика Золотой Орды. № 6. Казань. 2016. С. 18–32.

7. Петров П. Н., Бугарчёв А. И. Монеты Узбек-хана, выпущенные монетными дворами Булгарского вилайета // Stratum plus. № 6. Санкт-Петербург, Кишинёв. Одесса, Бухарест, 2012. С. 173–181.

8. Степанов О. В., Бугарчёв А. И. Находки джучидских монет из окрестностей д. Сахаровка Алексеевского района РТ // X Всероссийская научно-практическая историко-краеведческая (с международным участием) конференция «Проблемы истории и культуры Татарстана и народов Волго-Уральского региона». Вып. 6. / Под ред. А. А. Бурханова. Казань: Изд-во «Яз», 2017. С. 29–32.

9. Янина С. А. Общий обзор коллекции джучидских монет из раскопок и сборов Куйбышевской археологической экспедиции в Болгарах (1946–1958 гг.) // Материалы и исследования по археологии СССР. № 111. 1962. С. 153–178: ил.

НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ

(Дәвамы. Башын карагыз: № 3, 2018)

О.Р.Хисамов, И.Г.Закирова

Каргат районы

2017 елгы экспедиция вакытында Каргат районының Муса, Форпост, Җәйләү һәм Кышлау авылларында да материал тупланды. Биредә бараба татарлары һәм Казаннан килгән татарлар яши. Авыллар күп чакрымнарга сузылып киткән сазлыклар арасында урнашкан. Новосибирск өлкәсенең зурлыгы буенча икенче урында торган Уба күле дә шушы район территориясенә керә. Бу күлдән кайчандыр дистәгә якын төр балык тотканнар. Ул күл якын-тирә авылларны ризык белән тәэмин итеп торган, халык тормышында мөһим роль уйнаган. Хәзерге вакытта 37 км озынлыктагы һәм 17 км киңлектәге күлнең тирәнлеге бер метрдан артмый. Күлнең саегуы аның экосистемасының бозылуына да китергән. Күлдән бигрәк сазлыкка охшап калган Убада бары вак кәрәкә балыгы гына калган.

Халык сөйләвенә караганда Каргат районының исеме Каргат елгасыннан алынган, елга исеме карагат, ягъни карлыган сүзеннән килеп чыккан. Биредә карлыган күп үсә, шуннан исеме килеп чыккан дигән фикер бар.

Муса авылының исеме татарча булса да, биредә татарлар гына түгел, руслар һәм башка халыклар да яши. Авыл исеме кеше исеменнән алынган. Риваятьләр бу исемне авылга нигез салган кеше исеме белән бәйли. Информантыбыз Зөфәр абый Сөләйманов авыл исеменең килеп чыгуын болай дип аңлатты: «Бер бабай килгән Россиядән. Монда Хөснетдин Мифтахов бабайның Муса исемле улы үлгән. Шуны беренче итеп җирләгәннәр. Авыл исеме шуннан».

Зөфәр абый сөйләве буенча, Муса авылына 1921 елгы ачлыктан качып килгән халык нигез салган. Халык Идел буеннан килгән. Оренбург өлкәсенең Габдрахман авылыннан килгәннәре дә булган. Алар башта Җәйләүгә килгәннәр. Җәйләү бу яклардагы иң борынгы татар авылы. Җәйләүдән Сарыкамышка күчеп өч ел яшәгәннәр. Аннары бирегә күченгәннәр. Муса авылы төзеләчәк урында хутор кебек булып өч - дүрт йорт урнашкан башта.

Муса авылы халкы һәрвакыт Сабан туйларын үткәреп, матур итеп кунакка йөрешеп яшәгән.

Сабан туйлары бик күңелле уза иде. Почти каждый год була торган иде. Акча бирәләр иде җитәкчеләр, колхоз җитәкчеләре. *Атлар ча-*

быштыралар иде. Посевной компания беткәч, бүләкләр бирәләр, чабышлар була. Мин үзем *1957 елда 12 июньдә атта чаптым. Сабан туена бүләк җыялар иде. Битъяулык бирәләр иде, кулъяулык бирәләр. Битъяулык – сөлге ул. «Бүләк бир Сабантуйга»,* – дип әйтәсе юк, алдан әзерләп куялар. Колга белән бүләк җыючылар килгәнне күреп, халык бүләген алып чыга. Бүләкне шул агачка эләктерәләр. Сабантуйга йомырка буйыйлар. Шул бүләк җыючыларга бирәләр. Сабан туенда баганага меңәләр, әтәч алырга. Көрәшкә тәкә бирәләр. Татарча җырлыйлар. *Каргаттан да киләләр җырларга (Муса авылы. Сөләйманов Зөфәр Нури улы, 1931 елгы).*

Хуҗиәхмәт Мәхмүтов 1967 елгы фольклор экспедициясе вакытында Муса авылы турында түбәндәге мәгълүматларны язып куйган:

«Муса район үзәгеннән 45 чакырым ераклыкта утыра. Бередә Чапаев исемендәге колхозның үзәк усадьбасы урнашкан.

Авылда 155 йорт. Шулардагы *30 дан артык хуҗалык – руслар. Колхоз председателе – Шибатько Илларион Игнатович. Авыл советы председателе – Габидуллин Григорий Миңгалиевич. Парторг – Евкин Феликс Яковлевич. Авылда урта мәктәп бар. Укыту рус телендә алып барыла. Мәктәп директоры – Гизатуллин Яхъя Габидулла улы.*

Муса авылында шулай ук 200 урынлы клуб, элемтә бүлеге, китапханә, радиоузел, медпункт һәм сельпо бар. Клубның кызыл почмагында, русча басмалардан тыш, «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналлары алына. Китапханәдә татарча китаплар бармак белән генә санарлык. 9000 китаптан 150 ләп кенә. Китапханә мөдире Салихова Мәгъфирә Хәсән кызы.

Халык колхозда терлек асрау һәм игенчелек белән шөгыльләнә.

Муса авылына тиздән 60 яшь тула. Клуб мөдире Миңзифа Усманова (50 яшьтә, шушы авылда туып-үскән), пенсионер Нуретдин Сөләйманов (72 яшьтә, бирегә 1921 елда килә) һ.б. сөйләвенә караганда, бу авыл 1908-1909 елларда салына башлаган. Халык җир җитмәүдән күчеп килгән булырга тиеш. Аларның чыгышы Татарстанның хәзерге Баулы районы Хансевар, Карамалы, Салих авыллары, Башкортстанның Ярмәкәй авылларыннан. Беренчеләр булып Умербаев Тимербай, Умербаев Тимерпулат, Фәтхуллин Лотфулла дигән кешеләр килеп утыра. Башта бередә өч йорт урыслар була. Фамилияләре Никитиннар. Болар әйтәләр: без татарларны яратабыз, әйдәгез, бергә торыйк дип.

Авылның исеме турында мондый риваять бар: Бирегә беренчеләр булып күчеп килүчеләрдән Мифтахов Хөснетдин исемле кешенең хатыны килгән вакытта йөкле була. Авылда беренче туган балага Муса дип исем бирәләр. Шушы ук исем авылга да кушыла.

Элеккерәк вакытта Муса тирәсендә Багдад, Бөгелмә, Кадыйр, Лабан исемле кечкенә-кечкенә татар авыллары булган. Хәзер аларның берсе дә

калмаган. Халыкның бер өлеше Мусага күчкән, калганнары башка якларга таралышканнар».

Экспедиция эшләгән соңгы авыллар – Җәйләү һәм Кышлау (русча Теренино и Шибаки). Бу авыллар бер берсенән ерак түгел урнашып, исеменнән үк күренгәнчә берсендә кыш чыксалар, икенчесендә җәен яшәгәннәр дип сөйлиләр. Хәзерге вакытта Кышлау авылы юкка чыгу алдында. Анда берничә генә хуҗалык калып бара. Җәйләү авылы исеменә туры килеп, җәй көне матур җәйләүгә әйләнә, ялга кайтучылар авылга җан кертеп җибәрә. Кышын халык азрак кала.

Җәйләү авылында информантларыбыз безне авыл клубында көтәләр иде. Чын татарча итеп, чәйләр куеп, татар халкының милли ризыкларын пешереп, кадерле кунаклар итеп каршы алдылар. Бу очрашу барыбыз өчен дә матур бер бәйрәм булды дисәм дә арттыру булмас. Ул авыл халкы өчен яшьлекләрен искә төшерергә, истәлекләре белән уртаклашырга да этәргеч бирде, халыкның асыл кыйммәтләре барланды.

Халык ата-бабаларының Идел буе ачлыгыннан качып, кечкенә арба тартып җәяү килгәнен риваятьләр буларак саклый. Җәйләүнең төп халкы бараба татарлары белән Казан татарлары тиз аралашып киткән тел-сөйләмдәге аерымлыклар халыкта шактый гына мәзәкләр чыгуга да китергән. Шундый мәзәкләрнең берсе Казан кызы турында:*«Казан кызы бараба татары егетенә кияүгә чыккан. Кичен, йокларга җыенганда киленгә «ишекне сула» диләр икән. Килен аңлап бетермәсә дә,* кайтарып сорап тормаган. Монда шулай кирәктер дип, ишеккә бер чиләк суны сипкән ди. «Сула» – ул бикләү дигән сүз икән. Икенче киленгә: «утыс самоварны», – диләр икән. «Нинди утыз самоварыгыз булсын, бер генә бит самовар», – дип әйтә ди Казан кызы. «Утыс» – ул утырт, ягъни самовар куй дигән сүз булган».

Барабалылар балык тоткан, ауга йөргән. Иван чәй, төче тамырны (солодка) чәй итеп эчкәннәр.

Авылның мәчете дә булган. Ул сугышка кадәр диярлек торган да, сугыш алдыннан гына бетергәннәр. Аен кискәч, ай очып киткән. Кая төшкәнен дә күрүче булмаган, күпме эзләсәләр дә таба алмаганнар. Халык Корбан, Ураза гаетләрен мәчет беткәннән соң өйләрдә җыелып укыган. Һәр йорт хәзергә кадәр авыз ачтыра, корбан суя, дини йолаларны үтәп яши.

Биредә Яңа елны каршылау бәйрәме – Нәүрүзне дә бәйрәм иткәннәр. Аны Сәдака бәйрәме дип атаганнар. «Сәдәка бәйрәмендә өйдә һәркем төрле ашлар пешерә дә инде, чәй эчә торганнар иде. Баурсаклар, ашлар шулай пешерәләр иде. Йомырка буйый идек. Бер-беребезгә кунакка керә идек», – дип искә алалар апалар бу бәйрәмне. Яшьләр, балалар Сәдака бәйрәмендә өйдән-өйгә йөреп теләк теләгән, сәдака җыйган. Нәүрүз дә Казан татарла-

рында нәкъ шулай уздырылган. Шул яшьләрнең акча җыюы да календарь йоланың исемен Сәдака бәйрәме дип үзгәртүгә сәбәп булган.

Садака бәйрәмендә яшьләр, балалар өй саен кереп йөри.

Садәка, садәка,
Акчаларын – кесәгә,
Муллаларын – оҗмахка
Шайтаннарын – тәмухка,

дисең инде, тиенләп акча бирәләр иде, пешкән әйбер, йомырка да бирәләр. Буямыйча гына бирәләр, зурлар йөрми, балалар йөри. Югырак вакыт иде. Нәрсә булса да бирәләр иде. Аннары күл буйына бара идек менә, яшьләр бөтенесе. Анда бергәләп ашлар, бәрәңге пешерә идек (Җәйләү авылы апалары сөйләгәннән).

Биредә экспедициядә булганнан соң, әлеге ике авыл турында Х.Ш. Мәхмүтов түбәндәге мәгълүматны бирә: *«Болар Каргат районының Форпост Каргатский авыл советы составына керәләр. Һәр икесендә – колхоз бригадалары. Халык терлек асрау һәм игенчелек белән шөгыльләнә.*

Җәйләүдә – 35 йорт, Кышлауда – 37.

Борынгы заманнарда бу авылларда җирле бараба татарлары яшәгән. Хәзер Казан татарлары белән күп аралашкан.

Һәр ике авылда башлангыч мәктәп бар. Башка культура һәм көнкүреш хезмәте учреждениеләре юк.

Элеккерәк заманда бу ике авылда бер үк кешеләр яшәгән. Кыш көне бер авылда – Кышлауда, җәй көне икенчесендә – Җәйләүдә.

Авылларның тагын Тәрәнә (Җәйләү) һәм Шыбак (Кышлау) дигән исемнәре дә бар. Тәрәнә – имештер *«тәрергә» (җыярга – карлыган җыярга) сүзеннән алынган. Шыбакны* чабак сүзеннән дип аңлатучылар да бар. Бу авыл Каргат күле буена урнашкан.

Ә бу авылдан 70 яшьлек Монасыйпов Абделхак Аббас улы Шыбак исемен башкача аңлата: «Имештер, бер 300 еллар элек бу урында Шыбак исемле бер кеше яшәгән. Ул кнәз шикеллерәк бер кеше булган. Аның фармазоны – сихерчесе булган икән. Шушы Шыбакка үтеп барышлый байлар, купецлар кергәч, ул алар белән мондый уен уйнаган. Бер савыт алган, аңа көл салган. Шуннан ике якта көлгә алтын салалар. «Бута!», – ди Шыбак байга. Бай бутый. Хәзер теләгән ягыңны ал, ди. Бай, үзе бутагач, белә бит инде алтынның кайсы якта икәнен. Ләкин соңыннан тикшереп карасалар, бөтен алтын Шыбак ягында булып чыга икән. Моны, имештер, өй артында ятучы фармазон шулай алыштыра икән. Шулай итеп Шыбак бик баеп киткән, ди».

Бу авыллар бик борынгы булырга тиеш. Шул ук Абделхак бабай авылның иске зират урынында (хәзер аның күп өлеше күл астында), яр буенда

үзләре кечкенә вакытта иске замандагы горшоклар һәм башка әйберләр табылуы турында сөйли.

Тәрәнә (Җәйләү) авылыннан 80 яшьлек Мостафин Габдрахман бабай үзенең бабаларының (бараба татарларының) бу авылда бик күптәннән яшәүләре турында сөйли. Ул мондый шәҗәрә китерә: «Ләвәлләү, аның улы – Бәкшән, аның улы Төхфәтулла, аның улы – минем әти Мостафа булган. Һәркайсы 75–80 яшькә кадәр яшәгәннәр. Әле Ләвәлләүгә кадәр бик күп элек биредә минем бабаларым торганнар. Тик аларның исемнәре генә онытылган, – ди ул.

Бу авылларда халык бик борыннан аучылык, балык тоту, мал асрау, соңга табарак шулай ук игенчелек белән шөгыльләнгән».

Бу язмада авылның борынгы исеме дә искә алына. Җәйләү авылының Тәрәнә авылы булуы аңлашыла. Тәрәнә яки Җәйләү авылында атаклы галим академик В.В. Радлов та булып, ул биредә шактый гына материал язып алган. Галимнең шушы эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак дөнья күргән 10 томлык «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» дигән хезмәтенең 1872 елда басылып чыккан дүртенче томы шушы авылда «Тәрәнә ил»дә һәм «Бараба ил»дә язып алынган материаллар белән ачыла. В.В.Радлов Тәрәнә илнең Каргат күле (Каргат күленнән башланып киткән Каргат елгасы да бар) янында һәм Бараба илнең Ом суы (елгасы) буенда урнашуын күрсәтә. Әлеге җирләрдә бараба татарлары яшәгәнен, бу авыл исемнәренең ыру-кабилә исеменнән алынганын галим үзенең «Из Сибири» дигән хезмәтендә күрсәтә: «Они делятся на семь волостей, каждая имеет свою управу. Названиями волостей и селений чаще всего служат родовые и племенные названия». «Тәрәнә ил» дигәндә Тәрәнә дигән кабилә нигез салган авыл күздә тотыла. «Бараба ил» хәзерге вакытта Барабинск шәһәре тирәсе халкы буларак мәгълүм.

Хәзерге вакытка авылның татарча иске исеме Тәрәнә булуы онытылып бара. Ул авылның рус телендәге рәсми атамасында Теренино буларак кына сакланып калган. Тәрәнә авылында Хәмит Ярми 1940 елгы экспедиция вакытында да була. Ул, В.В.Радлов булган авылларда булып, халыктан академик В.В.Радлов турында да сорашкан. Галим Тәрәнә авылында 1940 елның 22–23 маенда язып алган «Кузы Курпы мән Паян-Сылу» («Кузы Көрпә белән Баян-Сылу») дастаны янына болай дип язып куйган: «*1870 елларда шушы Тәрәнә авылында В.В.Радлов булып киткән. «Авылда күп кенә карт кешеләр бар» дигәч мин бу авылның иң карт кешеләрен җыйнап Радлов турында сораштым. Чөнки мине Радловның нинди кеше булуы, бу ерак Себердәге татар авылларында аның ничек эшләп йөрүләре, халык иҗатын ничек һәм кемнәрдән язып алулары бик нык кызыксындыра. Минем уемча Радлов бу авылларда бик аз тук-*

талып үтеп китүенә карамастан, ул халыкның тел үзенчәлекләрен бик яхшы тотып ала белгән һәм әкият, дастаннарны халыкның үз телендә (үз шивәсендә) бик матур итеп язып алган. Аның әйтүенә караганда дин әһелләре фольклор язып йөрүенә бик нык каршылык күрсәткәннәр, ләкин ул, шулай булуга карамастан, күп эш эшли алган.

Минем үтенүем буенча җыелышка түбәндәге картлар килде: Хәсән Кәримов (77 яшь), Фазулла карт (85 яшь), Габдулла карт (90 яшь), Габбас карт (92 яшь) һәм Гыймран карт (70 яшь). Бу картлар белән бик озак сөйләшеп, гәпләшеп утырдым. Мин аларга Казан хәлләрен сөйләдем, ә үзем шушы ерак Себер җирләрендәге борынгы тормыш хәлләрен тыңлап, мәс килеп утырдым. Кайбер материалларны язып алдым. Картлардан 92 яшендәге Габбас карт кына В.В. Радлов килүен хәтерли. «Мин яшь идем. Безнең авылга озын гына, башына кара эшләпә кигән бер кеше килгән иде. Аның картларны чакырып сөйләшкәнен хәтерлим. Ни язгандыр, ни сорагандыр, анысы белән кызыксынмадым. Ул вакытта без бер нәрсә белән кызыксынмадык. Аның янында бер яшь кеше дә бар иде сыман. Алар бездә берничә көн торып киттеләр», – ди. В.В. Радловның архивын, көндәлекләрен табасы иде, анда сәяхәте турында да бардыр дип уйлыйм».

Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның экспедиция язмалары бер кызыклы мәгълүмат саклый. Бу Бараба татарларының кеше исемнәре. Информант 1887 елда туган Мостафин Габдрахман бабайның шәҗәрәсен искә ала. Биредә хәзерге вакытта очрамый торган ике исем – Ләвәлләү һәм Бәкшән дигән ир кеше исемнәре очрый. Һәр буынга якынча 25 ел биргәндә бу исемнәрнең бараба татарларында XIX гасыр башында кушылган булуы аңлашыла. Соңрак гарәп исемнәре килеп кергән. Ләвәлләү исеменең этимологиясе ачык түгел. Ул бозылган яки кыскартылган булуы да мөмкин. Бу күренеш татар халкында шактый очрый. Себер татарларында ул бигрәк тә таралган булган. Мәсәлән, исемнәре җырга кергән Әйтүкәнең тулы исеме Әйтмөхәммәт, Батышның чын исеме Фатыйма. Ә Бәкшән дигән исем Казан ханлыгы вакытыннан татарларда мәгълүм булган.

Йомгак ясап әйткәндә, экспедиция барышында төрле жанрларга караган фольклор материаллары язып алдык, халыкның кул эшләре белән таныштык, тарихы, ышанулары, шөгыле турында мәгълүмат саклаган топонимиясен барладык. Гарәп язулы кульязмаларны, китапларны, эпитафик истәлекләрне өйрәндек. Халыкның тел үзенчәлекләрен чагылдырган материал тупладык. Әмма бер мәкалә кысаларында бөтен материал белән таныштыру мөмкин түгел. Алар Институтта «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясендә дөнья күрәчәк китапта урнаштырылачак.

КОРЪӘН СҮЗЕНЕҢ ИДЕЛ БУЕНА БЕРЕНЧЕ КИТЕРЕЛҮЕ

Ф. З. Яхин

Һиҗрәтнең 7-нче елында, ягъни Европада кабул ителгән Милади ел исәбе белән 629-нчы елда, борынгы бабаларыбызга бәйле мондый вакыйга булганлыгы хакында Мисыр галиме Мөхәммәт Чокрыкчызадәнең «Алты бармак китабы»нда болай дип язылган: «(Бер вакыйга дәхи) Фәруһ бине Гомру Хазами – Рум падишаһы тарафыннан, арду-Болгардан, гоман хакиме иде, мөселман улды. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәссәлләмә мәктүп күндереп, кәнде мөлазимнәреннән, Мәсгуд бине Сәгъд нам кемсә илә нәчә төхфә, һидийә тарикыйлә, билә күндерде. Мәдинәйә кәлүп, намәсене Рәсуллуллаһы саллаллаһи тәгалә галәйһи вәс-сәлләмдә укыдылар.

Язмыш ки: «Бу мәктүп хәзрәте Пәйгамбәр саллаллаһи тәгалә вәс-сәлләмә Фәруһтан, шуйлә әгълам идәр ки: бән иманә кәлдем, Аллаһы тәгаләнең вәхдәниятенә вә сәнең нәбүвәтеңә икърар итдем, белерем, сән ул пәйгамбәрсең ки, Гайсә галәйһис-сәлам сәнең киләчәгеңнән бәшарәт итте, вәссәламү-галәйкүм!».

Хәзрәт ул килән кемсәйә әкрам итте. Билалә әмер итте: дәрел-зыйафәтә кундыра вә һидайәсен кабул итте.

Әйдерләр ки, бер бийаз катыр һидайә әрсал итде вә алтын илә тукынмыш бер сондус кафтан вә берничә нәснә. Дәхи катры Әбу-Бәкрә багышлады, кафтаны Мөхрәмә бине Нуфалә ихсан итте. Вә бер ат вә бер мәркәп вар иде, анлары Сәгъд-Сәгъдияйә вирде. Та кем, күзәдә вә инҗә җамәләр вар иде. Хатыннарына кыйсмәт итте. Намәнең җавабында язды ки: «Мөхәммәд рәсулуллаһтан Фәруһийә язылды, әмма бәгъдә күндердегең безә вәсил улды вә Исламыңнан хәбәр вирмешсән, тәхкыйк Хак тәгалә сәне тугыры юлә дәлаләт итмешдер, әгәр бәшвакыт намазы кылып вә зәкәтеңе әда идәрсәң!»

Вә Билалә әмер итде, Мәсгудә бәш йөз дирһәм вирде вә аны кире вилаятенә күндерде.

Нәкль улыныр ки, Фәруһның исламының хәбәре Рум падишаһына иреште. Адәм күндереп, Фәруһйы таләп итде вә әйтде: «Мөхәммәд диненнән дүн, сәңа нечә мәмләкәтләр вирәйем!».

Фәруһ әйтде: «Дүнмәзем! Зирә белүрем ки, Хак пәйгамбәредер. Вә сән дәхи белерсең ки, Гайсә бине Мәрйәм, галәйһүммас-сәлам, кәлимәсе илә бәшарәт итте ки пәйгамбәрлеген. Мөлкеңнән вә мәмләкәтеңнән аерыламыз, сән бәне Хактан манигъ идәр».

Аннан Рум падишаһы аны хәбес итте. Нечә мөтдәттән соңра катыйль идеп, җәсәдене дарга асды, рәхмәтуллаһи галәйһи!» [*Чокрыкчызадә*: 1905. 427–428 б.].

Бу текстның хәзерге татар теленә тәрҗемәсен бирәбез: «(Тагын бер вакыйга) Гомру улы Фәруһ Хазами – Рум падишаһлыгы тарафыннан, Булгар җиреннән, гуман [халкының] хөкемдары иде, мөселман булды.

Пәйгамбәр саллаллаһ галәйһи вәс-сәлләмгә хат ирештереп, үзләре тиешле күреп, хөрмәт күрсәтүен белдерер өчен Сәгъд улы Мәсгуть исемле кешене ничә төрле бүләк белән монда җибәрде. Ул, Мәдинә шәһәренә килеп, хан язган хатны Аллаһының Рәсүле саллаллаһы тәгалә галәйһи вәс-сәлләмгә укыдылар.

Язган: «Бу хат Пәйгамбәр хәзрәтләре саллаллаһы тәгалә вәс-сәлләмгә Фәруһтан, шулай дип белдерә: мин иманга килдем, Аллаһы тәгаләнең бердәнберлегенә вә синең пәйгамбәрлегеңә ышанычымны белдердем, беләм, син ул пәйгамбәр буласың – Гайсә галәйһис-сәлам синең киләчәгең хакында сөенечле хәбәр бирде, сиңа иминлек ирешсен!».

Хәзрәт ул килгән кешегә хөрмәт күрсәтте. Билалга әмер итте: йортында аш уздырып аны кунак итә. Һәм бүләкләрен алды.

Әйтәләр, хан бер ак ат бүләк итеп китерде һәм алтын белән тукылган бер ефәк кафтан һәм берничә нәрсәләр. Аннары [Пәйгамбәр] атны Әбу-Бәкергә багышлады, кафтанны Нуфал улы Мөхрәмәгә зурлап бирде. Һәм бер ат һәм аргамак бар иде, аларны Сәгъд һәм Сәгъдиягә бирде. Тагын да чинаяк һәм энҗе чәшкеләр бар иде. Хатыннарына насыйп итте. Хатка җавабында язды: «Мөхәммәд рәсүлуллаһтан Фәруһка язылды: шулай итеп, җибәргәннәрең безгә килеп иреште. Һәм Исламыңнан хәбәр биргәнсең, шиксез, Аллаһы тәгалә сине туры юлга керткән, әгәр бишвакыт намазыңны кылып һәм зәкәтеңне үтәрсең!».

Һәм Билалга әмер итте: Мәсгудкә биш йөз акча бирсен һәм аны иленә кайтарып җибәрсен.

Хәбәрдә шулай сөйләнелә: Фәруһның Ислам динен алу хакындагы хәбәре Рум (Византия) патшасына килеп иреште. Ул, кеше җибәреп, Фәруһны чакыртты һәм аңа әйтте: «Мөхәммәд диненнән кайт, сиңа күп илләрне бирермен!», – диде.

Фәруһ җавап бирде: «Кайтмыйм! Чөнки беләм: ул – Хак тәгаләнең пәйгамбәре. Һәм син дә беләсең, Мәрьям улы Гайсә, аларның икесенә дә Аллаһының сәламнәре булсын, үз теле белән сөенечле хәбәрендә пәйгамбәрлеген әйтте. Мөлкәтеңнән һәм мәмләкәтеңнән аерылабыз, чөнки син мине Хак тәгаләдән аерасың», – диде.

Аннары Рум патшасы аны тоткын итте. Ничә вакыттан соң, үтертеп, гәүдәсен дар агачына асты, (Фәруһка) Аллаһының рәхмәте булсын!»

Бу тарихи риваятьнең авторы – Мөхәммәт Чокрыкчызадә Төркиянең Бурдә шәһәрендә Тарикъ Бәйрәмнән һәм Сәед Җәгъфәр хәзрәтләреннән белемнәр алган. Берара вакыт Солтан Мөхәммәт-хани мәчетендә имамлык итә, шул елларда зур галим буларак таныла. Аннары Мисырның Каһирә шәһәренә җибәрелә, анда да мулла хезмәтен башкара һәм 1033 елның башында (ягъни, Милади ел исәбендә 1623-нче елның ахырына туры килә) вафат була.

Мөхәммәт Чокрыкчызадәнең «Алты бармак китабы»ндагы болгарларның мөселман булу, иман китерү вакыйгасы хакындагы хәбәрен тарих, әдәбият һәм фольклор фәннәренең игътибарсыз калдыруы дөрес эшме? Әлбәттә, юк! Андагы вакыйгаларны чынбарлыкка туры килми дип әйтергә һәм шуның белән аларны онытырга да була. Уңайлы юл. Әмма...

Хикмәте шунда, вакыйга мөселман ел исәбе Һиҗринең 7-нче елында, Европада кабул ителгән ел исәбе Милади белән 629-нчы елда бара. Болгарларның тарихлары Азов (Азак) һәм түбән Идел, Төньяк Кавказ белән бәйле бу чор тәфсилләүне тиешле санаган тарих гыйлеме өчен бөтенләй диярлек мәгълүм түгел сыман. Ә менә аларның күршеләре хакында җентекле хәбәрләр җитәрлек. Сәбәбе гади: ул халыклар, мәдәни милләтләргә хас булганча, үз тарихларына һәм тарихлары белән бәйле һәртөрле хәбәрләргә хөрмәт белән карыйлар. Аннары, аларның язма истәлекләре сакланып калган, бүгенге көнгә килеп ирешкән. Ә безнекеләр?.. Ә безнекеләр, булсалар да, әкияткә чыгарылып, аяк астына ыргытылганнар.

Тарихчы Г.Дәүләтшин, «Алты бармак китабы»ндагы болгарлар белән бәйле бу хәбәрне фәнни әйләнештә игътибар үзәгенә салган беренче галим-тарихчы: «Шул рәвешле «Алты бармак»та китерелгән вакыйга ул чордагы тарихи мөхиткә бик туры килә»[*Дәүләтшин:* 1999. 221 б.], – дип белдерә. Ул: «Шушы вакытта (VI гасырның 20нче елларының ахыры – VII йөзнең 30нчы елларының башы) Азов, Кара диңгез, Кубань буйларында Бөек Болгар дәүләте оеша. Бу дәүләт берләшмәләренең иң күренекле ханнары – Орган һәм Кубрат» [*Дәүләтшин:* 1999. 221 б.], – дип, «Алты бармак китабы»нда бәян ителгән тарихи вакыйганың асылына төшендерә. Ул елларда Византия белән император Ираклий (ул 575–641-нче елларда яши) идарә иткәнлеген дә искәртә. Аңа кадәр император Бөек Юстиниан хөкемдарлык тота һәм аның үлеменнән соң илдә буталыш чоры башланып китә, VII гасыр башына Византия тәмам таркалыр хәлгә җитә [Виппер: 1994. С. 279]. Шулай да кабат тернәкләнү юлы табыла, Африкадан килгән хөкемдар улы Ираклий Константинопольдә император буларак игълан ителә, ул 610–631-нче елларда тәхет тота.

Ираклийның император итеп утыртылуына күп тә үтми, фарсы шаһы Хөсрәү II (591–628-нче елларда шаһ) Византиягә (Румга) каршы сугыш

ача, тиз арада Сүрия, Фәләстин һәм Мисырны яулап ала. Иерусалимдагы (Кодсе-шәрифтәге) христиан диненә бәйле изге ядкәрләр дә аның кулына күчә. Бу вакыйгалар христиан дөньясына зур зыян сала, халыкта күңел төшенкелеге, рухи таркаулык, харабат булу хисе көчәя.

Фарсы гаскәрләренең бер өлеше Константинополь шәһәре янындагы Халкиндонга ирешә, моның өчен бөтен Кече Азия аша уза [Виппер: 1994. С. 279]. Берничә елдан фарсы гаскәре кабат килеп җитә. Төньяктан, ягъни Дунай буйларыннан төрки аварлар (алар составында славяннар да була) Константинопольгә якыная [Виппер: 1994. С. 279]. Император Ираклий качып китәргә уйлый, әмма аны патриарх Сергий туктата һәм тәхетендә калырга өнди. Яңадан гаскәрләрен туплап, император иң тәүдә аварларга сугыш белән чыга. Аларны чигендерә. Аннары фарсыларга каршы өч тапкыр яу чаба, Сүрия, Фәләстин һәм Мисырны үз кулына кайтаруга ирешә.

Бу туктаусыз алып барылган сугышлар Сүрия, Фәләстин, Мисыр халыкларына зур авырлыклар китерми калмаган. Алар, византлардан аермалы буларак, «монофелит» дип аталган христиан мәзһәбендә торганнар. Бу мәзһәб вәкилләре Гайсә пәйгамбәрдә, бер яктан – кеше асылы, икенче яктан – илаһи асыл-рух яши, әмма алар уртак – бер ихтыярга буйсыналар, ягъни илаһи җан һәм кеше җаны аңарда бергә бербөтенлек хасил иткән хәлдә, – дип беләләр. Ә Византия әһелесе аларны бу мәсьәләдә каты тәнкыйть итә тора. 680-нче елда Константинопольдә уздырылган православие христианнарының VI Гомум-Соборы (Вселенский Собор) тарафыннан монофелит карашлары кире кагыла һәм нәкъ менә шул Собор (ягъни корылтай, съезд кебек җыелып карар чыгару өчен уздырылган югары формадагы дини җыелыш) Гайсә пәйгамбәрне илаһи кеше (богочеловек, Господь, ягъни Тәгалә) дип игълан итә, аңарда кеше ихтыяры да, Хода ихтыяры да аерым-аерым яши, әмма кеше ихтыяры Хода ихтыярына буйсынган хәлдә дип белдерә [Католицизм: 1991. С. 194]. Ә бу дини-фәлсәфи карашлар, шулай итеп, изге саналган православие христианнарында бары тик VII гасыр башында гына формалаша [Католицизм: 1991. С. 194].

Император Ираклий монофелитлар белән дустанә яшәү җаен эзли, аларны үз ягына аудару сәясәтен башлый. «При Константине Погонате, или, может быть, незадолго до выступления его на престол, *болгары,* народ тюркского происхождения, под предводительством Аспаруха (Испеpуха) поселились на нижнем Дунае и основали болгарское государство» [Васильев: 1994. С. 280], – дип яза тарихчы А. А. Васильев. Ә 681-нче елда Аспарух хан Византияне Болгар дәүләтен танырга мәҗбүр итә [Васильев: 1994. С. 280].

Константин IV Погонат (ягъни Сакаллы) җиде ел буена Константинопольне камап торган мөселман-гарәп флотын «грек уты» ярдәмендә чигендерүгә һәм яндыруга ирешә. Шул ук император христианнарның монофелит мәзһәбен (680-нче елда) инкарь итү һәм юкка чыгару максаты белән Константинопольдә VI Гомум-Соборны җыя [Васильев: 1994. с. 280]. VII гасырның ахыры – VIII йөзнең башында Византия чуалыш-буталыш чорына кабат килеп керә [Васильев: 1994. С. 280].

Алар белән мөселманнар арасында каршылык Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук башланып китә. 633-нче елда Пәйгамбәребез Мәңгелек йортка күченгәч, беренче хәлифләр чорында Ислам гаскәрләре Сүрияне, Фәләстинне, Ефрат буйларын һәм фарсы илен яулыйлар, ә 637-нче елда Иерусалимны (Кодсе-шәрифне) алалар һәм VIII гасыр башына Испаниянең бер өлешен буйсындырып, франклар иленә килеп керәләр [Васильев: 1994. С. 286].

Шушы тарихи вакыйгалар эчендә бары тик болгарларның гына Ислам динен үз теләкләре белән алуына аерым игътибар бирергә һәм моңа зур мәгънә салырга тиешбез дип беләбез.

Ислам диненең дөньяга киң таралу дәвере, шулай итеп, VII гасыр ахырына – VIII йөз башларына туры килә. «Бу вакытта Бөек Болгар дәүләте таркалып, Хәзәр каганлыгына кушылган була, – дип яза Г. Дәүләтшин. – 737 елда гарәпләр Мәрван җитәкчелегендә Хәзәр башкаласын алгач, каганга һәм ил халкына ислам диненә керергә тәкъдим ителә» [*Дәүләтшин:* 1994. 221 б.]. Шунысы әһәмиятле, ни өчен мөселман гаскәрләре Идел буйларын тәмам яулап алмыйлар соң? Ул заманнарда Идел буенда, җиңелгән хәзәрләрдән гайре, аларга каршы тора алырлык ил дә булмаган түгелме? Мөселман яуларының Хәзәр каганлыгында туктап калуларының төп сәбәбе әллә болгарларның бу вакытта чыннан да Ислам динендә булулары аркасындамы?

Моңа тарих китапларында ачык җавап юк кебек. Ул хакта гарәп чыганаклары да искәртмиләр сыман. Әмма «Алты бармак» китабында бәян ителгән тагын бер вакыйгага тукталып киткәндә, сорауга җавап юлында берникадәр аңлатма да табыла. Ул моңардан гыйбарәт: Болгар ханы Фәруһ бине Гомру Хазамидән Мөхәммәд пәйгамбәргә илче булып килгән Мәсгуть бине Сәгъд Болгарстанга кабат киткәч, Мәдинәдә гыйбрәтле хәл була. Ислам диненә өндәргә дип Габдулла бине Әби-Җәдүдне гаскәр башында бер таифәгә җибәрәләр. Ул гаскәрдә Әбу-Катадә һәм Мөхәлим бине Җәсамә исемле сәхабәләр дә була. Аларга Гамер бине Әл-Ихбат әл-Ишҗагый, юлда очрап, мөселманча сәлам бирә. Әмма аның сәламен гаскәриләр алмыйлар һәм, җитмәсә, Мөхәлим аны үтерә.

Бу хакта хәбәр Пәйгамбәребезгә ирешә. Мөхәлимнән ул ни өчен мөселман кешене үтерүен сорый. Мөхәлим: «Ул үлемнән куркып мөсел-

ман булды», – дип җавап бирә. Мөхәммәд пәйгамбәр аны шушы җавабыннан соң бик каты орыша. Мөхәлим гафу үтенә. Пәйгамбәребез аңа: «Лә гаффаруллаһ ликә!» (ягъни «Сиңа Аллаһының гафуы юк!»), – дип җавап бирә, чөнки бу вакытта андый вакыйгалар белән бәйле хөкем дә ирешкән була. Шушы хәлдән соң, озак та тормастан, Мөхәлим вафат була. Аны өч тапкыр җирлиләр, әмма өчесендә дә җәсәден җир кабул итми. Бер чокырлы урын табып, шунда аның мәетен ташлар белән каплап куялар. Бу хакта Пәйгамбәребезгә хәбәр ирешә. Ул моны, ягъни җирнең кабул итмәвен, Аллаһының хикмәте буларак аңлата [*Чокрыкчызадә*: 1905. 428 б.].

Шушы вакыйга мөселманнарның болгарлар өстенә сугыш белән бармавының да сәбәбен аңларга ярдәм итә түгелме? Аннары, Пәйгамбәребезнең Фәруһ бине Гомру Хазами ханга язган хатны да искәрик, анда: «Хак тәгалә сәне тугъры юлә дәлаләт итмешдер, әгәр бәшвакыт намазы кылып вә зәкәтеңе әда идәрсәң!», – диелгән.

Шунысы тагын да әһәмиятле: Мөхәммәд пәйгамбәребезнең гомерендә иң куанычлы, сөенеч белән тулы көннәре дә шушы, һиҗрәтене 7-нче елында булган һәм аңа «Ән-Нур сурәсе» (Коръәннең 24-нче сурәсе) дә шушы вакытларда иңгән. Анда мондый (56-нчы) аять бар:

ومرحت كملعل لوسرلا اوعيطا و ةوكذلا اوتا و ةولصلا اوميقا و

«Вакыймү салата вәтүз-зәкәтә ватийгур-рәсулә ләгалләкүм түрхамүн».

(Ягъни: «Намазлар укыгыз, зәкәтләр кылыгыз һәм Рәсулен таныгыз, сезгә (Аллаһы тәгаләнең) рәхмәте ирешер).

Бу аять Болгар ханы Гомру улы Фәруһ Хазамигә язылган хат белән аваздаш яңгырый. Моңа таянып, Коръән аяте, Аллаһының сүзе Болгар иленә тәүдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламнең үз хаты белән килеп иреште дип белдерә алабызмы? Әлбәттә һичбер шикләнүсез һәм икеләнүсез бу фикергә килә алабыз!

Болгар ханының исеме хатта «Фәруһ бине Гомру Хазами» дип бирелгән. *Фәруһ* исеме *Аспарух* хан исеме белән дә аваздаш. Икесенең дә тамырлары бер. *Фәруһ* исеменең сүз мәгънәсен чыгару да мөһим, ул *фәр//пәр//бәр* һәм *уһ//ух//ук*, ягъни *«бәрук»* килеп чыга, *«аткан ук»*, *«оча торган ук»* мәгънәләренә ия. *Хазами* сүзе дә аңлашыла. Аның *Казам* яки *Хазам//Казан* икәнлеге күренеп тора, ягъни «*Казанлы»* дигән кебек. Әмма монда сүз хәзерге Казан шәһәре хакында бармый, билгеле. Казан атамасы бер бездә генә булмаган.

Аннары, җире – Болгар, халкы – гоман, диелгән. Монда сүзнең коман халкы турында бара ахрысы. 1303-нче елда латинча-фарсыча-команча төзелгән сүзлек фәнгә яхшы мәгълүм. Аннан күренгәнчә коман//күмән дип Венеция сәүдәгәрләре кыпчакларны атап йөрткәннәр. Димәк, «ко-

ман» яки «гоман» дип кыпчакларны атау Европада борынгыдан килә булып чыга. Бу сүздәге *к/г* авазларының параллельлеге кызыклы. Димәк, Фәруһның атасы *Гомру* исеменең дә *Комру* булганлыгы шик тудырмый.

Тагын да бер тарихи ядкәргә игътибар итү урынлы булыр – Дунай Болгарстанындагы Шумен төбәге Чаталар авылы (хәзерге Крумово авылы) янында табылган язулы таш. Аны «Омуртаг хан язуы» дип тә йөртәләр. «Запись хана Омуртага, – дип белдерәләр болгар галимнәре Н. Николов һәм В. Харампиев, – отмеченная годом Шегор (корова), соответствует 821 г.н.э.» [Николов, Харампиев: 1991. С. 155]. Бу факт Фәруһ ханның әтисенең исеме *Гомру* белән Дунай болгарларындагы *Омуртаг* хан исеме дә үзара аваздаш булуы хакында сөйли. Димәк, Гомру улы Фәруһ ханның тарихта булганлыгы һәм Мөхәммәд пәйгамбәребез заманында яшәгәнлеге туры дәлилләр белән ачыклана. Шул ук вакытта Фәруһ бине Гомру Хазами хан исеменең гарәп колагына ишетелеш формасында «Алты бармак» китабында язылып калынган булуын да күзаллавы авыр түгел.

Әдәбият

1. Васильев А. А. История средних веков. М.: Республика, 1994.

2. Виппер Р. Ю. История древнего мира. М.: Республика, 1994.

3. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Таткнигоиздат, 1999..

4. Котолицизм /Под общ. ред. Великовича Л. Н. М.: Политиздат, 1991.

5. Николов Н., Харампиев В. Звездачеты древности: пер. с болг. М.: Мир, 1991.

6. Чокрыкчызадә Мөхәммәт бине Мөхәммәт. «Алты бармак» китабы. Казан: Император университеты типографиясе, 1905.

БҮЛӘР (БАРАҖ) ШӘҖӘРӘСЕ

Р. С. Сәетов

Урман белән капланган бу төбәккә килгән бабаларыбыз урманнарны чистартып, чәчүлек җирләре әзерләгәннәр, иген иккәннәр. Тик табигатьнең кырыс шартлары, җирнең кызыл балчыклы булуы игенчелеккә алга китәргә мөмкинлек бирмәгән. Халык һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнә башлаган. Тиз арада авылда зур базар төзелгән. Монда Түбән Новгород, Иваново, Казан, Петербург, Урта Азия илләреннән килгән сәүдәгәрләр сату иткән. Әлеге һөнәр кардәшләребезгә мул тормышта яшәргә мөмкинлек биргән.

Бүгенге көндә Кистемдә 900гә якын кеше яши. Күпчелекне, әлбәттә, милләттәшләребез тәшкил итә. Араларында удмуртлар, бисерменнәр дә бар. Болар – күрше авыллардан Кистемгә килен булып төшүчеләр. Алар татар телен, авыл халкының гореф-гадәтләрен үзләштереп бетергәннәр. Авыл халкы затлы, зыялы нәселдән.

Удмуртия белән безнең вакытны чагыштырып караганда бер сәгать аерма бар. Ә бу авыл халкы Казан вакыты белән яши. Тагын шунысы кызык. Кистем авылы кешеләренең 99 проценты Касыймов фамилиясен йөртә. «Укучыларның барысы да диярлек Касыймов фамилиясендә. Шуңа күрә без балаларга исеме һәм әтисенең исеме белән дәшәбез. Ә безгә апа-абый дип эндәшәләр», – диләр укытучылар. Мәктәптә татар теле бары тик фән буларак кына укытыла.

Мәктәптә иң кадерле урын, мөгаен, музейдыр. Ул 1992 елда ачыла. Хәния апа Касыймова авыл кешеләре ярдәме белән бик бай материаллар туплаган. Хәзер инде ул лаеклы ялда. Аның эшен яшь тарихчы, авылның имамы Илмир хәзрәт дәвам итә.

Авыл элек-электән мәгърифәтле, укымышлы була. Музейда гарәп телендә язылган бик күп китап саклана. Алар арасында коръәннән алып әдәби әсәрләргә кадәр бар. Шуларның иң борынгысы – 1859 елда Гали Мостафа улы тарафыннан күчереп язылган «Мөхәммәдия» китабы. Биредә шулай ук авылның данлыклы шәхесләренә дә киң урын табылган. Алар үзләренең авылдашлары белән хаклы рәвештә горурланалар. Ибраһим Вәлиулла улы Әхмәров 1912 елда туа. Һөнәре буенча физика һәм математика укытучысы. Ибраһим күктәге йолдызларны биш бармагы кебек белгән. 1939 елның 14 апрелендә лекциядән кайтканда ул күктә билгесез комета күреп ала. Шунда ук Ибраһим Әхмәров район үзәгенә йөгерә һәм Пулков обсерваториясенә кометаның урнашкан градусларын хәбәр итеп телеграмма юллый. Бу ачыш ил, дөнья күләмендә танылa. Һәвәскәр астроном ЮНЕСКОның халыкара медале белән бүләкләнә. Удмуртиянең атказанган укытучысы Ибраһим ага 75 яшендә, 1987 елда вафат була. Бүгенге көндә галәмдә Әхмәров исемле койрыклы йолдыз-комета, татар йолдызы йөзә.

Казанда Таулар бистәсендә «Бертуган Касыймовлар» урамы бар. Абыйлы-энеле Галиулла белән Сәмигулла Касыймовлар Татарстан тарихында тирән эз калдырган җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр һәм нәкъ менә Кистем авылы егетләре икән. Галиулла ТАССРның халык комиссары була, Татарстан хөкүмәтенең беренче төркеменә кертелә. 1937 елда шәхес культы корбанына әйләнә. Энесе Сәмигулла хезмәт юлын үз төбәкләрендә гади укытучыдан башлап, төрле сикәлтәле юллар аша үтеп, Татарстанның Госплан рәисе дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Казанның Энергетика институты белән җитәкчелек итә. 1968 елда дөнья куя. Татарның менә шундый зыялы уллары ул – бертуган Касыймовлар.

Нурислам Зәйдулла улы Касыймов Киров педагогика институтын тәмамлаган. Глазовта физика укытучысы булып эшләгән. Штанга күтәрү буенча Удмуртия чемпионы. Сеңелесе Әминә Зәйдулла кызы гимнастика буенча СССРның спорт остасы.

Хәзерге көндә татар җыр сәнгатендә үз юлын эзләүче җырчыбыз, Финляндиядә яшәүче Җәмилә Низаметдин дә Кистем кызы. Ул җибәргән хатлардан, открыткалардан гаилә фоторәсемнәреннән музейда почмак та эшләгәннәр. Җәмиләнең үзе язган шигырьләрен, җырларын да җыялар.

Татар дөньясына Кистем авылы биргән шәхесләр арасында Франция, Алжир илләрендә француз телендә кибернетика һәм информатика укыткан галим Рифкать Касыймов, техник фәннәр кандидаты, Уфа авиация институты доценты Разия Касыймова, Русиянең атказанган геологы Хикмәтулла Арсланов, бөтен гомерен балалар укытуга багышлаган Социалистик Хезмәт герое Закир Хәсәнов, Кистем авылының шәҗәрәсен төзегән тарихчы Гыйльман Касыймовлар бар. Бүгенге көндә Удмуртиянең урман хуҗалыгы министры Рафис Касыймов, Дәүләт Советындагы 12 татар депутатлары арасында ике Касыймов та нәкъ менә Кистем авылыннан. «Казанда сөйли торган «Татар радиосы»ннан яңалыклар җиткерүче Марат Касыйм да безнеке», – диделәр миңа, сөенеп Кистемдә.

Бу төбәктә элек-электән динле халык яшәгән. Бүген дә шулай. Авылның имамы – гыйлемле яшь мулла, Татар дәүләт гуманитар институтын һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган Илмир хәзрәт Касыймов. Ул саф татар телендә сөйләшә. Бүгенге көндә аны «күз өстендәге каш» дияргә була. Илмирны авылда олысы, кечесе хөрмәт итә. Аны Бөтендөнья татар конгрессының IV съездына бертавыштан делегат итеп сайлау да нәкъ менә яшь имамның авторитеты турында сөйли.

Архив документларыннан күренгәнчә, авылда XIX гасыр башында 3 мәчет була. Беренчесе 1829 елда төзелә. Беренче указлы муллалар Фәхретдин Чәчәков һәм Габделгалим Насыйров 119 малай һәм 80 кызга үз өйләрендә белем бирәләр, дин тарихын, гарәп язуын өйрәтәләр. Ан-

нары, еллар узгач, муллаларның игелекле эшләрен уллары дәвам итә. 1894 елда Кистемдә мәдрәсә ачыла. Шул ук елда авыл мәчетен дә яңарталар. Аны Госман хаҗи төзетә. 1903 елда авылда көчле янгын чыга. Кистемнең өчтән бер өлеше янып бетә. Бу вакытта Госман хаҗи юлда була. Бу коточкыч хәбәрне ишеткәч: «Әгәр дә минем йортым исән калса, авылда яңа мәчет төзетәчәкмен», – дип сүз бирә. Ходай рәхмәте белән, хаҗиның йорты исән кала. Авылда яңа мәчет салу эше 1905 елда тәмамлана. Бу мәчет Кистем авылына бүген дә иман нурын сибеп тора.

Клубта берничә ансамбль иҗат итә. Татар җырларын, моңнарын, биюләрен, шигъриятен һәрчак халыкка җиткереп, милләтебезнең телен, динен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклаган татар авылы Кистем көн күрә Удмуртия Республикасында.

ҖИДЕ БУЫННЫ БАРЛАГАНДА НИЛӘР БЕЛЕП БУЛА

Р.Х. Әмирханов

Җиде буын бабаңны белү безнең халыкта күркәм сыйфат саналган. Бүгенге көндә халкыбыз арасында нәсел агачын төзү, ата-бабаның кем булганы белән кызыксыну арта бара. Нәсел-нәсәбәне ачыклау өчен мәгълүматны халык санын исәпкә алу материалларыннан, архивларда саклана торган никах (метрика) язуларыннан белергә була.

Рәсәй империясендә халык санын исәпкә алуның беренчесе 1718–1719 елларда була (1-че ревизия). 1730 елларның башына кадәр Нугай Урдасының көнчыгыш якларында, хәзерге Әлмәт төбәгендә һәм тирә-якта, урыс хәкимияте әле урнашмаган. Бу тирәдә урыс гаскәрләре яңа Кама аръягының күчмә чиге (новая Закамская засечная черта) төзелгәч кенә күренәләр. Шул вакыйгаларга кадәр урыс түрәләре Казан-Уфа арасындагы юлны Минзәлә аркылы гына таптаганнар. Һәм шул сәбәпләргә бәйле империядә сан алучыларның куллары безнең төбәкләргә җитмәгән. Шуңа бу тирәдә халык санын алу 1745–1746 елларда гына оештырыла (2-нче ревизия). Ә туу-үлем, никах һәм талак язуларын (1829 елдан башланалар) гадәттә авыл мулласы тутырган һәм бу материаллар да, әйтелгәнчә, архивта саклана.

Архив материалларында авылларның нигезләү вакыты, халыкның кайсы яклардан күченеп килгәне, гаиләгә кайсы төбәкләрдән килен алганнары, кемнәр муллалык иткәне һәм башка тарихи яктан әһәмиятле мәгълүматны табарга була.

Мисал өчен Татарстан Республикасының Әлмәт районына кергән Кама-Исмәгыйл авылын карап китик.

Кама-Исмәгыйл авылы Зәй елгасы буендагы Кама (Камка) исемендәге кечкенә елга буенда нигезләнгән. Бу авылның исеме беренчеләрдән күченеп утырган Адыл (Гадел?) улы Исмәгыйл белән бәйләнгән. Авылның нигезләнгән вакыты – 1719 ел. Бу җирләр үз вакытында күренекле тарихи шәхес Нәдер Уразмәтовның борынгы бабаларына Казан ханнары тарафыннан бирелгән җирләргә керәләр. Авыл ике кисәктән торган – Югары һәм Түбән очлардан. Берееләрен урыс хәкимияте уйлап тапкан сословиялар исемлеге буенча »типтәр», икенчеләрен «ясаклы» татарлар дип язганнар. Өченче сословиедагы камалыларны «служилый» татарлар дигән яңа исем белән «бүләкләгәннәр».

Сакланган материаллардан күренгәнчә, авыл имамы Фәйзулла Йосыф улы, 1701 елда туган. Имамлыкта XVIII гасырда, «ясачный» татарлардан[ГАСО. Ф.150-1; ЦГИА РБ. Ф.И-295, оп.9].

Габдулла Габделҗәлил улы, 1743 елда туган. Мулла һәм мөдәррис булган, имамлык вакыты XVIII гасыр азагы. «Служилый» татарлардан.

Гыймадетдин Гайсабир улы имам булып 1825 елның 25 ноябреннән эшли башлаган.

Ногман Гаделшаһ улы – мәэзин, туган авылы Уразай (Азнакай волосте). Губерния идарәсенең карарлары 31 декабрь 1831 ел һәм 9 июль 1849 елда.

XVIII гасырның уртасында һәм икенче яртысында имамлыкта Гайса Габделмәҗид улы һәм Гайсаның улы Шәрәфетдин булганнар. Алар икесе дә Кама-Исмәгыйль авылында туып үскәннәр, «типтәр» сословисында булганнар.

Шәрәфетдин Гайса улы, 1-нче җәмиг мәчетенең имамы һәм мөдәррисе. Губерния идарәсенең карары 1852 елның 19 апреленнән.

Гайсаның һәм дә аның улы Шәрәфетдиннең ревизия материалларында һәм метрика кенәгәләрендә чагылыш тапкан нәсел шәҗәрәсенә күз салыйк.

2-нче ревизия язмаларында Гайсаның һәм аның улы Шәрәфетдиннең бабалары Яңа Нәдер авылында күрсәтеләләр: Әлмәк улы Уразай (т.1719) һәм аның «пасыныгы» (якын туганының улы) Уразгилде Рахманкол улы, туган елы 1735.

3-нче ревизия чорында (1762 ел) бу гаилә Кама-Исмәгыйль авылындалар. Ике ревизия арасында Кама-Исмәгыйль авылына күченеп киткәннәр.

Мөхтәрәм имам Шәрәфетдиннең шәҗәрәсе Рахманкол улы Уразгилдедән башлана.

1-нче буын Рахманкол.

2-нче буын Уразгилде (1735).

3-нче буын Габделмәҗид (1757–1830), Вәлид (1767), Ибраһим (1770–1828) һәм Кобис (1779).

3-нче буында Габделмәҗиднең балалары: Габделнасыйр (1784), Гайса (1793) һәм Гали (1797).

4-нче буында Габделнасыйрның балалары: Габделхалик (1804), Габделвәли (1806) һәм Гафия (?).

Гайсаның балалары: Шәрәфетдин (1820–1901, 27.04), Шафибетдин (1801), Шаһабетдин (1823) һәм Галәүтдин (1852).

Галинең балалары: Гыйлман (1820), Идрис (1828–1903, 05.03), Гыйлаҗетдин (1831–1897, 04.05), Мәсуфбану (1833, 28. 10), Файзә (1839, 12. 01).

Тагын да кызыксынып, кемнәр белән никахлашканнарын барлап китик. Габделмәҗиднең улы Гайса авылның «типтәрләр» командасының мулласы. Гайса имамның хатынының (остабикәнең) исеме Сәрвиҗамал була. Сәрвиҗамалның Бәдриҗамал исемле апасы Иштирәк авылының имамы Мөхәм-

мәдкәрим никахында булган. Бәдриҗамал һәм Сәрвиҗамалның Галибәк исемле аталары Кама-Исмәгыйль авылы кешесе була. Галибәкнең хатыны Хафиза Иштирәк авылында яшәгән Бакый исемле кешенең кызы булып чыга. Бакыйның атасы Гыйсматулла, бабасы Шәмсетдин, Шәмсетдиннең атасы Габдеррәшид исемле булган. Заманында бу токымнар Сембер якларыннан күченеп килгәннәр. Без китергән язма Ризаэтдин хәзрәтнең «Асар» дигән китабыннан алынды [Фәхретдин: 2006. Т.1. 565 б.]. Бу мисалда әйтелгән шәхесләрнең ата-бабалары Ризаэтдин хәзрәтнең бабалары белән бертуган булулары бик тә ихтимал. Шулай уйлар өчен нигез дә бар.

Ризаэтдин хәзрәтнең Иштирәк авылы белән бәйләнгән язмасында «... Янкилде абыз, аның улы Җанъегет абыз Сембер урынын шәһәр итү өчен биргән...», – дигән җөмлә бар.

Икенче мисал. 1889 елның 3-че мартында Галиның Идрис исемле улының Бибимәчтүрә исемле кызы һәм Бигәш авылының 40 яшьлек Мөхәммәди Мохит улы белән никахлашалар. Кыз ягыннан вәли вәкил атасы була. Никахны укучы имам Сөләйман Гайнан улы.

Мохит улы Мөхәммәди гаиләсендә Хәйрулла исемле бала туган. Хәйрулланың гаиләсендә Нәбиулла исемле бала, ә Нәбиулла гаиләсендә – Рөстәм туа.

Өченче мисал. 1879 елның 28 январендә Бөгелмә өязе Кама-Исмәгыйль авылының беренче мәчетенең имам-җәмигы һәм мөдәррисе Шәрәфетдин Гайса улы үзенең никахы белән 17 яшлек кызы (1862 елда туган) Шәмгыҗамалны шул ук өязнең Әлмәт авылында яшәүче 31 яшьлек (1848 елда туган) Җарулла Сабит улына хатынлыкка бирә. Кыз ягыннан вәли-вәкил мулла үзе, кияү ягыннан – кардәше Әхмәдзәки булалар. Ризалыкта Баһман улы Мөхәммәдшакир булган. Мәһәрнең күләме акчалата 150 сум бирелгән.

Җарулланың кардәше Әхмәдзәкинең кайсы якларда яшәгәнен ачыклый алмадык, Әлмәт авылында Әхмәдзәки исемле ир-атның исеме күренмәде.

Бу гаиләдә 1880 елның 7-нче мартында Мөхәммәдрәшид исемле малай туа. 1910 едның 14 ноябрендә Әлмәт авылында Мөхәммәдрәшиднең гаиләсендә Әхмәд исемле бала туа. Ә ул исә Әхмәд Тимер исеме астында бөтен дөнъяга танылачак татар галиме була.

Бу никах Җарулла хәзрәтнең тормышында икенче никахы булган. Беренче никахта аның хәләл-җефетенең исеме Миңлысылу, Бөгелмә сәүдәгәре Шәрәфетдиннең кызы. Яшь гаиләнең беренче баласы Бибифатыйма исемле кыз, 1878 елның 2-нче сентябрендә туа. Миңлесылу, 18 яшьлек хатын, баласын тудырган көнне үк вафат булган. Шул ук көнне кыз бала да вафат була.

Бу гаилә трагедиясеннән соң дүрт айдан артыгырак вакыт узгач Җарулла Кама-Исмәгыйль авылының имамы Шәрәфетдиннең кызы Шәмгыҗамал белән никахлашкан.

Түбәндә Җарулла хәзрәтнең тугыз баласының исемнәрен китерәбез.

1. Бибифатыйма, туган 1878, 02.09, анасы – Җарулланың 1-нче хатыны Миңлесылу. Бибифатыйманың вафат булуы метрикада теркәлмәгән.

Калган сигез баланың анасы Шәмгыҗамал булган.

2. Мөхәммәдрәшид (1880, 07.03–1938, 15.02), язылган 1-нче мәчеттә, атып үтерелә.

3. Әхмәдшаһид (1881, 28.11–1883, 09.01), вафат чәчәк чиреннән.

4. Фатыйма (1883, 28.11–1885, 19.12), 1-нче мәчеттә язылган.

5. Рокыя (1886, 19.05–1887, 10,11), вафат ютәлдән.

6. Зәйнәб (1888, 07.07–1889, 17.04), вафат «саргы берлә».

7. Әхмәдшаһид (1890, 09.02.–1890, 08.12), вафат «әфси» чиреннән.

8. Бибихәлимә (1891, 23.11.–1893, 08.04), вафат ютәл чиреннән.

9. Рәшидәнбәһия, туган 1894 елның 16 февраленда.

Әлмәт авылының метрикә кенәгәсендә никахлар теркәлгән язуларда Җарулла хәзрәтнең беренче имзалары 1877 елың 3, 20 март һәм 19 май айларында очрыйлар. 1878 елда 2-нче мәчеттә 03. 01; 17. 03; 01. 12 һәм10. 12. 1879 елда җиде никахның өчесендә.

1879 елдан соң Әлмәт авылы метрикаларында Җарулла хәзрәтнең имзалары очрамыйлар. Әммә аның гаиләсендә туган балаларның барысы да Әлмәт авылында теркәлгәннәр.

Әхмәд Тимернең бабасы Җарулла хәзрәт 1890-нчы елларның уртасында гаиләсе белән Төркиягә күчеп китә. 1891–1892 елларда ачлыктан җәдәгән һәм империяда халык санын алган чорларда үзләренең ризасызлыкларын белдергән татарлар туган авылларын ташлап Төркиягә («на туретчину») китәргә мәҗбүр булалар. Бу татар гаиләсе берникадәр вакыт Сүриядә һәм Гарәбстанда да яши. Шул заманда Мөхәммәдрәшид Җарулла улы 10 ел Мәдинә һәм Мәккә мәдрәсәләрендә укый [Тайсин: 1992. 109 б.]. Җарулла хәзрәт һәм остабикә шул сәфәрдә вафат булалар. Остабикә Сирияда, Халеп (Алеппо) шәһәрендә, хәзрәт Мәдинәдә җирләнәләр. Мөхәммәдрәшид Мәккә һәм Мәдинәдә белем туплап, туган якларына кайткач, Әлмәт авылына имам хатип һәм мөдәррис дәрәҗәсенә билгеләнә.

Мөхәммәдрәшид хәзрәтнең имзалары никахлар укыган язмаларында 2-нче мәчетнең метрика китапларының 1907, 1909–1915 елларында күрсәтеләләр.

Мөхәммәдрәшиднең һәм аның хатыны Зәйнәбнең (Түбән Шәлчеле авылы Габделфаттах кызы, туган 1888 елда, вафат 1978 елның 12 апре-

ләндә) гаиләсендә барлыгы җиде бала туа. Аларның 1-че баласы 1-нче мәчеттә, 2-нче, 3-нче һәм 4-нче балалары – 2-нче мәчеттә теркәлгәннәр. 5-нче, 6-нчы һәм 7-нче балаларының исемнәре Әхмәт Тимернең автобиографиясыннан китереләләр.

1. Мөхәммәд (1908. 22.02–*1993. 13.08), һәлак сугышта*. 2. Әхмәд – Әхмәд Тимер (1910. 14.11 – 2003. 19.04). 3. Мәхмүд т.1913, 01.01. 4. Бәкер – *Башир* (1915. 13.03 – *1955. 02.05*). 5. *Һауа, туган 1919. 03.08*. 6. *Сәгыйд, туган 1923*. 7. *Гамир, туган 1926*.

Метрика кенәгәсендә Җарулла хәзрәтнең әтисе Сабит Мансуров дип языла. Автобиографиядә нәсел агачының нигезендә Мәүлед күрсәтелә, аның улы Габделнасыйр. Габделнасыйрның улы Менди, Мендинең улы Сабит. Мансурны Менди дип атау аның исемен кыскарту белән бәйләнгән булуы бар. Татар авылларында кеше исемнәрен кыскартып әйтү гадәти хәл, бигрәк тә гарәптән килгән исемнәрне. Бу хәлне болай аңлатып буладыр дип уйлыйбыз: борынгы татар исемнәре, тәңречелек чорындагылары, бик кыска булганнар, күбрәкләре тормыш-табигать белән бәйләнгәннәр һәм халык кыска исемнәрне яраткан.

Менә шундый кызыклы да, уйландырырлык та ул ата-баба эзләре буенча үткәнгә кайту.

Әдәбият

1. ГАСО. Ф. 150-1.

2. Тайсин Ә. Әхмәт Тимер // Йөртә безне язмышлар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992.

3. Фәхретдин Ризаэддин. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – 360 б.

4.ЦГИА РБ. Ф. И-295, оп. 9.

ДИНАСТИЯ БУРНАШЕВЫХ

У.Х. Бурнашев

Не одно столетие стоит на ермишинской земле с. Азеево, где с давних времен живут в мире и согласии «дети разных народов» – славяне, татары, мордва. Это село и теперь еще довольно большое, со старинными традициями, продиктованными числом живущих здесь татар со времен весьма далеких. Даже по названию видно, что его основали выходцы со Среднего Поволжья.

Начало села – XVI в. Известно, что оно по тем временам было самым большим в округе и по численности населения постоянно увеличивалось. И если в XVIII в. было чуть больше 1000 жителей и в основном татары, то в следующем столетии село насчитывало почти три тысячи человек.

В прошлом Азеево было зажиточным торговым селением. Организация жизни была продуманной: взрослые работали на канатных заводах, их было целых три, работали в кузницах, которых имелось две, действовали четыре ветряные мельницы. До революции в селе было семь мечетей. Дети учились в двух магометанских школах. Грамотного населения было все же мало.

Крестьяне работали на земле, а в зимние месяцы, видимо, более удачливые, либо более активные – на канатных фабриках. Канаты продавали за приличные деньги. Везли свой товар в Москву, Новгород, Рыбинск.

Вообще-то, азеевцы слыли предприимчивыми людьми. Многие уезжали на заработки далеко отсюда и расходились по всей России. Бывало, пропадали лет на пять-шесть. Но возвращались. С деньгами. Строили здесь просторные каменные дома. Некоторые сохранились до нынешних дней. Азеево старинное и самобытное село. Здесь испокон веков жили предки рода Бурнашевых.

Кучер Его величества

Отсюда родом Сайфулла Хабибуллович Бурнашев. Родился он в 1856 г. в бедной крестьянской семье. Подростком его отдали в услужение богатым людям. Затем он служил у губернатора Польши, которая, как известно, тогда входила в состав России. Во время службы в армии крепкого голубоглазого молодца приметил и взял к себе кучером не кто-нибудь, а сам Великий князь Алексей Александрович – родной брат императора Александра III, приходившийся Николаю II дядей. Жил он в роскошном дворце, имел чин адмирала флота и слыл богатейшим человеком Российской империи.

Кучера Сайфуллу Великий князь называл Степаном Николаевичем. И ценил его не только за исполнительность, но и за надежную богатырскую силу и преданность. Однажды, например, Алексей Александрович поспорил со своим другом о том, что кучер сможет на себе затащить лошадь на второй этаж своего дворца. К великому удивлению гостя, он выиграл этот спор.

Сайфулла был выше среднего роста, плечистый, представительный, крупный. Носил вьющуюся черную бороду, ходил в белом кителе с золотой цепочкой на груди – именными часами с гербом Российской империи, подаренными ему Романовыми. Его голову покрывала красная турецкая феска с кисточкой. В таком наряде он любил прогуливаться по Невскому проспекту, привлекая внимание барышень…

У Сайфуллы Хабибулловича было восемь сыновей. Всякий раз с рождением очередного ребенка великий князь посылал в дар семье по 50 рублей. Тогда это были немалые деньги. Квартира в Петрограде, где проживала вся его большая семья, была куплена им у какого-то генерала, выезжавшего за границу. Пять просторных залов этой квартиры занимали целый этаж дома. Своим сыновьям Сайфулла дал приличное образование. Их воспитанием, обучением хорошим манерам занималась специально нанятая для этого бонна, татарка по национальности.

Перед смертью Алексей Александрович завещал своему племяннику, «чтобы хоронил меня мой кучер Степан», и просил Николая II взять его к себе на службу. Царь выполнил эту просьбу. Великий князь был похоронен в Александро-Невской лавре, рядом с могилой генералиссимуса А. В. Суворова.

В последний путь его провожали все представители царствующей династии. Гроб с телом покойного был установлен на пушечном лафете, а кучер Степан, как и завещал его господин, сидел на своем облучке, с головы до ног покрытый траурным тюлем. Во время движения похоронного кортежа непременно молился, прося Аллаха о том, чтобы какой-нибудь террорист не бросил бомбу, и его дети не остались сиротами.

После смерти великого князя Сайфулла Хабибуллович был определен на службу кучером к императору Николаю II. Кучер Сайфулла ловко управлял цугом чистокровных рысаков английской породы, а в роскошной царской карете гордо восседали император Николай II с императрицей Александрой Федеровной. Любопытны такие детали: коляска царской кареты были инкрустированы драгоценными камнями, а само «рабочее место» кучера находилось на высоте около двух метров. И подняться наверх кучер мог только с помощью четырех камердинеров

После Февральской и Октябрьской революций 2017 г. он не оставил свою редкую профессию. Правда, членов советского правительства он возил уже не в царской карете, а в обычной «гражданской» пролежке. Если вождь мирового пролетариата был «прост, как правда», то Троцкий, по его воспоминаниям, имел важный, господский вид и всегда расплачивался с извозчиком, несмотря даже на то, что тот состоял на службе у Совнаркома.

За границу Сайфулла Бурнашев не уехал, как это делали многие, кто служил при дворе Его величества. На предложение эмигрировать, он отвечал: «Я у Романовых богатства не нажил. Заработал лишь два отмороженных пальца в сорокоградусный мороз. У меня восемь сыновей и никуда отсюда не поеду».

Тем самым Сайфулла Хабибуллович нажил врагов в своем бывшем окружении и обрел друзей в новом.

В.И. Ленин и М.И. Калинин предлагали ему, чтобы он стал гидом Каретного двора в Екатерининском дворце в Петрограде, но он вежливо отказался, сославшись на старость. Отказался он и от пожизненной пенсии, которую ему предлагала советское правительство, хотя потом об этом жалел. Умер Сайфулла Хабибуллович Бурнашев в 1933 г. в возрасте 77 лет и похоронен на мусульманском кладбище родного с. Азеево.

От кареты к автомобилю

Интересно то, что профессию Сайфуллы унаследовали пятеро из восьми сыновей. Разумеется, восседали они уже не на кучерских козлах, а за рулем автомобиля – чуда XX в. В его двигатель можно было «загнать» целый табун лошадей, какими правил кучер Степан. И профессия шофера была такой же необычной, престижной, как и профессия космонавта лет 30–40 назад.

Параллель с именитым Сайфуллой Хабибулловичем, который возил государя-императора – его второй сын Вали возил первого руководителя советского государства. В семейном архиве сохранилась не только редкая фотография, но и копия удостоверения № 459 от 29 июня 1918 г., свидетельствующего о том, что В.С. Бурнашев состоит на службе в гараже № 2 ВЦИК Советов рабочих и солдатских депутатов.

Вали Сафиуллович неизменно отмечал простоту и душевность вождя. Известно и то, что в двадцатые годы по поручению Ленина он доставил в Татарию 20 грузовиков. Этот факт подтверждают и документы, хранящиеся в Набережночелнинском городском музее.

Вали Сафиуллович прожил долгую, интересную жизнь. Он умер в возрасте 97 лет и с почестями был похоронен в г. Ташкенте, где он жил, находясь на пенсии.

Шоферской профессией связаны между собой и четверо других братьев Вали Бурнашева – Халиль, Инаят, Ахмеджан и Ариф. Причем Халиль Сайфуллович, третий сын царского кучера, так же, как и его отец, некоторое время служил при дворе Николае II. Он возил на «Мерседесе» дочерей царя – Ольгу, Анастасию, Марию. По рассказам известно, что все царевны, несмотря на сословное положение, были отнюдь не избалованы, милы, просты в общении и очень любили покататься на машинах.

После Октябрьской революции Халиль некоторое время жил в Азии, работал мельником. Потом женился, переехал с женой и тремя детьми в Казань. Как автомеханику и водителю высокого класса, ему доверили возглавить автохозяйство Казанского Кремля.

Дочь Равиля Халилевна Бурнашева – известный в Татарстане врач, профессор, доктор медицинских наук, даже после замужества в память о деде оставила его фамилию. Она живет в Казани и несмотря на преклонный возраст, продолжает работать в Казанской многопрофильной больнице №7. Обе ее дочери тоже избрали профессию врача и так же, как мать, имеют ученые степени в области медицины, продолжают трудиться в области здравоохранения.

Инаята Бурнашева, пятого сына Сайфуллы, судьба забросила в Белоруссию. Он тоже возил членов правительства, а затем вместе с семьей был командирован в Монголию. Там он попал в аварию и после лечения вернулся на постоянное жительство в Москву. Его сын Джавдат тоже пошел по стопам отца своего дяди Вали и деда Сайфуллы. Правда, со скидкой на время в его руках уже были не вожжи и не «баранка» автомобиля, а штурвал литерного лайнера правительства ИЛ-62. Его так и звали – «кремлевский летчик». На своем борту он возил членов правительства, Политбюро, его пассажирами были сначала Н.С. Хрущев, затем Л.И. Брежнев. Сейчас заслуженный летчик СССР Джавдат Инаятуллович Бурнашев находится на пенсии и проживает в Москве.

Трагически сложилась судьба шестого и седьмого сыновей Сайфуллы – Арифа и Ахмеджана. Первый сгорел в машине в результате несчастного случая, второй погиб от осколка снаряда за рулем своей машины, на которой возил генерала по фронтовым дорогам Великой Отечественной войны. Случилось это под Москвой.

Не вернулся с войны и сын Вали Сайфулловича Талгат. Он был военным летчиком-истребителем. Его двоюродному брату Джафару, сыну Халиля Сайфулловича, который тоже воевал в небе, повезло больше. Будучи тяжело раненным в одном из воздушных боев, он, лишившись глаза, чудом дотянул до земли.

Трое других сыновей Сайфуллы, старший Мухамед-Али, четвертый Камал и Мухаметжан – восьмой сын, выбрали профессии, не связанные ни с техникой, не с извозом высокопоставленных особ. Камал Сайфуллович в советские годы работал комендантом Казанского Кремля. Мухаметжан Сайфуллович после окончания Ленинградского института стал известным ученым-геодезистом. В годы войны он преподавал в трех академиях (имени Сталина, Фрунзе и Жуковского), участвовал в строительстве Турксиба, обследовал оз. Балхаш. Написал книгу «Судоходство каналов Средней Азии». Старший из братьев – Мухамед-Али Сайфуллович, родился в 1888 г. В семнадцатилетнем возрасте ему довелось быть очевидцем «кровавого воскресенья». Затем он служил унтер-офицером Новочеркасского полка. После революции занялся журналистикой, публиковал очерки и статьи в казанских журналах. В голодные двадцатые годы XX в. семья Мухамед-Али переехала в Среднюю Азию. В семье было шестеро детей. Трудно жилось многодетной семье на чужбине и через некоторое время они вынуждены были вернуться на свою родину – село Азеево.

Старшая дочь Адиля связала свою трудовую деятельность с искусством – музыкой. В Москве обучалась в Гнесинке, затем перевелась в Ташкентскую консерваторию. Училась старательно, получала повышенную стипендию. Работала концертмейстером в Государственном ордена Ленина академическом театре имени Хамзы г. Ташкента. Четверть века ее жизни связана с г. Хабаровском, куда она поехала на заработки, чтобы помогать маме и младшим сестрам. Сам Мухамед-Али был хорошим скрипачем, красноречивым и в меру своих сил работал в колхозе. Его жена Азиза работала воспитательницей в колхозном детском саду, была миловидной и скромной женщиной. Дочь Рабига стала женой моряка-офицера Тихоокеанского флота – нашего земляка Урманова Хусаина Садековича. Зять Бурнашевых – Хусаин Садекович, дослужился до капитана II ранга, в годы Великой Отечественной войны храбро сражался, был тяжело ранен, контужен, лишился одного глаза. После демобилизации по состоянию здоровья переехал на постоянное местожительство в г. Москву, где и скончался, так как здоровье было сильно подорвано.

Вместе с женой Рабигой воспитали трех дочерей, которые связали свою судьбу с музыкой. Получили высшее музыкальное образование в г. Москве. Старшая дочь Лайла играет на арфе, часто выступает с концертами в Москве, городах России, совершает с музыкальной труппой поездки за границу. Дослужилась до профессора. Дочь Наиля – скрипачка, вместе с сестрой Дилей выступала на концертных сценах столицы. С младшей дочерью Бурнашевых я посещал детский сад. С Джавидой мы

учились в одном классе с 1941 по 1951 гг. в Азеевской средней школе. После окончания школы наши пути с Джавидой разошлись. Она поехала на учебу в г. Москву, где жили ее родственники. Окончив учебу, она всю жизнь работала в Москве в Белорусском посольстве.

Я же, в свою очередь, являюсь дальним родственником рода Бурнашевых, имею ту же фамилию. Вся моя трудовая деятельность связана с воспитанием молодого поколения. После окончания педагогического института я 45 лет отдал любимой работе с детьми. В родном селе был директором Азеевского детского дома, затем директором местной средней школы.

В Азееве до сих пор сохранился небольшой дачный домик Мухамеда-Али. По деревенским обычаям эту семью прозвали «Питерские». Ежегодно дочь Рабига с дочерьми Лайлой и Наилей приезжают летом в родное село, останавливаются в доме отца и деда. Во время их приезда в Азеево часто вспоминаем былые времена, гордимся своим прошлым – династией Бурнашевых.

Род Бурнашевых начиная от Сайфуллы Хабибулловича, оставил заметный след в истории нашего Отечества.

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫҢ ТАТАР ТАМЫРЛАРЫ

Ф. Ә. Бәйрәмова

Аннотация: *В статье раскрывается история происождения и поселения на берегах оз. Ыссык-Куль древнего татарского рода Абдулвалиевых. Анализируются последствия политики раскулачивания и репрессий отдельных представителей этого рода и влияние этих явлений на творческое становение Чингиза Айтматова, принадлежавшего по материнской линии к роду Абдулвалиевых.*

Ключевые слова: *Кукморы, Мачкара, Абдулвалиевы, политические репрессии, Айтматов.*

Билгеле булганча, Чыңгыз Айтматовның әнисе – Нәгыймә Габделвәлиева татар булган. Нәгыймә апаның әтисе Хәмзә 1860 елларда Вятка губерниясының Малмыж өязе, Мәчкәрә авылында туган, ул хәзерге Татарстан Республикасының Кукмара районына керә. Нәгыймә апаның әнисе Газизәбану Шаһиева да татар милләтеннән булган, ул хәзерге Казахстанның Җидепулат-Семипалатински шәһәрендә туган. Шулай итеп, дөньякүләм танылган язучы Чыңгыз Айтматов әнисе ягыннан тулысынча татар милләтеннән, затлы морзалар нәселеннән. Ул моны үзе дә белгән һәм гомеренең ахырында булса да татар тамырларын танып, 2006 елның 15 сентябрендә Кукмара музеена түбәндәге сүзләрне язып җибәргән:

«Дорогие учредители музея Кукмора! Выражаю Вам искреннюю благодарность за информацию о создании родославной Абдулвалиевых, моих предков по материнской линии. Для меня такая чудесная весть была неожиданной и исторически великой для всего нашего семейства Айтматовых, для моего рода. Вы установили нашу родославную на Кукморской земле. Теперь это место, это деревня будет для нас святым местом...» «Кадерле Кукмара музеен оештыручылар! Сезгә әни ягыннан әби-бабаларым булган Габделвәлиевләр шәҗәрәсен төзү барышында тапкан мәгълүматларыгыз өчен ихлас рәхмәтләремне белдерәм. Могҗизага тиң бу хәбәр минем өчен көтелмәгән булды, ә Айтматовларның барлык гаиләсе, нәселе, әби-бабаларым өчен бу тарихи бөек хәбәр. Сез Кукмара җирендә безнең нәселнең шәҗәрәсен торгыздыгыз. Хәзер бу урын, бу авыл безнең өчен изге урын булачак...» [Байрамова: 2015. С. 5].

Чыңгыз Айтматов кебек даһиның әнисе ягыннан бабаларының нәкъ менә Кукмара төбәгеннән, Мәчкәрә авылыннан, Ишмән нәселеннән булуы бер дә гаҗәп түгел. 1552 елдан соң бирегә Казан ягыннан качкан

татарлар күпләп килә, шулай итеп, Кукмара төбәгендә шәһәр мәдәнияте һәм мәгърифәтен үзләштергән, һөнәрчелеккә оста каладан чыккан катлам барлыкка килә һәм ул бүген дә дәвам итә. Инде Мәчкәрә авылының Чыңгыз Айтматов бабалары яшәгән чорларына – XVIII–XIX гасырларга кайтыйк. Шунысын да әйтергә кирәк, бу авыл ул вакытта ук гөрләп торган, саладан бигрәк, каланы хәтерләткән, мәгърифәт-мәдәнияте белән нык аерылган, сәнәгать-промышленность ягыннан да үзәк ролен башкарган. XVIII гасыр ахырында инде монда таш мәчетләр һәм данлыклы мәдрәсәләр булган, XIX гасырда исә Мәчкәрәдә киҗе-мамык, бәс-тукыма фабрикалары, чуен кою заводлары гөрләп эшләп торган, аның сәүдәгәрләре дөнья белән эш йөрткән. Моңа төбәк тарихын өйрәнүче галимнәр дә игътибар иткән:

«*До советского периода село входило в состав Малмыжского уезда Вятской губернии,* – дип яза алар. – *Населенный пункт резко отличался от многих татарских селений тем, что уже в конце XVIII в. являлся торгово-промышленным центром. С 1778 г. здесь свою продукцию производили кумачная и кожевенная мануфактуры, принадлежавшие братьям Абдулле, Мухаметрахиму и Ярулле Утямышевым. В XIX в. их потомки владели медеплавильным, мыловаренным, суконным, ваточным предприятиями в Казанской и Вятской губерниях*» [Кукморский край: 2008. С. 161].

Бу хезмәттән күренгәнчә, «беренче гильдияле Малмыж купецлары» Үтәмешев – Габделвәлиевләр хәйриячелек белән дә нык шөгыльләнгәннәр – алар Малмыждан Казангача арада йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр салдырганнар һәм тотканнар. «*1802 елда Казанда алар акчасына «Иске таш» мәчете һәм 1882 елда «Мөхәммәдия»* мәдрәсәсе төзелә», – дип язалар алар турында. Моның өстенә Үтәмешевләр төрле дәрәҗәдәге депутатлар, гласныйлар, җәмәгать эшлеклеләре дә булып торалар. Бу зур һәм затлы, бай нәсел турында мәгълүмат, Кукмара төбәге музеенда сакланган Ишмән шәҗәрәсеннән тыш, Киров өлкәсе дәүләт архивының Мәчкәрә авылы буенча ревизия материалларында да бар.

Инде Габделвәлиевләрнең ничек итеп Кыргызстан җирләренә килеп урнашулары турында сорасак, моңа җавапны Исхак Габделвәлиев шәхсиятен һәм биографиясен өйрәнеп белә алабыз. Ул яшьтән үк Казанда, Оренбургта, Троицкида, Эрбеттә сәүдә тирәсендә эшләп байый, аннан Семипалатинскида һәм Петропавлда үзенең сәүдә үзәкләрен ача, соңыннан Верный (хәзерге Алма-Ата) шәһәренә килеп урнаша. Ул бөтен Җидесу төбәгенең иң зур бае булып таныла, Россия һәм Кытай белән сәүдә итә. Менә шушы Исхак хаҗи 1880 елларда Мәчкәрәгә кайтып, абыйсы Хәсәннең балалары Хәмзә, Әхмәтгали һәм Галияне Урта Азиягә алып

китә, шулай итеп, Габделвәлиевләр хәзерге Караколга килеп җитәләр һәм шунда төпләнеп калалар.



Әлбәттә, Габделвәлиевләр килгәнче дә Караколда татарлар яшәгән, алар инде XVIII гасыр башында ук бу тирәләрдә сәүдә белән шөгыльләнгәннәр һәм шәһәр төзелә башлагач, шунда күчкәннәр. Истәлекләрдән күренгәнчә, Хәмзә Габделвәлиев башта Караколда башка сәүдәгәрләргә хезмәт күрсәтә, аннан үз эшен ача. Безгә калса, ул үз эшен ачуны алай сузмагандыр, чөнки Хәмзә үзе дә, башка туганнары да тирә-якның данлыклы бае Исхак хаҗи ярдәмендә, аның «канаты астында» булалар бит. Исхак хаҗи Габделвәлиев абыйсының улы Хәмзәне балдызы Газизәбануга өйләндерә, мөгаен, тормыш башлап җибәрү өчен шактый гына капитал-мал да бирелгәндер. Яшь гаилә 1886 елда корылган булырга тиеш, чөнки аларның беренче балалары Мөхәммәтҗан 1887 елда туа. Газизәбану – Семипалатински шәһәренең данлыклы Шаһиевлар кызы була, ул үзенең тыйнаклыгы, матурлыгы, яшьлеге һәм сафлыгы белән аерылып тора. Яшькелт күзле, ак йөзле Нәгыймә әнисенең тышкы кыяфәтен дә, холык-фигылен дә үзенә ала.

Хәмзәнең башка туганнары да яңа җирдә бик тиз үз тиңнәрен табалар – Галия Караколның иң зур баена – Гали хаҗи Рафиковка кияүгә чыга, Әхмәтгали дә татар баеның кызына өйләнә. Хәер, ул вакытта димләп-яучылап та өйләнешкәннәр, байлар байлар белән туганнашырга

тырышкан, диниләр укымышлыраклар белән гаилә корганнар. Бертуган Габделвәлиевләр исә Ыссык-Күл буйларында ныклы тормыш башлап җибәргәннәр, алар мануфактура, галантерия, тире-яры белән сәүдә иткәннәр, Караколда зур-зур кибетләр ачканнар, заводлар салганнар, диңгездәй күлдә пароходлар тотканнар.

Габделвәлиевләргә Казанда калган сәүдә элемтәләре, таныш-белешләре дә нык ярдәм итә, Исхак хаҗи белән берлектә, алар Җидесу төбәгендә эшмәкәрлекне гөрләтеп җибәрәләр, Кытай белән Мәскәү арасында сәүдә арадашчылары ролен үтиләр. Үзенең матурлыгы, төзеклеге, яшеллеге, байлыгы белән Каракол тирә-яктагы башка калалардан аерылып торган, монда татарларның да өлеше зур булган. Ике катлы өйләрдә дә беренчеләрдән булып татарлар яши башлый, ул заманда Караколда 12 шундый йорт барлыгы билгеле, 1909 елда Хәмзә Габделвәлиевнең ишле гаиләсе дә ике катлы агач йортка күчә. Шулай ук аларның Караколда зур алма бакчалары да булган, бу як халкын алма үстерергә Хәмзә Габделвәлиев өйрәтеп калдырган, дип сөйлиләр. Бәлки Чыңгыз Айтматов та үзенең «Ыссык-Күлнең кызыл алмалары» дигән әсәрен татар бабасын истә тотып язгандыр. Моңа Караколдагы Ыссык-Күл өлкәсе дәүләт архивы директоры Чынар Сейдиматова да игътибар иткән, югарыда телгә алган фәнни-гамәли конференциядә ул болай дип чыгыш ясаган:

«Я всегда с волнением перелистываю повести нашего знаменитого земляка – Чингиза Айтматова. Даже их названия звучат как образные предельно сжатые исторические тезисы: «Ранние журавли», «Первый учитель», «Красные яблоки Иссык-Куля», «И дольше века длится день»... Кстати, о яблоках. Видимо, писатель знал, что сортовые яблоки в Прииссыккулье развели татары – его родственники по матери. На окраине Каракола его дед Хамза Абдулвалиев впервые разбил прекрасный плодовый сад, о котором с трепетом пишут в своих воспоминаниях Р.Т. Айтматова и другие члены их семьи и родственники» [Эстафета памяти: 2012. С.7].

Чыңгыз Айтматов үзе дә Караколдагы татар бабасы турында бик җылы итеп искә ала:

«Мама родилась и воспитывапась в богатой купеческой, образованной семье Хамзы Хасановича. Она очень часто нам, детям, рассказывала о своих родителях, о братьях и сестрах, о прекрасном доме, яблоневом саде, о красоте Тянь-Шанских гор, о лучезарном озере Иссык-Куле. И сейчас, будучи взрослым, я думаю, что и я был в детстве рядом со своей мамой»[Ч.Айтматов, х/ф «Белые сны, по дороге домой»].

Егерменче гасыр башында Каракол-Пржевальскида инде ун меңнән артык кеше яшәгән, анда алтмыштан артык промышленность предприятиесе эшләп торган, аларның абсолют күпчелеге татарлар кулында

булган. Бу хакта югарыда телгә алган фәнни-гамәли конференциядә Ыссык-Күл өлкәсе хөкүмәтенең бүлек мөдире Нарметжан Ташбаев менә нәрсәләр сөйләгән:

«Деловыми людьми из татарского сообщества были основаны многочисленные мельницы, маслобойки, зернодробилки, обувные цеха и мастерские, многочисленные торговые лавки. Дед нашего великого писателя Чингиза Айтматова Хамза Абдулвалиев владел сетью магазинов, а также организовал производство мыла, выделку шкур. Усилиями купцов-татар в селе Джаргылчак был построен лесопильный завод и создан малый флот из барж и баркасов, который на протяжении многих лет перевозил грузы по озеру Иссык-Куль. Караваны татарских купцов привозили товары со всего света, закладывая основы будущих культурных, межэтнических и межгосударственных связей» [Эстафета памяти: 2012. С. 31].

1883 елда Караколда Җәмигъ мәчет төзелә, аны төзүдә Хәмзә Габделвәлиев тә беренчеләрдән булып катнаша. Ул гына да түгел, аның барлык балалары да диярлек, шул исәптән Нәгыймә дә шушы мәчет каршындагы мәдрәсә-мәктәптә башлангыч белемне алалар. Караколда Хәмзә белән Газизәнең 8 баласы туа, Нәгыймә шуларның бишенчесе.

«Мама часто вспоминала свое счастливое детство в отчем доме, – дип искә ала Роза ханым Айтматова. – Жили они в двухэтажном доме, с прекрасным садом и цветниками. По праздникам, она вспоминала, как отмечались в их семье «Ураза гайт» (Орозо айт), «Курбан гайт» (Курман-айт), «Навруз», когда к ним приходило много гостей, причем обильные угощения готовились и для богатых, и для бедных. Был обычай на праздники детям обязательно надевать новые наряды. Газиза заранее раздавала ткани бедным семьям, чтобы они сшили новые наряды своим девочкам» [Айтматова: 2013. С. 130].

Хәмзә Габделвәлиевнең Караколда өч шәхси йорты, биш кибете, сәүдә рәтләре, зур алма бакчасы, завод-фабрикалары, пароход-баржалары була. Аның данлыклы алма бакчасы турында әйттек инде, Ринат абый Габделвәлиевнең хәтирәләреннән күренгәнчә, ул бакча 8 гектар җирне алып торган һәм Каракол елгасы буена кадәр сузылган була. Ул тирәдәге автобус тукталышы әле хәзер дә «Абдулвалиевский сад» дип атала икән. Әмма революциядән соң, 1919 һәм 1929 еллар арасында совет хөкүмәте Хәмзә байның бар йортларын, байлыгын берәм-берәм тартып ала, Каракoлдагы соңгы көннәрендә ул гаиләсе белән җәйге бакча йортында яшәргә мәҗбүр була, 1930 елда исә уллары Сабир аларны Үзбәкстанга алып китә. Караколда Хәмзә бабасының барлык мал-мөлкәте турында документларны архивларга кереп өйрәнгән оныгы Ринат Габделвәлиев бу турыда менә нәрсә яза:

«В начале XX в. наш бабай, каракольский купец II гильдии Хамза Хасанович Габдулвалиев, благодаря усердию и смекалистости открывает пять магазинов разного профиля, организует кожевенный завод в городе Каракол, строит в 1905 г. жилой дом с магазином. Приобретает в 1909 г. 2-х этажный деревянный дом стоимостью 3800 рублей (золотом). Организует в своем дворе начальную школу для киргизских детей. Вся недвижимость Хамзы-бабая к 1910 г. стоила более 5000 рублей (золотом). Возрастив восьмерых детей, в 1925 г. он лишается домовладения под номером 79/33 по ул. Базарной в Караколе. 23.06.1928 г. проводится муниципализация домовладения по ул. Октябрьская-Крупская-Парковая (по воле судьбы теперь эта улица носит имя Нагимы Айтматовой)» [Абдулвалиев: 2013. С. 16].

Бүген Караколда Хәмзә бай йортларыннан берни дә калмаган, ә совет заманында алар мәктәп булып та, китапханә булып та, клуб, аптека, таможня, йортлар идарәсе, кибетләр булып та хезмәт иткәннәр. Шул елларның хәтирәсе булып, Караколда Нәгыймә Айтматова исемендәге урам барлыкка килгән, аны Нәгыймә апаның 100 еллыгына, шәһәр хакмияте карары белән биргәннәр. Ә шәһәр музеенда Нәгыймә апаның үзе турында да, Габделвәлиевләр турында да, шушы шәһәрне тоткан һәм үстергән татар байлары турында да бер хәбәр, бер сүз дә юк.

Инде Хәмзә белән Газизәбанунының сигез баласы турында сөйләүгә күчик. Алар 1886 еллар тирәсендә өйләнешкәннәр, дидек, чөнки беренче балалары Мөхәммәтҗан 1887 елда туа, Сабирҗан – 1890да, Шәрифҗан – 1899да туа, Гөлша(т)ның туу елы – 1901, Нәгыймә – 1904 елда, Абдулла 1909 да дөньяга килә, Зәйнәп белән Әсмәбикәнең туу еллары да, үлү еллары да билгесез. Чыңгыз Айтматовның булачак татар анасы Нәгыймә, әйткәнебезчә, 1904 елның 7 декабрендә Караколда туа, 1971 елның 10 августында Фрунзе (Бишкәк) шәһәрендә үлә. Нәгыймә башта Караколда мәчет каршындагы мәктәп-мәдрәсәдә белем ала, аннан соң шәһәрнең рус телендәге кыз балалар гимназиясен тәмамлый.

Яшьлеге революция чорларына һәм большевиклар хакимияте заманына туры килгәнлектән һәм бай баласы булганлыктан, үзе теләгән медицина техникумына керә алмый, Пишпәктә стенографистлар курсларын тәмамлый. Аннан, 1925 елда – Кыргызстанның партия һәм совет җитәкчесе Түрәкол Айтматов белән очрашу, аның белән гаилә кору, балалар табу, ире белән бергә, Каракол, Ош, Җәләләбад, Пишпәк-Фрунзе шәһәрләрендә партия эшләрендә эшләү. Бер-бер артлы балалары туу, беренче уллары Ризаның үлеме, 1928 елның 12 декабрендә дөньяга Чыңгызның аваз салуы, аннан – Илгиз, игезәкләр Рево һәм Люция, Ревоның сабый чакта ук үлеме, аннан төпчек бала Розаның тууы. 1931елда Нәгыймәнең

әнисе Газизәбану Нәмәнганда, Хәмзә 1932 елда Ташкентта берсе артыннан берсе үлеп китәләр. 1934 елда абыйсы Сабирны, халык дошманы, дип атып үтерәләр. Айтматовлар баш очында да кара болытлар куера башлый, ире Түрәколны, Кыргызстанда иң зур партия-совет җитәкчесе булуы да, ул вакытта Мәскәүдә укып йөрүе дә коткара алмый.

Түрәкол Айтматов Мәскәүгә Кызыл Профессура Институтына укырга җибәрелгәч, 1935 елда Нәгыймә дә балалары белән анда бара һәм 1937 елда, иренең баш очында шомлы болытлар куера башлагач, балаларын алып, яңадан Кыргызстанга – иренең туган якларына кайта. Менә шуннан соң инде Нәгыймә Айтматованың чын мәгънәсендә яшәү өчен авыр көрәше башлана, үзе өчен генә түгел, берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласы өчен, аларны саклап калу, юкка чыккан ире, аның һәм балаларының намусы өчен дә ул тиңсез көрәшкә күтәрелә. Үзе каты авыру хәлдә булса да, ул балаларын ач далаларда, карлы-бозлы тауларда яралы болан кебек саклый, халык дошманы хатыны һәм балалары, дигән кара тамга белән, авызы тулы кан булса да, аны ил алдында түкермичә, гаять тырышлыгы һәм күркәм холкы белән, ил алдында тирән хөрмәт казана. Ул дүрт баласына да югары белем бирә, аларны дала-тау араларыннан киң тормышка алып чыга, балаларының зур галимнәр, яхшы кешеләр икәнлеген, Чыңгызының дөньякүләм танылган язучы булуын күреп кала. Ире Түрәколның 1938 елда ук атып үтерелүен ул егерме елдан соң гына белә. Гомер буе ирен көтеп яши, аның олы мәхәббәтенә тугры булып кала, иренең авыр вакытларда үзенә сыендырган туганнарына, милләтенә дә тугры була – нәселен аларга тапшырып китә.

Чыңгыз Айтматов боларның барысын да белгән, ишеткән, үз күзләре белән күргән, ул татар Анасы Нәгыймә апа янында олы шәхес, талантлы язучы булып тәрбияләнгән. Ул барлык әсәрләрен дә беренче булып әнисенә укыта торган булган, аларда аның да язмышын чагылдырган. Чыңгыз Айтматовның «Йөзгә – йөз», «Анам кыры», «Язгы кәрваннар», соңрак язылган «Гасырларга тиң көн», «Ахырзаман» («Плаха») һәм башка әсәрләрендә ачы язмышына каршы берьялгызы көрәшергә мәҗбүр булган хатын-кыз образы, Ана образы – ул Нәгыймәападан алып язылган...

Әсәрләре 176 телгә тәрҗемә ителгән, 80 миллион тираж белән басылып чыккан дөньякүләм танылган язучы, дипломат, Дәүләт бүләкләре лауреаты Чыңгыз Айтматов әнисе турында болай дип әйтеп калдырган:

«Поклон Матери нашей! Каким мужеством, мудростью и преданностью своему родительскому долгу обладала она! Все лучшее в нашей жизни и судьбах наших, включая наше образование, было достигнуто благодаря ее труду и мужеству. Мать – это начало Родины, Мать – это

родной язык, Мать – это совесть, вкушенная вместе с материнским молоком».

Әдәбият

Абдулвалиев Р.Ш. Хамза из Мачкары, дед Чингиза. – Бишкек, 2013.

Айтматова Р.Т. Белые страницы истории. Мои воспоминания. – Бишкек, 2013.

Байрамова Ф.А. Татарская мать Чингиза Айтматова. – Казань, 2018.

Бәйрәмова Ф.Ә. Ана. – Казан, 2015.

Кукморский край. – Казань, 2008.

Эстафета памяти. Научно-практическая конференция «Вклад татаро-башкирского сообщества в социально-экономическое развитие и культуру Иссык-Кульской области и города Каракол». – Каракол, 2012.

ЛЕЙЛА АХМЕТОВА (АХМЕРОВА) О НЕИЗВЕСТНЫХ СТРАНИЦАХ ЖИЗНИ ОТЦА И МАТЕРИ

Р.З. Салиев

Лейла апа родилась в 1934 году. В настоящее время она проживает в г. Заинске.

– Лейла апа, известно, что ваш отец до 1917г. был первым имам-хатыбом и мударисом д. Старая Киреметь. Благодаря его усилиям в Старой Киремети появилась не только школа, но и возникли мечеть, библиотека. Это благодаря его стараниям жители деревни смогли официально оформить свое «отпадение» от православия в ислам, получили разрешение на строительство мечети и иметь своего указного муллу.

– Мой отец – Хасанжан Ахмеров родился 20 октября 1874 г. в д. Абдреево (Новомалыклинский район, Ульяновская область). В нашей семье из 15 детей пятеро умерли в детстве. Самая старшая – Амина (1901 г.), в детстве дружила с Х. Туфаном, они вместе учились и играли. Из 10 детей шестеро пошли по стопам отца и матери, они стали учителями. Моя мама – Нагима еще до замужества работала учительницей в деревне Кизляу (Курманаево), она родом из Старой Киремети. Мама была хорошо воспитанной и образованной, росла без отца. В деревне она слыла первой красавицей и модницей…

– Лейла апа, раз вы заговорили о матери, расскажите историю вашего рода по материнской линии. Эта история интересная?

– В 1890-е гг. в Старую Киреметь приезжают артисты с медведем на поводке, чтобы показать жителям деревни цирк. На площади в центре деревни собираются все, в том числе дети. После представления зрители начали потихоньку расходиться. Артисты остались одни, уже темнело. Только Гайнетдин бабай (он был очень простым и добродушным человеком), недолго думая, подошел к артистам и пригласил их в свой дом на ночлег. Он щедро угостил гостей, в том числе и медведя. Гости даже попарились в бане. Утром артисты, попрощавшись с хозяевами, уехали. С тех пор деду дали прозвище – «Аю» («Медведь»). Вот этот «Аю» бабай и есть отец моей мамы. Без әни ягыннан «Аю» – Гайнетдин бабай нәселе булабыз.

Мать моей мамы звали – Махижамал, она была молодой женой Гайнетдина. Когда Махижамал выходила замуж за Гайнетдина, он уже имел шестерых детей. Отца Махижамала звали Абдували. Абдували был ува-

жаемым человеком в деревне, его жену звали Махмижамал. У Гайнетдина было 11 детей. У Абдували (дед моей мамы) тоже было 11 детей. Отца Абдували звали Амир. Вот этого Амира забрали в царскую армию, у него дома осталась молодая жена с сыном Абдували. Представьте, в течение нескольких лет молодая жена не получает никаких вестей от Амира.

Вскоре молодую мать с ребенком забирают родители, и, не спросив ее согласия, выдают замуж за другого мужчину. Через некоторое время объявляется солдат Амир – очевидно, он сбежал из армии. Солдат видит, что дом пустой, сын и жена отсутствуют. Добрые люди объясняют Амиру, что к чему. Амир был смелым, он решается на отчаянный поступок – забирает к себе домой сына и жену. Беглеца усиленно ищут и находят в Старой Киремети дома. Амира в тот же момент арестовывают и увозят неизвестно куда. Больше он домой не возвратился.

Имам-хатыб Хасанжан Ахмеров с женой Нагимой. 1921

– Дальнейшая судьба Амира известна?

– К сожалению, больше о нем мы ничего не знаем.

– Интересная и печальная история. Почти готовый сценарий для кинорежиссёров.

– Равиль, таких историй из жизни нашей семьи можно рассказать очень много…

– Лейла апа, я внимательно прочитал воспоминания вашего отца. До издания этих мемуаров о просветительской деятельности Хасанжана Ахмерова мы знали из воспоминаний Х. Туфана. Конечно, наши знания о вашем отце, о его бурной деятельности в Старой Киремети расширились, когда его «Истәлекләр» стали достоянием читателей. Но весь вопрос в том, что эти воспоминания прерываются 1924 г. Даже Масгут Гайнетдинов (доктор филологических наук), издавший это уникальное воспоминание, на стр. 21 («Истәлекләр». Казан: «Иман» нәшрияты, 2004) пишет: «Яуширмәдә күпме яшәгәнлеге, Урта Азиягә кайчан китеп кайда яшәгәнлеге, горбәттәге (читтәге) язмышның нинди кагу-сугуларны күргәнлеге, кайда яшәгәнлеге хәттә безгә билгесез. Үзенә карата шундый рәхимсез булган бу дөньяда кайчан күз йомганлыгын да белмибез. Совет режимы аңа, кеше буларак, үз көне тотрыклыгын саклау хәсрәтеннән башка мөмкинлекләр калдырмый. Анысына да, үкси-үкси шөкер итмәле: ГУЛАГ газаплары фаҗигасыннан котылып кала алганга охшый».

– Равиль энем, сейчас я постараюсь восполнить этот пробел. Отец вынужден был уехать из Старой Киремети в 1924 г. Там остался Калим жизни (он был женат на сестре моего отца Асме). В деревне его все звали просто – Калим жизни. После Октябрской революции в Старой Киремети начинает действовать Комитет бедноты. Секретарем этого комитета и был Калим җизни. Вскоре его арестовывают и отправляют в Чистополскую тюрьму. Пробыв несколько месяцев в тюрьме, он выходит на свободу. Калим жизни ненадолго появляется в деревне и куда-то уезжает с семьей. Больше о нем у меня нет сведений.

Отец же с 1924 г. выполняет обязанности муллы в 1-й махалле Яуширмы. В 1926 г. его арестовывают и он оказывается в Чистопольской тюрьме. После ареста отца, маму с семью детьми выгоняют из дома. Окна и дверь заколачивают досками, все книги, что были дома, сжигают на костре. Семья остаётся на улице. К ним никто не подходит – все боятся даже слово сказать. Только одна, очень сердобольная старушка, пожалела и пустила к себе на ночлег, она их накормила. Остальные же все отвернулись от них. Ночью в окно бабушки постучали. Бабушка сообщила, что за ними приехали друзья отца. Они усадили всех в телегу и семья отправилась в Чистопольскую тюрьму, чтобы попрощаться с отцом. Только матери с маленьким ребенком на руках дали возможность

увидеть отца и попрощаться с ним. Бу кечкенә бала төрмәдә әтидән дога алып чыга.

Чтобы выжить, мама принимает решение уехать в Самарканд к родственникам. На железнодорожном вокзале воры, разрезав мешок, крадут у мамы деньги и документы. Друзья отца, провожавшие семью, отдают маме свои деньги, у кого сколько было. Купив билеты, они сели на поезд «Казань – Самарканд» («Максимка»), он был окрашен в красный цвет, возможно, это был товарный вагон (пол был застлан соломой). Добирались ровно 7 дней, поезд часто останавливался в пути. С кучей детей мама буквально вваливается в дом к Амировым. Нургали Амиров – правнук солдата Амира, о котором я уже рассказала. По профессии мама учительница, но она осталась без документов. В то время учителя пользовались спросом, они нужны были везде. Хоть и без документов, маму принимают на работу в одном отдаленном от города горном кишлаке. Председатель колхоза выделяет отдельный дом для жилья, нам помогают. Мама в очень короткий срок своими руками ремонтирует школу, складывает печь, белит стены, потолки. Приводит в порядок и дом. Мама одевается как узбечка, разговаривает на узбекском языке, ее уважают, она соблюдает намаз. Дети ее любили, и сама она очень любила детей. В то время в горах свирепствовали басмачи, они часто убивали учителей, их семьи. Спасая семью и себя мама решает бежать из этого кишлака. Она увольняется с работы и переводится на другое место жительства.

– Извините, откуда у вас такие подробности, вы же тогда были маленьким ребенком?

– Да это так, меня ещё на свете не было или я была ещё маленькая, но мне об этом не раз рассказывали мои старшие братья. Я, как губка, все это впитывала.

Отец четыре года сидел в Чистопольской тюрьме. Друзья, родственники не раз ходатайствовали, чтобы его освободили, доказывали, что он не «враг народа». В итоге, в июне 1930 г., его выпускают из тюрьмы на свободу. Отца вновь зовут в Старую Киреметь, но он говорит, что ему надо найти свою семью. Он находит нас и воссоединяется с семьёй. У отца на руках был единственный документ, что сидел в тюрьме. Пишет письмо в Абдреево и Старую Киреметь, но ответа не получает. Окончив курсы счетоводов в г. Самарканде, отец получает документ. Это 1931 г., наверное. Да, точно.

В августе 1931 г., он, наконец, устраивается на работу счетоводом в колхоз «Каганович» Джамбульского района Узбекской ССР, где мать работала учителем. В 1938 г. отец выходит на пенсию, и они с мамой переезжают в г. Душанбе. Дети уже выросли, получили образование, и кое-кто

из моих братьев и сестер обосновались в Душанбе. Отец умер в Душанбе 15 января 1955 г.


Указъ ЕГО ИМПЕРАТОРСКАГО ВЕЛИЧЕСТВА САМОДЕРЖЦА ВСЕРОССІЙСКАГО, изъ Казанскаго Губернскаго Правленія Чистопольскому Уездному Полицейскому Управленію.

Въ Губернскомъ Правленіи по выслушаніи дѣла объ опредѣленіи

ПРИКАЗАЛИ:

– Я уже догадался, почему ваш отец в своих воспоминаниях ни словом не обмолвился о своих мытарствах в Чистопольской тюрьме. Он не хотел навредить своей семье, и прежде всего своим детям? Очевидно, по этой же причине его воспоминания обрываются 1924 г., когда он покинул Старую Киреметь и прибыл в Яуширму.

– Равиль энем, времена были сложные. Все страдали. О том, что мой отец сидел в тюрьме как «враг народа», я сама узнала, будучи уже на пенсии.

– Как Вы оказались в Заинске?

– Когда наступили «смутные времена» – 1991–1992 гг., старший сын Марат с женой вынуждены были уехать из Душанбе и обосноваться в Заинске. По воле судьбы мы с супругом тоже оказались здесь.

– Лейла апа, Ходай Сезне сәламәтлектән аермасын! Аллаһы Тәгаләдән киләчәктә озын бәхетле гомер сорап, изге теләкләр юллап догалар кылам.

– Ходай сиңа да, гаиләңә дә озын гомер бирсен!

Примечание: В Национальном архиве РТ я обнаружил ряд документов связанных с деятельностью Х. Ахмерова в качестве имама-хатыба села Старая Киреметь. Эти документы я включил в книгу: «История села Старая Киреметь» (Казан: Яз, 2017. 284 бит).

Мое открытие

В 2004 г. издательство «Иман» («Вера») выпустило книгу «Истәлекләр» («Воспоминания»), автором которой является Хасанжан Ахмеров – имам-хатыб и мударрис с. Старая Киреметь Аксубаевского района.

Мулла Хасажан Ахмеров, первый учитель Хасана Туфана. Это он был проводником мальчика по имени Хисбулла (Хасан) на пути в прекрасный мир поэзии. Х.Туфан с любовью вспоминал своего учителя и прямо указывал, что Х.Ахмеров сыграл большую роль в его становлении как поэта. «Давыллы еллар лирикасы» (1970) исемле җыентыгында, «Бәлки шагыйрь булмас та идем», – дигән кереш мәкаләсендә Хәсән ага Туфан бу мәсьәләгә аерым туктала. «Соңга таба минем «белем даирәм» тагын да киңәя төште. Безнең авылның мулласы Хәсәнҗан Әхмәров абый мине үз өенә килгәләп, китаплар, газетлар укып йөрергә чакырды. Яшьтәшем булган кызы белән без аның бик кызыклы әңгәмәләрен тыңлый идек. Ул, безне газета дигән нәрсәгә ияләштерү өчендер, алардагы хәбәрләр буенча, бик кызык сөйләшүләр, аңлатулар алып бара иде. Хәсәнҗан абый безне кояш тирәсендә әйләнүче планеталар һәм Галәмнең төзелеше белән дә аз-маз таныштырды».

Прочитав эти строки, становится понятным, откуда берет начало родник поэзии Туфана...

На том, как рукопись (оригинал) воспоминаний Х. Ахмерова оказалась в руках известного писателя Газиза Кашапова, автора книги о Х. Туфане «Млечный путь», я останавливаться не буду. После смерти Г. Кашапова обладателем копии рукописи Х. Ахмерова стал доктор филологических наук Масгут Гайнетдинов, который и подготовил ее к печати…

Как-то я пришел в гости к отцу и застал его за чтением «Воспоминаний». Чтение отцу дается с трудом, подводит зрение. Увидев меня, отец сказал:

– Улым, я немного отдохну, пойду в сад, а ты почитай вот эту книгу. Она – настоящее сокровище, цены ей нет. Вот только обложка очень тон-

кая, да и качество бумаги желает лучшего, переиздать ее надо большим тиражом.

– Отец, это стоит больших денег…

– Видать еще не осознали значимость этих воспоминаний. Ее автор Хасанжан Ахмеров – мулла нашего села, он в 1906 г. открыл медресе и мечеть в Старой Киремети. Его я знаю по рассказам отца и Хасана Туфана, это о нем я поведал когда-то Р. Батулле.

– Отец, ты иди, отдыхай. Я уже приступил к чтению, потом расскажешь…

«Воспоминания» я читал «запоем», без минутной передышки, точно взахлеб. Моя голова впитывала все, что написано, как песок в горячей пустыне – капельки случайного дождя. Захватывающая книга, автор описывает события, в гуще которых он сам когда-то «крутился». «Воспоминания», без сомнения, являются уникальным произведением, оно еще мало изучено, и только что входит в научный и литературный оборот. Свои воспоминания Х. Ахмеров написал в 1945–1946 гг., будучи 72-летним стариком, 55 лет спустя после событий, о которых он пишет. 27 лет он верой и правдой служил жителям Киремети. Летом 1924 г. Х.Ахмеров вынужден был покинуть Старую Киреметь. Красные говорили: «Мулла – для революции чуждый элемент». Белые говорили: «Коммунист – мулла». Во время «вилочного» движения его чуть не убили, укрылся в Биляре в штабе красных. После долгих раздумий он решает совсем отказаться от духовного сана. Вскоре Х. Ахмеров приезжает в Чистополь, чтобы сдать указ о его назначении муллой в Старую Киреметь. Мухтасиб Шигаб мулла уговаривает его поехать в деревню Яуширма (родина Гаяза Исхаки) в качестве муллы. Он соглашается и получает другой указ. На этом месте рукопись воспоминаний прерывается. Как сложилась дальше судьба Х. Ахмерова? Сколько времени он прожил в Яуширме? Когда он уехал в Среднюю Азию? На эти вопросы в книге нет ответов. Масгуд Гайнетдинов, издавший «Воспоминания», в своей авторской версии пишет: «Нам даже неизвестно, где и когда он умер»…

В книге имеются интересные эпизоды: о революционных днях 1905 г. (Астрахань), о восстание «вилочников» (1920 г.), о голоде 1921 г. Большой интерес для меня представляет преподавательская деятельность Х. Ахмерова. Его я бы назвал и муллой, и директором школы. По сути, он занимается теми же вопросами, что и директора школ – это и подбор кадров, внедрение новых форм и методов обучения, оснащение школы учебно-наглядными пособиями. Он тоже «ломал голову» – искал источники финансирования школы, а денег как всегда, не хватало. В воспоминаниях Х. Ахмерова имеется богатый материал и по истории с. Старая

Кереметь. Очевидно, о существовании рукописи «Воспоминаний», о ее содержании, до недавнего времени никто не знал. Мне кажется, что ученых, изучающих историю татарского народа, а также исследователей татарской педагогики и жизни татарских медресе, ждут открытия. Это еще впереди. Жаль, что тираж книги очень мал, всего 200 экземпляров, это же капелька в море. Прав мой отец, переиздать ее надо большим тиражом.

Пока отец отдыхал, я сделал важное открытие для себя. Х. Ахмеров в своих воспоминаниях (С. 117) пишет: «1906 елның җәендә, ике урәтник, авыл старостасы Кәшшаф Сәлиевне алып, мулла Хәсәнҗан Әхмәровны сорап киләләр. Өемдә тентү үткәреп, шөбхәле һичнәрсә тапмастан китәләр».

Вот это да! Значит в книге «Бер тамчы ярату» (в рассказе «Дәрвиш хатирәләре») Набира Гиматдинова ничего лишнего не придумала. Мне не раз говорили, что сочинять можно что угодно. Вот и доказательство, что мой дед был старостой деревни Старая Киреметь, об этом черным по белому пишет Х.Ахмеров. Мой дед хорошо знал и отца Хасана Туфана…

Далее на 118 странице я обнаружил кое-что о моем прадеде Сали бабае и его дочери Бибиҗамал. Вот, что пишет Х. Ахмеров в своих воспоминаниях: «1907 елда мәзкүр Габделкәрим ага Сибирәков кыз балалар өчен дә мәктәп салдырды. Кызлар мәктәбе бар, укытучы гына юк. Хатыным аврый. Кардәшем тормышка чыкты 1907–1908 уку елына уз мәхәлләбездән үзебездә укыган кызлардан Сәли бабай, Гыйззәт бабай кызларын (Бибиҗамал, Саимәләрне) укытучы итеп тәгайин кылдым»...

Рассказывал же мой отец, что Бибиҗамал апа учила детей в школе. Позднее в 1940–50-х гг. в Старокиреметской школе работали моя мама – Валиахметова Ркия Махмутовна и мой отец – Зуфар Салиев. Х. Ахмеров в своих воспоминаниях («Воспоминания», стр. 124) пишет: «Бикүледән таланып куылган китапханәне Кармәтбашында ачып, шул китапханәдә эшләргә мулла Хәсәнҗан тәгайин кылына. Тәгайин кылыну берлә, китапханәгә кирәкле китапларны алу өчен Казанга китәм. Кәшшаф Салиевтан йортны иҗарәгә (арендага – Р.С.) алып, рәсми рәвештә, китапханәне ачам» (открытие библиотеки относится к началу 1917 г.).

Мне не раз приходилось слышать от отца, что мой дед был грамотным: умел читать и писать, хорошо разговаривал по-русски. В период Столыпинской реакции и Русско-японской войны 32-х летнего Кашшафа Салиева (родился в 1870 г.) избирают старостой Старой Киремети. Несколько раз подряд, каждый раз на три года.

Уже находясь где-то в далекой Средней Азии, Х. Ахмеров (он, как было сказано, бежал туда из-за преследований Советской власти и своих врагов) с глубокой тоской вспоминает своих друзей и жителей Старой Киремети, кто оказал ему помощь и содействие.

«Булып үткән остазларымның һәм дусларымның кемнәр булуын язып үтүне тиеш күрәм: Беренче остазым Яңа бистәнең дәмелла Салихҗан Галиев, Габделкаюм хәзрәт Бәдыйгый, дәмелла Галимҗан Баруди, Чистайның дәмелла Нажиб хәзрәт Әмирхан, тарикать остазым дәмелла Нуретдин хәзрәт Тархани, хәлфә Батырша хәзрәт, Камалетдин бин Гыйниятулла, Фатыйх – Тажи-Гани, Дәүләтша Искәндәр, мулла Кәмаль, Мулла Мөхетдин Фәхретдин. Мәхәллә картларыннан күп яхшылыклар күргән картларым: Фәхретдин бабай, Шәкүр бабай, Гөбәш бабай, Сәли бабай, Ишмөхәммәт, Сабит бабай, Зариф Гөбәш, Хисаметдин Гайнетдин, Нуретдин Гыйнетдин».

Автор «Воспоминаний» (С. 132–133) перечисляет имена и фамилии около 50 человек, большинство из них – это муллы и учителя, друзья и деревенские старики. Как видим, обширный список состоит из двух частей. В первую автор включил своих друзей и тех, кто оказал ему большую помощь и содействие. Во второй части списка не так много имен и фамилий, тут автор перечисляет своих противников и тех, кто его не раз обманывал…

Я внимательно читал этот список, искал своего прадеда и деда. Когда нашел прадеда Сали бабай, то неслыханно обрадовался – он в первой части списка. Во второй части списка моего деда Кашшафа Салиева я не обнаружил – это меня тоже радует…

Закончив читать, я пошел в сад к отцу. Вижу, как он «отдыхает» – читает второй экземпляр этой книги.

– Отец, ты уже отдохнул? Сейчас я тебя обрадую. В «Воспоминаниях» автор обмолвился и о твоих предках. Что скажешь?

– Сынок, мои предки – это и твои предки, они достойные люди. Хорошо и почетно идти по их стопам, они шли прямым путем. Мулла Хасанжан Ахмеров их упоминает только добрым словом. Я же сказал, что эта книга – настоящее сокровище. Клад же в твоих руках, а им надо делиться.

Примечание: В Национальном архиве РТ я обнаружил ряд документов связанных с деятельностью Х.Ахмерова в качестве имама-хатыба села Старая Киреметь. Эти документы я включил в книгу: «История села Старая Киреметь» (Казан: Яз, 2017. 284 бит).

КЫЯМ ҖӘГЪФӘРЕВ: АВТОБИОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

(Дәвамы. Башын карагыз № 2, 3, 2018)

Дамир Таҗи

КАЗЫЙЛЫК

1895 елның көзе. Көзге суыклар куып китергән шикелле Тайсуган мәдрәсәсенә иске шәкертләр белән аралаш яңа шәкертләр дә килеп тула. Укулар башлана. Талипның шәкертләре елдан ел арта. Шулай уку эшләрен җайлап йөргәндә Талипны Зәки хәзрәт үзенә чакырып ала. Хәзрәтнең өендә, зур бүлмәдә Яхшыбай Мортаза хаҗи ашап, чәй эчеп утыралар. Алар икесе дә Талип хәлфәне якты чырай белән каршы алып чәй өстәленә дәшәләр. Хәл-әхвәлләрне белешкәннән соң Зәки хәзрәт сүз башлый: «Мулла Талип! Мөхтәрәм Мортаза абзый үзләренең кечкенә уллары Гыйльфанетдинне сезгә укырга алып килгәннәр. Без мәслихәтләштек тә, аның үзегезнең кулыгызда тәрбия табуын муафыйк күрдек. Бүгеннән алып кабул кыласыз...»

Шул мәҗлестә Зәки хәзрәт Талип хәлфәгә мәдрәсәнең казыйлык вазифасын да тапшыра. Хәлфә бу тынгысыз эшне алмаска маташса да, хәзрәт аның авызын да ачтырмый өстенә йөкләп куя. Шул көннән ул Тайсуган мәдрәсәсенең хәкыйкый җитәкчесе булып кала. Шәкертләр арасындагы интизам, дини кагыйдәләрнең мәктәп эчендә үз вакытында үтәлеп торуы, мәчеткә йөрү, намаз калдырмау, җомга намазына бару шикелле мәсьәләләр казый кулында булалар. Казый булган кеше мәдрәсә эчендә һәм укучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне белеп тынычлык саклап торырга тиеш.

МӘДРӘСӘГӘ ШАЙТАН КИЛГӘН

Талип хәлфә сүзгә оста, сөйләгәндә мишәр шивәсе белән ашыкмый сөйли, ялган аралаштырмый, ялганлаган кешене җаны белән сөйми. Шук, шаян сүзләргә бик тапкыр, иптәшләренең фикерен бер сүз әйтү белән төшенеп ала. Казый булганнан бирле аның эше күп, барлык мәшәкатьләргә өлгерергә кирәк. Тайсуган мәдрәсәсендә укучыларны, сыйныфларны үз эченә алып, ятакларны, уку корпусларын берләштерүче аерым бина юк. Зур ишек алдында эреле-ваклы агач өйләр төзелеп киткән, аларның уртасына таштан салынган ашханә урнашкан. Анда иртәдән кичкә кадәр чәй кайнап тора. Каен, имән утыннары җәһәннәмдәге кебек шартлап янып,

олы плитәне кызыл төскә кергәнче кыздыралар. Ашханәнең эче һәрдаим болыт шикелле пар белән тулы, аяк асты һәрвакыт юеш. Яшь укучы шәкертләр киез итек белән кереп аның күзенә басалар. Анда бертуктамый шәкерт кайнаша: чәй ала, аш, ботка пешерә, анда һәрвакыт мәш киләләр. Мәдрәсә тормышы авыр булганлыгы сәбәпле укучылар арасында еш кына төрле низаглар чыгып күңелсез вакыйгалар очрап тора. Кемдер берәүне сүккән, кемдер берәүгә типкән яки суккан, салып еккан, болар гади һәм табигый хәдисләр. Әгәр Сарт Вәли, таз Касыймны тотып кыйнаган икән, моңа берәүнең дә исе китми. Шәкертләрнең һәрберсенең үз кушаматы бар. Кәкере Шакир, Ябалак Кәрим, Сукыр Нури кебек кушаматлар бер туктамый эшләп тора. Хәттә хәлфә хәзрәтләрнең дә кушаматы бар. Мәсәлән Зәки хәзрәтне «күркә Зәки» дип атаганнар. Еш кына мәдрәсә шәкертләренең фәнни-гыйльми тәрбияләре бик түбән, нәрсә дисәң шуңа ышаналар. Шайтан, җен, албасты, убыр, су анасы, өй анасы, пәри, шүрәле, рух, хозыр кебек әфсанәләр (фантастик хикәяләр, мифик хәлләр) турында үзара чынлы-хаклы хикәяләр сөйләү гадәте бар. Моңа кечесеннән алып зурысына кадәр ышаналар. Пәри ялаган, җен суккан, шайтанланган, су анасы алыштырган дигән сүзләрне кулланып, шуңа чын күңелдән ышанып, бераз өстәп тә дөресен сөйлиләр. Бигрәк тә яшь шәкертләр мондый хикәяләрне зур ихлас, аерым ләззәт белән тыңлыйлар. Мәдрәсә хәяты борынгыдан килгән традицияләр нигезендә дәвам итә.

Кыш уртасы. Пәнҗешәмбе (атна кич), ягъни иртәгә җомга, бөтен мөселманнар өчен бәйрәм һәм ял итү көне. Якын тирә авыллардан килгән укучылар ата-аналары янына, ялга кайтып китәләр. Талип казый Яңа Әлмәткә киткән була. Мәдрәсәдә ерак авыллардан килгән укучылар гына калган. Һәр өйдә 10–15 баладан артык түгел. Балалар һәркем үз эше белән мәшгуль (нәрсә дә булса эшләп утыру). Кичке сәгать 11–12 тирәләре. Яшь һәм кечкенә балалар укый торган өйнең бозлы тәрәзәсенә әллә нинди бер куркыныч нәрсә килеп каплана. Йөзе бик киң, борыны чамадан тыш зур, авызы исә җәелеп әшәке тешләре күренеп тора. Маңгаенда бердәнбер күзе ут кебек янып, бер ачылып, бер ябылып тора. Аннан югарырак олы бер мөгезе дә бар. Тәрәзә аркылы бу тагын да коточкыч булып күренә. Мәдрәсәдә утырган балалар авызларын ачып катып калалар да, һәммәсе бергә «шайтан», «шайтан» дип кычкырып җибәрәләр дә, чабыша һәм елаша башлыйлар. Зурырак шәкертләр кулларына һәфтияк, Коръән кебек китапларны алып әгузе бисмиллә әйтеп укырга тотыналар. Бераз вакыттан соң тәрәзәдәге шайтан юкка чыга. Тышка чыгарга да куркыныч. Шулай да кулларына дин китапларын тотып төркем-төркем урамга чыгалар. Башка өйләрдән дә чыгып кушылган олы балалар белән шайтанны күпме генә эзләсәләр дә таба алмыйлар. Шайтан күптән инде күккә иңгән.

Икенче көнне иртә белән мәдрәсәгә шайтан килгән дигән имеш-мимешләр авыл буйлап таралып зур бер хикәягә әйләнә. Хәйран калган халык ышанырга да ышанмаска да белми. Талип хәзрәткә дә моны мөһим зур вакыйга итеп сөйләп бирәләр. Бу хәл инде онытылды дигәндә, 15 көннәрдән соң тагын кабатлана. Мәдрсәгә шайтан килә. Балалар тагын бик куркышалар. Зур шәкертләр бик тиз киенеп Коръән, һәфтиякләрен күтәреп, йөгереп урамга чыксалар да шайтан эзсез югала. Шайтанның бу килүендә дә казый өйдә булмый. Мондый эчпошыргыч хәлнең янә кабатлануы, аннан соң һәр ике килүендә дә казый өйдә булмаган чакка туры килүе серле. Бу усал шәкертләрнең яки берәр үчле кешенең уйнатуы түгелме икән? Талип казыйның кәефе китеп ачуы чыга. Бу шайтан дигәннәре кем икән соң? Аны ничек тотып фаш итәргә икән? Шайтанны һичшиксез тотып балалар алдында акылга утыртырга кирәк дигән катгый фикергә килә казый һәм бер хәйлә кора.

Алдагы атналарның берсендә Талип казый пәнҗешәмбе көн, дәресләр беткәч һәм күп балалар өйләренә кайтып киткәннән соң, якташ дусты Хәниф хәлфә белән бергә икәүләп, барлык шәкертләргә таныш булган Садыйк бабайның ат-чанасын җигеп, мәктәп ишек алдында һәркем күрсен өчен бик озак маташып, кара толыпларын киеп, кичкырын чанага утырып Әлмәткә дип чыгып китәләр. Гадәттәгечә аларны хәлфәләр, шәкертләр җыелышып кул болгап озатып калалар...

Тайсуган авылын караңгы каплап ала. Мәдрәсә эчендә керосин лампалары берсе артыннан берсе яндырылып шәкертләр кич утырырга әзерләнә. Кичке сәгать уннар тирәсендә мәдрәсә ишек алдында йөрүләр туктагач Талип казый белән Хәниф хәлфә бер кешегә дә күренмичә, ишек алдына күп итеп өеп куелган утыннар, әрдәнәләр арасына толыпларын кигән көенчә кереп посалар да теге шайтанның килүен түземсезләнеп көтәләр. Кич сузылган саен тәнгә суык үтә бара. Җил күтәрелеп карлы буран уйный. Кар өстендәге эзләр дә күмелә. Төн эченә кергән саен авыл буендагы шау-шулар кими, мәдрәсә эче дә бөтенләй тынып кала. Шактый күп вакыт уза. Хәлфәләр суыктан калтырап шайтанны бик ачулы гына көтүләрен дәвам итәләр, өсләренә кар бөртекләре кунып үзләре дә ак төскә кереп бетәләр. Шайтан һаман юк та юк. Инде мәдрәсәдә соңгы лампалар да сүнде. Бу эшнең уңышсыз бетүенә хәлфәләр борчылып, инде торып китәргә уйлыйлар. Шулай икеләнеп торган чакта, мәдрәсәнең күрше Хәким ындырлары ягыннан нindider бер ак нәрсә, шәүлә күренеп китә. Хәлфәләр моңа бик сөенеп шайтанга күренмәс өчен сагаеп, тагын да яхшырак яшеренәләр. Бу баштан аяк кәфенгә уралган гәүдәнең шайтан булуына хәлфәләренең шик шөбһәсе калмый. Шайтан бик зур саклык белән мәдрәсәгә якыная. Бераз килә дә ак карга

утырып, я ятып тирә якны күзәтә, кеше фәлән булмаганлыкка төшенгәч тагын алга бара. Менә ул ашханәне үтеп, бөтен гәүдәсе белән кечкенә балалар укый торган өйнең тәрәзәсенә каплана, әллә нинди хәрәкәтләр ясый, аның битенә кигән маскасы ерактан ук дәһшәтле, җанны өшетерлек булып күренә. Балалар кычкырышып елаша башлыйлар. Шайтанга шул гына кирәк тә, үз батырлыгына шатланып, әллә нинди дуңгыз чинаган тавышлар чыгара. Әмма шайтан бөтен кыланмышларын күрсәтеп бетерә алмый. Ике кара толыплы кеше җәһәт кенә килеп, шайтанның өстенә бау ташлап урап алалар, карга яткызып кыймылдарга да ирек бирмиләр.

– Әй шәкертләр! Тиз булыгыз, монда чыгыгыз! Шайтан кулга төште, – дип кычкыралар. Бу сөенечле хәбәргә бөтен өйләрдән шәкертләр, хәлфәләр йөгерешеп киләләр. Арада моның чын шайтан булуына ышанучылар да була. Шайтанга барысы да тибеп калырга ашыга, кайсыдыр аның аркасын йодрык белән дөмбәсләп карый, өченчеләре шаккатып бу хәлне күзәтә. Шайтанның киеме бик калын ахыры, ул типкәнгә дә, сукканга да эндәшми. Бу Талип казыйга бер дә ошамый. Шайтан бик иркен ята, тавыш чыгармый, үзенең кем икәнлеген әйтми. Талип казый аны хәрәкәткә китерер өчен:

– Әй шәкертләр, бисмилла әйтеп шайтанга таяк белән сугыгыз. Югыйсә качып китүе ихтимал, – дип, дәртләндерә. Әмма шайтан һаман дәшми. Бу чараның да нәтиҗәсе юклыгы беленә. Казый эшне тагын куертып җибәрә:

– Шәкертләр барыгыз тиз генә ашханәдә купны кайнатыгыз, плитәне кыздырыгыз. Өстенә кайнар су коеп, утлы плитәгә бастырыйк. Китап шулай куша, – дип үгетли. Бу боерыкны алган берничә шәкерт ашханәгә йөгереп китәләр. Шайтан бу сүзләрне ишетеп куркудан калтыранып ята. Бу тамашадан кызып киткән кайбер шәкертләр күсәкләр күтәреп киләләр. Әммә аның белән сугарга рөхсәт ителми. Ниһаять, эшнең бик зурга киткәнен чамалаган шайтан телгә килә:

– Ә-ә-ә, кем, мелла Талип! Бу мин, шәкертләр, бу мин бит, Хәким абзыегыз. Мин шайтан түгел, мин болай гына, уйнап кына килгән идем, – дип акланмакчы була. Казый исә, аның сүзен тыңламый да:

– Берүк шайтан, җен-пәри сүзләренә колак салмагыз, гөнаһлы булырсыз. Шайтан булгач, ул Хәким кыяфәтендә дә, ат, сыер сүрәтендә дә, хәтта эт булып килүе дә мөмкин, ди. Шайтан эшнең гел начарга калуына пошынып һаман ялвара:

– Әй мелла Талип! Зинһар дип әйтәм. Мин күрше Хәким. Валлаһи дип әйтәм, мин шайтан түгел. Казый эшнең уңышлы барганын күреп, яшьләрнең канын тагын да уйнатып:

– Шайтан ул кыйнауны белми, аны ут кына җиңә. Әй Әхмәтҗан, Шәрифулла, плитә кыздымы әле, су кайнап чыктымы? Шайтанны ашханәгә алып барыгыз... Шәкертләр шайтанны күтәреп ашханәгә алып керәләр, ләкин йөзен ачмыйлар. Аны уртага алып, чиләккә кайнар су куялар. Хәким бөтенләй куркып кала.

– Сез мине үтерәсезмени, –дип елап җибәрә. Шайтанны аякка бастыралар да маскасын алып идәнгә ташлыйлар, Хәкимнең куркынган йөзе чагылып китә. Тайсуган Хәкимнең өе мәдрәсәдән ерак булмый. Ул үзе дә кайчандыр шул мәдрәсәдә укып, аны яхшы бетергән, әмма ниндидер сәбәпләр белән мулла була алмый калган. Ул хәзер атасыннан калган байлык белән авылда кибет ачып сәүдә итә. Хәким мәдрәсә шәкертләрен шаяртырга ярата торган була. Кибеткә килгән шәкертләргә дәресләре өстеннән төрле сораулар биреп сүз ярыштырырга, алардан көләргә ярата икән. Бу юлы да ул кызык чыгарып яшь казыйны ахмак итеп калдырмакчы, авылда төрле мәсхәрәле хикәяләр таратмакчы була. Әмма ни кызганыч, үзе адәм мәсхәрәсенә әйләнә. Шәкетрләргә дә ачуларын кайтару өчен бу хәл бик шәп була. Бу маҗараны казый тәрбияви якка юнәлдереп җибәрә:

– Юк ла, бу Хәким булмас. Шайтан нәрсә сөйләмәс. Кулдан ычкындырмагыз үзен, һавага очып китүе дә мөмкин. Ничек инде ул, сакалына чал кергән, авылның беренче бае, сәүдәгәре мәдрәсәгә килеп балалар куркытып йөрсен ди. Бу чеп-чи ялган. Аяклары белән кайнар плитәгә бастырып карыйк. Шуннан соң белербез, шайтанмы бу, әллә Хәкимме?

– Әйе, дөрес, бик дөрес дип кычкыралар җыелган халык. Шул арада шайтанның киез итекләрен салдырып алалар. Һич көтмәгәндә каяндыр Хәкимнең улы ашханәгә килеп керә һәм атасының кызганыч хәлдә булуын күреп аптырап кала. Хәким:

– Улым! Бар әниеңә әйт, шкафтан 25 сум алып бирсен. Шәкертләр иртәгә зыяфат (кунак булу) ясарлар, – ди. Әмма шәкертләр ризалашмый, 25 сум гына аз. Хәкимнең улы 50 сум алып килеп биргәч кенә төнге маҗара тәмам була.

Икенче көнне, ягъни җомга көн, Тайсуган мәдрәсәсендә чәйле, пылаулы күңелле кичә ясыйлар. Кичәнең эчтәлеге мәдрәсәгә шайтан килүгә багышлана. Шул вакыйгадан соң мәдрәсәгә һич бер шайтан килми. Аны авыл халкы озак еллар кызык бер мәзәк итеп сөйләп йөри.

МӘКӘРҖӘ ЯРМИНКӘСЕ

Тагын ямьле язлар җитә. Кечкенә елгалар шаулап ташыйлар. Инде зур елгаларга нәүбәт килгән. Тайсуган авылын икегә бүлеп, кисеп үтә торган Зәй елгасының да ташуы аерым көч-куәт белән ага. Ул киң болыннарны тулы каплап ага, кайбер авыллардан мунча, сарай, бура кебек карал-

тыларны да агызып килә. Җирләр кибә башлагач, язгы сабан якынлаша. Шәкертләр язгы кыр эшләренә авылларына китә. Укулар туктау белән Талип Зәки хәзрәт тапшыруы буенча мәдрәсә ишек алларын тазарта, бер урынны калдырмыйча себертә, мәдрәсә өйләренең тәрәзәләр капкачын ябып, такта белән кадаклап куя. Бер ике көн хәзрәтнең йөзләгән багана умарталарын әрәмәгә алып барып тезеп куялар. Мондый эшләр һәр минут табылып кына тора...

Җомга намазыннан соң ул үзе торган мәдрәсәгә кайта. Мәдрәсә буш, тынып калган, беркем юк. Ул үз уйларына батып утыра. Күңелсез фикерләргә бирелмәс өчен Тайсуган авылы янындагы тауга менергә була. Тауның эченнән зур-зур ташлар да күренеп тора. Мәдрәсәдә укыган һәрбер шәкерт яз башында, тау түбәләреннән кар киткәч, шул тауга чыгып сәяхәт итү, язгы саф һаваны туйганчы сулап кайта торган булалар. Әнә шул ташларга чокып үзләренең исем фамилияләрен дә язып куялар. Анда Талип бик күп таныш исемнәр күрә. Бер яхшы гына шомарак ташны сайлап ала да, гарәп хәрефләре белән: «Талибетдин бин Хәертдин бин Фәхретдин бин Гобәйдулла бин Җәгъфәр мулла. 1894 ел, 25 апрель», – дип язып куяр. Бәлки кайчандыр кемдер укып искә алыр. Тау башыннан Габдрахман авылы, аның яшәреп килә торган урман куаклыклары, сул яктан ялтырап, әллә кайлардан агып килгән Зәй елгасы, аның тегермән буасы, андагы куе таллыклар, әрәмәләр, ерак та түгел Бөгелмәгә китә торган каенлы юл, андагы юлаучыларга карап моңаеп ала.

Утырдым мин тауның күкрәгенә,
Хатлар язам, җилкәй исми тор!
Чү, шаулама син дә, кара урман,
Үткән гомерем, искә төшми тор!

Әй уйлар, уйлар. Ялгызлык һәм чарасызлык. Алдагы тормышның томанлы, караңгы билгесез булуы Талипның йөрәген сызландыра, ярсыта иде. Алга таба нәрсә эшләргә?

Сызла, сызла, сызла күңелем!
Сызла төн йокламыйча.
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла бер туктамыйча.

Кыш көне Әлмәт базарында байлар белән аралашып йөргән чакта, ул мәкәрҗә базары турында күп кызыклы хикәяләр ишеткәне бар иде. Байлар кичке чәйне тәмләп эчеп утырган вакытта үзара: «Мәкәрҗә бик зур базар, анда узган ел мин менә моның кадәр файда табып кайттым», яки «Әхмәт бай тагын баеп кайткан», – дигән сүзләрне күп тапкыр ишеткәне бар һәм шуның өчен мәкәрҗәне күрү теләге Талипның күңелендә ята

торган иң татлы хыялларның берсе иде. Тайсуган авылының тау башында аның бу хыялларын беркем дә бүлдерә алмый иде. Әле көтү кайтканда гына ул тирән уйлардан айнып китте. Күп тә үтми Талип казый хәзрәтнең мәдрәсәдән тыш башкарыла торган печән чабу, саклау, умарталыкларны карап тору, кышка утын китерү кебек вазифаларны үзенең якташы фәкыйрь бер мишәр шәкерткә тапшырып, хәзрәттән гозер сорап һәм рөхсәт алып Нижний Новгород шәһәренә, җәйге мәкәрҗәгә олы бәхет эзләргә чыгып китә. Ләкин Талип уйлаганча олы бәхет аны шәһәр читенә чыгып кочагын җәеп каршы алмый. Талипка ошаган авыр тормыш куып йөрүче яшьләр монда күп. Урыс, татар, чуваш, башкорт егетләре һәм алар кебек һөнәрсез, акчасызлар әллә кайчан килеп тулганнар. Байлар, сәүдәгәрләр, артистлар, угырылар, шулерлар шәһәрдәге бөтен кунак өйләрен биләп бетергәннәр. Талип кунак өеннән дә мәхрүм кала. Канвин ягындагы «двухцветная гостиница» каршындагы бакчага, үсеп утырган агачлар, куаклар арасына кереп урнашырга мәҗбүр була. Кичкырын бакчада адәм затлары күбәя төшә. Алар арасында Уфадан, Оренбургтан, Казаннан килгән татар яшьләре, мәдрәсә шәкертләре дә килеп чыга. Бәхет эзләп килгән бу бичара татар яшьләре иртәдән кичкә кадәр анда чабып, монда барып, ике кулга бер эш таба алмастан, ярым ач хәлендә кичен кунарга тагын шул бакчага, карт каен, имәннәр арасына кереп сыеналар. Ул вакытта багана башларында әле электр лампалары юк. Анда-монда куелган керосин лампа фонарьлары сәгать 12 ләрдә сүндерелә. Утлар сүнгәч, бигрәк тә болытлы төннәрдә бакча эче дөм караңгылыкка чума. Әнә шуны гына көтеп торган угыры, шулерлар бакчага кереп йоклап яткан тәҗрибәсез татар малайларын, шәкертләрне акыртып талыйлар, аларның соңгы киемнәрен салдырып алып ялан өс калдыралар. Өстәвенә татар балаларының бер авыз урысча белмәүләре жуликлар өчен кызык булып күренә. Аларның: «Ах ты сволочь, фраер! Я тебя покажу, где раки зимуют, гололобый татарин!», – дип, кәләпүш һәм җилән кигән татар малаеның яңак төбенә берне биреп, кулындагы капчыгын, ахыргы өсте-башын алып киткәндә ярдәмгә һичкем килми дә, күрми дә. Бу көннәрдә Талип үз янына күңеленә хуш килгән якташ мишәр егетләрен туплап бергә йөриләр. Алар бакчада кичләрне бергә үткәзәләр, арыш ипиен турап, суга манып бергә ашыйлар, чиратлашып әйберләрен саклыйлар. Мәкәрҗә яшьләргә якты чыраен һаман да күрсәтми, айга якын вакыт үтеп киткән. Әле кулга алып һичбер эш эшләнгәне юк. Бәхет урнына һәр көн бәхетсезлек очрап тора. Беркемнең дә кәефе юк. Бакча каршындагы беренче класслы рестораннан ишетелеп торган исерек авазлар, тәрәзә яктысында чайкалган акчалы байларның типтерүләре, хатын-кызларның чыелдаулары, оркестр-музыка тавышлары ачыгып йөзләре саргайган, эшсез татар яшьләренең бәхетсезлек хисен

тагын да арттыра төшә. Бу «хәсрәт бакчасы»ннан ничек котылырга. Шулай да бер төркем иптәшләр Себер баржасыннан йөк бушаталар һәм йөк төяп куялар. Эш беткәч акча түләнә. Көндәлек хәрәкәтләр өчен булса да бераз акча эшлиләр. Тамак хакына дип бәяләрне белмәгән, базар хакын аңламаган шәкертләр иң авыр эшләрне дә арзан бәягә эшләп куялар. Бу исә Нижний Новгородның элеккедән грузчик булып эшләп килә торган урыс кадровый пролетариатының ачуын китерә, чөнки эш урыннары кулдан китә. Шул сәбәпле алар бу татар «фраер»ларын куып җибәрү, аларны куркыту юлына басалар. Еш кына аракы эчеп алып кул сугышлары чыгаралар. Яшьләрнең акчалырын кыйнап алалар, я аракы алып сыйларга мәҗбүр итәләр. Һәрдаим «татарская морда» сүзләре ишетелә. Мондый күңелсез вакыйгалардан соң кайбер татар малайлары «хәсрәт бачасы»на баргач, ярты шешәне алып, ач карынга төшергәннән соң, үзләре дә ахмак булып, кычкырышып, дулашып, кайчакта сугышып та китәләр. Әмма Талип бу пычрак эшләрдән гел читтә тора, авыр көннәр кичерүенә карамастан, бакчаның кеше йөрмәгән почмагына барып намазларын укый. Нәкъ менә шул елны Иран әзәриләреннән булган мөселман сәүдәгәре бик олы баржага җылы якларда гына үсә торган җиләк-җимешләр алып Каспий, соңыннан Идел аша Мәкәрҗәгә килә. Ләкин ни өчендер баржа бик соңга кала. Анда йөзем, кишмиш, курага, лимон, әфлисун, банан, эре чикләвек кебек нигъмәтләр була. Аларның кайберләре бозыла да башлаган. Бу бай һәр көнне Идел буена төшеп, борчылып үзенең баржасын көткән. Баржа килгәч тә аны бик тиз бушатырга кирәк була. Ираннан килгән бай русча белми, урыс грузчиклары белән турыдан-туры сөйләшә алмый. Шул вакыт пристанда аның күзенә тыз-быз чапкан мөселмән эшчеләре, Талип бригадасы күренеп ала. Менә Алланың рәхмәте бит, бик тиз килешү ясала. Татар яшьләре бик тиз баржаны бушатып, аларны шәһәргә, ярминкәгә алып барып бирергә ярдәм итәләр. Байның ярминкәдә алган товарларын шул ук баржага йөкләп тә бирәләр. Эш вакытында Талип бу бай белән яхшы танышып кала. Байга мөселман татарлар, аның төрекчә, фарсыча, әзәрбайҗанча сөйләшә белгән бригадиры ошап китә. Бу бай Иранлы Мамедовлар икән. Ул һәр елны Мәкәрҗә ярминкәсенә килеп зур сәүдә кыла торган кеше. Нижнийда аның арендага алган складлары, лавкалары бар. Мамедовларда эш туктаусыз чыгып тора. Талип бригадасы хәрәмләшмичә бөтен эшләрне дә намус белән башкара. Талип казый сату эшләренә дә аралашып, тиз бозыла торган җимешләрне сатышып бирә. Шулай итеп быелгы ярминкә узып та китә. Талипка быелгы ярминкә матди яктан зур файда бирмәсә дә, хыялда йөргән табышлар чыкмаса да, аның өчен башка яктан күп иҗаби файдасы була. Карт Мамедов белән хәерләшкәндә Талипка уйламаган җирдән йөз сум бирә. Яхшы ук

бүләкләр дә тапшыра. Аның белән киләчәк ел өчен вәгъдәләшеп куя. Тагын шул вакытларда очрашырга сүз куешалар.

ЯКУП ШӘКЕРТ

Бу елгы көзнең яңалыгы шул. Яңа Әлмәт бае Исхак хаҗи үзенең Якуп исемле улын Тайсуган мәдрәсәсенә укырга китерә. Хәзрәт белән сөйләшеп Якупны укытырга һәм тәрбиягә Талип хәлфәгә тапшыралар. Шулай итеп Талип хәлфә карамагында бөтен әтрафка даннары чыккан ике байның – Яхшыбай авылы Мортаза хаҗиның Гыйльфан һәм Әлмәт авылы Исхак хаҗиның улы Якуп Талип хәлфәдән укыйлар һәм дини тәрбия алалар. Талипның болардан башка да күп кенә укучылары бар. Күбесенең әти-бабалары мулла-мәэзиннәр. Гыйльфан һәм Якупларга ашны бергә әзерлиләр. Бу Талипның ашау-эчүен яхшыртып җибәрә. Талип хәлфәлек һәм казыйлык эшен, мәдрәсәнең хуҗалык эшен бер ялсыз башкара. Ул аз йоклый, иртә тора, чаба, әмма бүгенге эшне иртәгә калдырмый.

УГЫРЫ ТОТЫЛДЫ

Чистай өязеннән килгән мишәр егетләренә юл өзелгәнче дип мартның 15–20 ләрендә бик күп итеп ашау-эчү әйберләре китереп китәләр. Пешкән арыш ипие, солы-бодай күмәчләре, тары ярмасы, май, ит, эремчек, баурсак кебек нәрсәләр. Боларның бары да мәдрәсә чормасына чыгарылып, андагы сандыкка бикләнгән була. Тайсуган мәдрәсәсендә мәктәп чормасы укучылар өчен склад һәм суыткыч булып хезмәт итә. Анда һәрбер шәкертең сандыгы тәртип белән куелган. Көннәрнең берсендә шул чормадагы сандыкларның йозакларын ватып мишәр шәкертләренең күп кенә ашау-эчү ризыкларын урлап китүләре ачыклана. Ерактан килгән шәкертләр ач калалар. Инде нишләргә? Ачлыктан аяк сузаргамы, әллә берәр чарасын күрергәме? Талип казый мәдрәсә эчендә тентү оештыра. Ләкин югалган ашамлыклар табылмый. Талип ике мишәр шәкертен бик алама киендереп, Тайсуган авылы буенча хәер сорашырга чыгарып җибәрә. Алар садака сoранып иртәдән кичкә кадәр йөриләр, авылда кермәгән бер өй калмый. Кич кайткач, бөтен җыеп кайткан ашамлыкларны үзләренеке белән чагыштырып карыйлар, әмма бернинди дә ошашлык күренми. Угырылар Тайсуганныкылар булмаганлыгын фараз итәләр. Талип казый әлеге балаларны үгетләп, аларга ямаулы капчыклар астырып, билләрен бау белән бәйләтеп, аларны теләнче итеп Тайсуганнан ерак түгел утырган Габдрахман авылына юллый. Ясалма хәерчеләр иртәдән кичкә чаклы Габдрахман авылында өйдән өйгә кереп, соранып йөриләр. Шулай йөргәндә, бер өйдә боларга югалган ипиләргә ошаган икмәк бирәләр. Шәкертләр Тайсуганга йөгереп кайтып мәсьәләне казыйга сөйләп бирәләр.

Казый шунда ук 7–8 мишәр шәкертләрен туплап, аларга зурырак балалардан да кушып Габдрахман авылына барырга куша. Укучы шәкертләр туп-туры авылның старостасына баралар һәм шул өйдә тентү ясауны таләп итәләр. Тентү вакытында шәкертләрнең ярмалары, ит, майлары табыла. Кызып киткән шәкертләр йорт хуҗасын өендә үк, староста алдында тотып тукмыйлар. Ашамлыкларны кайдан алганлыкларын әйттерәләр. Улы Зыятдин Тайсуган мәдрәсәсендә укый икән. Әнә шул угыры шәкертләрнең бөтен ризыкларын төнлә белән атасының атлы чанасына төяп җибәргән. Шәкертләр йорт хуҗасыннан атын җиктереп, үзен дә шунда утыртып, тентүдә табылган азык-төлекне чанага йөкләп Тайсуган мәдрәсәсенә алып киләләр. Бөтен мәдрәсә шәкерте нәфрәтләнеп кузгала. Зыятдин бу хәбәрне алдан ишетеп качкан була. Аны да табып китерәләр. Атасы белән бергә бик каты кыйныйлар. Соңыннан чаналарына салып авылларына куып җибәрәләр. Шәкертләр Зыятдингә шул чаклы нык төшергән булалар ки, ул өйләрендә берәр ай авырап ятып, шуннан терелә алмыйча, язда үлеп китә. Атасы исә исән калган булса да имгәнеп гарип булып кала. Бу бик тә рәхимсез һәм гадел вакыйгадан соң мәдрәсә эчендә бернинди дә угырылыкка урын калмый. Хәттә энәне дә сорап кына алалар. Казыйның бу тәкбирләре шәкертләр арасында хәйран бер хәл булып хәтерләренә сеңеп кала. Һәрбер эшне алдан уйлап, үлчәп кылырга өйрәтә.

РӘХИМ ИТЕГЕЗ КУНАКЛАР

Шул заманнарда Тайсуган мәдрәсәсендә «Таз Фатих» яки «кәкере ыштан Фатих» исемле бер хәлфә эшли. Бер кешегә ике кушамат, шул мәдрәсәнең үзендә бирелгән була һәм икесе дә бер үк вакытта сүздә кулланыла. «Кәкере ыштан Фатих», – дип аңа беренче тапкыр мәдрәсәгә укырга килгәч, кечкенә чагында бирәләр. Ул чорда татар балалары арасында чалбар кию гадәте булмый, бәлки ак ыштан яки киҗеле, өйдә тукылган ыштан кияләр. Кечкенә Фатихның мәдрәсәгә беренче мәртәбә киеп килгән ыштаны буй-буй итеп тукылган киҗеле ыштан була. Ул бик озак салмаудан киелгәне өчен самавыр торбасы шикелле кәкерәеп каткан була. Иске шәкертләр моны бик тиз мыекларына чорнап куялар. Яңа килгән кечкенә шәкертнең исемен белмәгәнгә күрә, «әнә теге кәкере ыштанлы малай» дип аңа төртеп күрсәтәләр. Әнә шул рәвешле Фатих шәкертлек елларын «кәкере ыштан Фатих» кушаматы белән үткәрә. Фатих Тайсуган мәдрәсәсендә озак еллар укып хәлфә дәрәҗәсенә күтәрелә. Хәлфә булып эшләгән елларында аны хәрби хезмәткә чакыралар. Армия хезмәтеннән котылып калу өчен ул, үзенең башын каен көле селтесе белән юа. Башы һәм чәч төпләре бик әшәке кутырлап, башындагы чәче бөртек тә калмый

коелып төшеп бетә һәм шул сәбәпле хәрби хезмәткә бармастан «ак билет» алып кала. Әвәлге матур кара чәчле Фатих хәлфәгә шәкертләр «Таз Фатих» дигән яңа дәрәҗәле кушамат тагып куялар.

Таз Фатих мәдрәсәдә үзенең бертуган энесе Мөхәммәтша дигән егет белән яшиләр. Мөхәммәтша да Тайсуган мәдрәсәсен бетереп, шул ук мәдрәсәдә хәлфәлек вазифасын алып бара. Фатих белән Мөхәммәтша икесе дә озын буйлы, бик килешкән гәүдәле, йөзләре белән дә бер-берсенә охшаган игезәк балалар кебек. Алар Шөгер янындагы бер авылның бик бай мулла уллары булып, мәдрәсәдә саранлыклары белән даннары чыккан иде. Саранлыклары аркасында мәдрәсәдә төрле хикәяләр туып тора иде. Фатих белән Мөхәммәтша мәдрәсәдә укып йөргән чакларында ук үзләренең хәлфәләренә бер тиеннән, ике тиеннән артык хәер-садака бирмәделәр. Алар яши торган почмакка чаршау корылган, чаршау эчендә кечкенә тәбәнәк өстәл куелган, алар шунда ашыйлар, эчәләр һәм йоклыйлар. Кичләрендә өстәл өстенә бишле лампаны яндырып куялар. Әмма лампага керосинны аена бер тапкыр гына коя торган булалар. Мөхәммәтша кичтән лампаны бик нык тазалап, куыкларын ял иттереп сөртеп, аны өстәл өстенә ягып, утын бик нык басып, сүнмәслек кенә калдырып, үзләре исә, башка кеше лампасына барып укыйлар, күршеләре лампасыннан файдаланып дәрес хәзерлиләр. Бу адәм көлкесе булып хисапланган хәлне бөтен шәкертләр дә төшенәләр, шуның өчен, алар күрмәгәндә генә шук һәм шаян шәкертләр үтеп барганда, лампаның утын нык чыгарып якты итеп ягып китәләр. Шул рәвештә берничә минутлар үтеп китә. Шәкертләр шырык-шырык көлеп йөриләр. Бу хәлне сизгән ике бертуган сискәнеп китеп пожар сүндерергә барган кебек лампа янына йөгерешеп киләләр. Караңгы почмакта берсе икенчесен шелтәләп: «Сиңа карап күзәтеп торырга кирәк иде бит», «Ник үзең карамадың, сиңа якынырак та әле», «мае күпме янды икән, ах, әнә күпме кимегән», – дип озак тарткалашалар. Фатих белән Мөхәммәтша кайнар ашны да көндә пешереп тормыйлар. Кечкенә сары самавырларын кайнатып чәй белән генә канәгатьләнәләр. Кайнар аш пешмәгәндә, алар самавыр эченә йомырка салып, ипи белән йомырка ашыйлар. Хуҗалык эшләре, чәй кайнату, йомырка пешерү, лампа тазалау шикелле эшләрне Мөхәммәтша башкара. Фатихтан сорамастан ул үз белдеге белән һич нәрсә эшләмәс. Фатих сөйләгән чагында сүзләрне теш арасыннан кысып чыгара. Читтән карап торган кешегә бу сәер һәм көлке булып күренә. Ул: «Мөхәммәтша кукәй сал», – дип энесенә әмер бирә. Тегесе: «Абый ничәне?». «Перррне», – дип җавап бирә саран Фатих. Бу аттай ике зур кешенең самавырга бер йомырка салып пешереп, аны икегә бүлеп, арыш ипие белән бер самавыр чәйне эчеп бетерүләре дә шәкертләр өчен гадәттән тыш хәл булып

күренә. Алар икесе дә бик арык, тәндә ит юк, йөзләре-битләре көзге үлән кебек саргайган, күздәге нурлары кешегә хәлсез карыйлар, эчкә батып торалар. Шулай яшәп, яшь гомерне җилгә кибәк шикелле очырып йөргән бер заманда Мөхәммәтша Шөгер ягындагы бер авылда тол калган абыстайга йортка кереп, мәзинлек вазифасын алып мәдрәсәдән китеп барды. Әмма агасы Фатихка урын чыкмый әле, якын авылларда Фатихка урын булсын дип бер генә мулла да үләргә ашыкмый, үзенә чакырмый да. Ул кияүгә чыкмаган кыз кебек мәдрәсәдә утырып калды.

Тайсуган халкы кунакчыл һәм хуш күңелле кешеләр. Авылда зур дини мәдрәсә булуы, һәр хәлдә әлеге мәдрәсәдә татар халкының үз заманының алдынгы, үткер акыллы, мәдәниятле яшьләрен, хәлфәләрен күреп, алар белән күп яхшы мөнәсәбәттә булып, кеше белән сөйләшергә, кунакка хөрмәт күрсәтергә өйрәнгән. Мәдрәсәдә укый торган һәр шәкертнең очрашу, кунак өе була. Кунак өенә шәкертнең ата-аналары да килеп-китеп йөриләр. Кайвакыт йорт хуҗасына күчтәнәчләр дә калдыралар. Юмартыраклары 2–3 сум садака да бирәләр. Кунак өе хуҗасы шуның өчен шәкертне атна саен мунча ягып чакыра, каен себеркесе белән чабындырып мунча кертә, тавык шулпасыннан пешкән нечкә татар токмачы белән сыйлый, аннан соң бал-май белән чәй эчереп, Коръән укытып, шәкерт хәлфәләрнең күңелен күреп озаталар. Тайсуган авылында мондый кунак өйләре күп табыла. Әмма шулар арасында шәкертләр өчен җанын да кызганмый торган һәм шәкертләрнең кайнап ята торган кунак өе Садыйк картта була. Тайсуган мәдрәсәсендә Бишмунча урамындагы Садыйк өен белмәгән шәкерт-хәлфә юк. Аның өчен барысы да тигез, ярлы-ябагае да, бай-бәтчәсе дә баребер. Мунча гел әзер тора. Мәгълүм ике туган да кунак өен Садыйк картта тоталар. Садыйк картның холкын бик ошатып калалар. Чөнки Садыйк карт, шәкерт үзе белеп садака бирмәсә, мунча өчен акча сорамый. Мунчадан соң аш белән сыйлап җибәрсә дә, аны берәүгә барып мактанып сөйләп йөрми, гайбәт сатуны белми. Таз Фатихлар өчен бабай җирдән табылган хәзинә кебек була. Көннәр шулай үтә. Мөхәммәтша мәдрәсәдән мәэзин булып киткәч, абыйсы Фатихка күп итеп күчтәнәчләр җибәрә. Карт остабикә ашка-суга оста, күчтәнәчләр эчендә майда пешкән сумсалар, пәрәмәчләр, баурсаклар, бодай күмәчләре, алар белән бергә бер тартма кәрәзле бал, эремчекле май шикелле тәмле ашамлыклар хәтсез күп. Саран Фатих боларны беркемгә күрсәтми генә чормадагы сандыгына бикләп куя. Шуны әкерен генә иптәшләренә күрсәтмичә ашап йөри. Үткен күзләрнең моңа саруы кайный. Ләкин бернәрсә дә эшләп булмый. Алар читтән генә торып «әй бәхетсез күмәчләр», «бәхетсез майлар» кеше авызына тимәстән әчеп, күгәреп әрәм булып ятасыз дип корсакларын кашып уфтаналар. Шундый кызыклы бер вакытта

Талип казый Садыйк картны фәүкылгадә урамда очратып бик мөлаем сөйләшә һәм аңа мәдрәсәгә килеп хәлфәләрдә кунак булып китәргә, әле сезне Фатих та сагынып искә алды дип ышандырырлык итеп әйтә. Җомга көнне кичкә каршы мәдрәсә ишеген тыйнак кына ачып, «Әссаләмүгаләйкум», – дип, Садыйк карт килеп керә. Өй эчендәге бөтен шәкертләр, хәлфәләр бу тавышка борылып карыйлар һәм ишетерлек аваз белән төрле яктан «вәгаләйкум әссәлам», – дип җавап кайтаралар. Садыйк карт Таз Фатих белән самими туганнарча күрешә дә, анның чыбылдыгы эченә кереп утырып кагыйдәле итеп дога кыла. Әмма «кунак килсә, мулла намазга утыра» диләрме әле, дөрес икән. Фатих хәлфә Садыйк бабайдан тизрәк котылу өчен ахшам намазына әзерләнә башлый һәм картны ялгызын калдырып чыгып китә. Моны сизгән усал шәкертләрдән һәм хәлфәләрдән берничәсе дәррәү кузгалып карт янына кереп утырып зур самавырга утсу салып, чәй хәзерләргә боерык та бирә. Фатих ахшам намазын бик озак сузып укыса да, Садыйк карт һаман чыбылдык эченнән чыгып китми. Киресенчә чыбылдык эченә кергән усал хәлфәләрнең аны җибәрәселәре килми, Фатих кунагы итеп күрәселәре килә. Шуның өчен төрле сүзләр табып бабайны сөйләштерәләр, намаз беткәнне көтәләр. Фатих эшләрнең башка якка барганын сизеп, Садыйк карттан чәй эчмәстән котылып булмаганлыгын белгәч, ахыргы доганы укып, амин тотып чыбылдык эченә кереп: «Хуш килдегез, кунаклар», – дип әйтергә мәҗбүр була. Фатих чәй эчермәү планының барып чыкмаганлыгына нык ышанганнан соң гына кечкенә шкафның бер кул сыярлык кына тәрәзәсен ачып, аннан теләртеләмәс кенә яшел чәйнеген ипләп кенә ала. Шул ук тишектән әллә нинди чүпрәккә төенләнгән бөртекле чәйне алып, кечкенә генә чеметеп яшел чәйнек эченә ташлый. Калай савытның капкачын алып чыбылдык эченнән чыгып китә. Күп тә үтми, ул кулындагы савыт капкачына аз гына бал салып, аңа бераз җылы су өстәп, сыекландырып кечкенә өстәл өстенә китереп куя. Шкафтан агачтан ясалган калакларны алып, кесәсеннән пәкесен чыгарып, калакларны кырып бераз агарта төшә, аларны кунаклар алдына таратып тезә. Тегермән ташы кадәр арыш ипиен күкерәгенә терәп кисеп, бик юка телемнәр әзерләп өстәлгә урнаштыра. Бер сүз белән әйткәндә, Садыйк картны җиңел генә бер-ике чәшке чәй эчертеп озатмакчы була. Торнаны кунак иткән төлке мәсәлендәге кебек кунактан тиз генә котылырга теләгән саран Фатихның кыланмышларын карап торган хәлфәләрнең ачулары бик килсә дә, хәзер үк сүгеп ачуланып ташлауны уйлаган кешеләр булса да, кунак алдында җәнҗал чыгару дини әдәпсезлеккә керә дип, тавышланып алуны кунак китүгә калдыралар. Бу эшнең тагын да кызып китүенә Талип казый сәбәпче була. Фатих чыбылдык эченә чәйне, самавырны алып кереп, сөтсез сыек чәй, арыш ипие, агач калак, сыек

бал белән сыйларга кучкач, төлкеләнеп: «Садыйк абзый, балын кабып эч, Садыйк абзый тәмләп эч», – дигән сүзләрне бик юмарт яудыра. Ул да булмый чыбылдыкны күтәреп, өч-дүрт мишәр хәлфәләре чәй янына тезелеп утыралар. Исәнлек-саулык сорап торганда, карт шәкертләрнең берсе кулында поднос күтәреп, бик әдәпле хөрмәт-тәгъзим белән өстәл өстенә тартмасы белән кәрәзле балны, капламыгы белән эремчекле майны, күкәй күмәчләрен кунаклар алдына матур итеп тезеп чыга, һәркемнең алдына ялтырап торган көмеш бал кашыклары куя. Өстәлне ямсезләп яткан агач калакларны җыештырып ала да, тагын бик зур хөрмәт, түбәнлек-коллык күрсәтеп чыгып китә. Каралып беткән агач бал кашыкларын тагын шкафка кайтып кермәсеннәр дип сындырып чүплеккә ташлый. Бу гамәлләрне күреп торган Фатих эчендә кабынган ачуны кая куярга белмәстән, шешенеп, бүртенеп чыбылдык эченнән чыгып, бу сый хөрмәтләрне китергән шәкертне кыйнарга эзли башлый. Ләкин шәкерт моннан әллә кайчан инде сызган. Аның урынында Коръән тәфсире тоткан Талип казый диварга сөялеп укып утыра. Бу ни хәл? Кая теге шәкерт? Хәлфәләрне кем чакырып китергән дип тузына. «Валлаһи газыйм Талип, бу синең кылган эшең, кунаклар киткәч синең белән сөйләшербез», – дип муен тамырларын кабартып, күзләрен акайтып йодрыкларын казый алдында селки. Әмма Талип исе китмичә генә, барысы да ишетерлек итеп: «Фатих абзый борчылма! Хәзер керәм, хәзер керәм», – дип, китабын тотып чыбылдык эченә кереп Садыйк карт каршысына утыра. Талип казый Фатихның артык кыставына һәм үпкәләп, аска карап утыруына игътибар бирмәстән, Садыйк абзый һәм хәлфәләр бер-берсен кыстап «балдан алыгыз әле, бик әйбәт кәрәзле бал икән», «күмәченнән рәхим итегез», – дип, озак итеп чәй эчәләр. Өстәлдә утырган зур самавырның суы бетә. Моны саклык белән чаршау артыннан күзәтеп торган олы шәкерт Талип казыйның тамак кыруыннан сизеп алып, тиз генә бушаган самавырны алып, аның урнына шундый ук икенче зур самавырны өстәл өстенә китереп утырта. Талип казый һич нәрсә белмәгән кыяфәт белән шкафтан бер уч чәй алып, яшел чәйнек эченә салып, самавыр башына пешәргә куя. Моны күргән Фатих, җанын бугазыннан тартып алган кебек «ах» дип ыңгырашып җибәрә. Хәлфәләр көлешәләр. Талип казый: «Фатих абзый, ни булды? Әллә берәр җирегез авыртамы?», – дип сорый. Фатих исә: «Ах, тешләрем, тешләрем», – дип, бу мәсхәрәгә чыдамастан чыбылдык эченнән чыгып китә. Кунакларның кашыклары да оялмыйча бик актив эшләп торалар. Чуенда пешерелеп китерелгән аш та, бәрәңге белән пешерелгән каз ите дә, ничек килгән шулай юкка чыгып баралар. Аш тәмам булгач, бөтен җирдә тынычлык урнашкач хәлфәләрнең берсе кычкырып Коръән укып җибәрә. Аннан соң озын итеп дога кылалар. Шуннан соң Талип

казый сүз алып кунаклар исеменнән, үзе исеменнән Фатих абзыйга шундый сый-хөрмәтләре һәм Садыйк абзый белән очрашып күңелле сөйләшеп үткәзгән бәхетле минутлар өчен рәхмәтләр укый. Кунаклар байлыгыгыз меңартсын дип урыннарыннан торалар. Садыйк картны озатканда инде таң әтәчләре кычкырыша иде. Кунаклар китеп, мәдрәсә эче бераз тынганнан соң Фатих хәлфә берни эндәшми нитми килеп, аш пешереп торган шәкертнең колак төбенә бик каты итеп берне сала. Моны чамалап, көтеп торган Талип, казыйлар Фатихның кулыннан тотып алалар. Кунаклар утырган чаршау янында бик зур ызгыш-талаш, җәнҗал була. Бу Таз Фатихның кунаклар барында көчкә чыдап, түзеп утырган бомбаның шартлавы иде. Хәлфәләр кәкере ыштан Фатихны төрле сүзләр белән оялтып карыйлар, аның намусын уятмакчы булалар. Фатих тиз генә тышка чыгып китә.

Фатихның тыштан керүен көтеп яткан хәлфәләр шөбһәгә төшәләр. Ул һаман юк икән. Аптырагач бөтен укучылар, хәлфәләр Фатихны эзләргә чыгалар. Шунда ниндидер эш белән чормага чыккан бер укучы Фатих хәлфәнең чормада асылынганлыгын чабып кереп әйтә. Талип чормага менеп китә. Анда Фатих хәлфәне, үзенең зур сандыгы янында, кызыл башлы озын тастымалы белән бәпкә агачына асылынган килеш таба. Талип казый тиз генә кесә пычагы белән тастымалны кисеп, Фатихны күтәреп ала һәм чормада ук яткызып, аңа төрлечә хәрәкәтләр бирә. Унбиш минутлардан соң Фатих әкеренләп сулыш ала башлый. Фатих хәлфә вакыйгасы мәдрәсә эчендә бик озак авыздан-авызга, телдән-телгә пышылдап кына сөйләнә торган хикәя әйләнә. Фатих киләчәктә дә Тайсуган мәдрәсәсендә хәлфә булып кала. Тормышларының ахырына кадәр Талип мелла белән дус булалар, кунакка йөрешәләр.

Наше историко-краеведческое наследие

«МӘЛИКӘ КИТАБЫ» ТАРИХЫ

(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 2, 3, 2018)

Ф. З. Яхин

XI

Кыз: «Каю рәхмәт торыр – халык андин качар?», – дип сорый. Аның бу соравы табышмак, әлбәттә. Егетнең тапкырлыгын сынар өчен бирелә ул. Кыз: «Ягъмур торыр», – дигән җавапны ишетә. «Ягъмур» сүзе борынгы төрки формада язылган. Безнең татарда ул кайчаннан «яңгыр» булып киткән – әйтүе авыр. Дөрес, «явым» сүзендә борынгы форма сакланган, әмма анда да авазлар күчеше күзәтелә.

Егеткә кыз тагын бер табышмак бирә: «Каю фетнә торыр – халык аны сүвәр [сөяр]?», – ди. «Мал берлә угыл-кыз торыр», – дигән җавап ала һәм моңа дәлил таләп итә. Табышмакларның җавабына дәлилләү соралмый, югыйсә. Шулай да егет, Аллаһының сүзе дип, ягъни Коръән аяте буларак, болай әйтә:

«انما اموالكم و اولادكم فتنة»

[«Әмнәма ләмәвалкүм вә әүладикүм фетнәтүн». Ягъни, «Чынлыкта малларыбыз вә балаларыбыз фетнәдер»].

Фетнә сүзен бабаларыбыз «бәла», «кайгы», «сагыш» буларак аңлаганнар. Ул шулай ук «гаугалану» мәгънәсенә дә туры килә. Егетнең бу рәвешле җавап бирүе аңлашыла: халык акылы Аллаһы тәгалә сүзенә янәшә куела һәм шуның белән, бер яктан, Коръәннең чын мәгънәсендә хакыйкать чыганагы икәнлеге раслана, икенче яктан, халык акылы югары бәяләнә. Мондый параллельләр укучыда Коръәнгә дә, халык акылына да хөрмәт хисен уята.

Балаларга фетнә буларак карауның хикмәте шунда, ата-аналар аларны даими кайгыртып торырга, алар өчен җан атып, сагышланып яшәргә мәҗбүрләр. Ә балалар моны шулай кирәк дип кабул итәләр. Хәер, үсеп җитеп, гаилә коргач, алар да үз чиратларында балаларын кайгырта башлыйлар. Тормыш шулай дәвам итә. Һәр буын киләчәккә карап яши. Кешеләрнең генә түгел, бөтен дөньялыкның яшәеш тәртибе шундый. Бу кагыйдәне дини фәлсәфә үзенчә аңлаткан. Балаларны фетнә буларак

күзаллап, аларга таянмау, алардан яхшылык өмет итмәү мәсьәләсен суфичылык алга чыгарган. «Мәликә китабы» бу мәсьәләгә шактый якын килгән, әмма ул аны суфиларча чишмәгән. Бу факт исә суфичылык фәлсәфәсенең эшләнелеп җиткән чорында бу әсәр языла алмау хакында сөйли, суфичылык тәэсире аңарда гомумән дә юк дәрәҗәсендә. Сүзебез монда төрки, аерым алганда, татар дөньясындагы бөреләнеп килүче суфичыл фәлсәфәнең электән табигый нигезе булуы хакында һәм ул нигезнең халык акылына да таянуына бәйле, әлбәттә.

Кыз алга таба: «Каю нәмәрсә торыр – күрмәин барыр?», – дип, ягъни күрмичә дә нәрсәгә ышану дөрес булганлыгын сорый. Егет моның иман икәнлеген әйтә. Иманның хикмәте шунда – Аллаһы тәгаләгә инану өчен дәлил кирәкмәүдә. Гомумән дә, иман китерелгәндә кешедән ышану гына таләп ителә. Хәтта чын мәгънәсендә инанып иман китерәме ул, әллә куркып яки кирәк булган өченме – боларның да әһәмияте юк санала. Иман үз телең белән раслап: «Иман китердем!», – дип әйтү белән дөрес була. Ул кешенең чыннан да иманлымы-түгелме икәнлеген тикшерү, тәҗрибә кылу, бәяләү таләп ителми. Менә шуңа күрә дә иман – «күрмичә дә бара», ягъни раслау сорамый. Тагын шунысы әһәмиятле, иманны шушы рәвештә кабул итү кәлам фәлсәфәсенә хас, гакыйдәнең шарты булып тора. Бу бездә, татарларда, шулай кабул ителгән һәм монда «Мәликә китабы»ның тәэсире дә юк түгел дияргә мөмкин.

Иманның нәрсә һәм ничек булуы хакындагы бәхәсләр VIII гасырдан көч алып китәләр. Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Хәсән иманның «күрмичә дә бара» идеясен алга чыгара, шәһадәт сүзләрен әйткән һәркем, шулай итеп, мөселман санала башлый. Аның асылына бәндәнең хаклымы-түгелме икәнлеген ачыклау Кыямәт көнендә булачак дигән фикер салына. Шулай итеп, кеше иманлымы-түгелме – моны бер Аллаһы тәгалә үзе генә белә булып чыга. Шушы өйрәтмәләр Мөрҗийә мәзһәбен барлыкка китерә, Гыйракта ныгый һәм Шигый мәзһәбе тарафыннан кабул ителә. Өммийә нәселе хәлиф булып утырганда (661–750) гарәп дөньясында ул төп кагыйдә санала. Португалия һәм Испаниядәге Кордова хәлифлегендә (929–1031) бу традиция дәвам итә. Мөрҗийә мәзһәбе карашларына хариҗилар каршы чыгалар, кече һәм олы гөнаһлар белән бәйле принципиаль концепция булдыралар, зар гөнаһлар кешене имансыз калдыра дигән фикерне алга сөрәләр. Сөнни мәзһәбе идеяләре формалашуда төп рольне башкарулары белән аларның идеаллары алга таба яшәвен дәвам итә. Димәк, «Мәликә китабы»ндагы «күрмичә дә бара» дип иман хакында әйтелгән сорау һәм җавап Сөнни мәзһәбе өйрәтмәләре белән ярәшеп җитми булып чыга.

Кыз тагын да сорый: «Күкдин югары нә торыр?», – дип. Аңа төрлечә җавап бирергә мөмкин. Әйтик, Аллаһының тәхете «Көрси» дип тә,

«һәммә нәрсәдән өстен булучы» дип тә һ.б. Әмма әсәрнең авторы иманда – ныклы, аның фәлсәфи-дини карашлары һәм белемнәре – тирән. Бу үзенчәлеге аның чын мәгънәсендә талантлы булуы хакында да сөйли. Шунысы әһәмиятле, әсәрдә егетнең җаваплары, дөньяви мәсьәлә булганда да дини эчтәлек белән ныгытылган. Бу исә халыкта ислам дини тәгълиматлары инде нык урнашкан булуы хакында сөйли.

Кызның күкләрдән дә югарырак нәрсәнеңдер барлыгы хакындагы шушы соравына Габделхәлим: «Көфер сүзләмәк торыр», – дигән җавап кайтара. Монда «көфер сүз» дигәндә, хаталы, ялган сөйләү, бозык сүзләр тарату күздә тотыла. Аларның күктән югары торуларының сәбәбе шунда дип күзалларга тиешлеме: көфер, ялган, кабихи сөйләү дөньялыкка да, күкләргә дә сыешмый, ягъни бернинди кысага да сыймый, һәртөрле чикләрне уза дип, әллә башкачамы? Тик шунысын аңлый алдык: бу хәбәр көфер сөйләүнең өстенлеге хакында түгел, билгеле. Ничек инде бозык сүз күкләрдән дә өстен була алсын? Димәк, моңа җавабыбыз юк, бу мәсьәләне чишми калдырырга мәҗбүрбез.

Моннан соң кыз тагын да бер сорау бирә: «Ул нә кош торыр кем, кыяматкәчә бер-берендин калмаз?», – ди. Егет аңа бу кошларның кичә-көндез, ягъни көн белән төн булуларын әйтеп бирә. Бу, әлбәттә, чын табышмак һәм анда дини фәлсәфә дә, гыйльми мәгънә дә юк. Аңардан соң килә торган сорау да чын табышмактан гыйбарәт: «Каю егач [кайсы агач] – унике шахы [ботагы] бар, һәр шахында утыз яфрагы бар, бер йөзе – ак, бер йөзе – кара?». Монда тагын да шунысына игътибар юнәлтергә тиешбез, бу табышмакның телендә чыгтай элементы бөтенләй дә юк. Бу исә әсәрнең язылу урынын Урта Азия белән тыгыз бәйләргә мөмкинлек бирми. Әмма эчтәлеге?

Мәликәнең ул табышмагын Габделхәлим болай чишә: «Ул егач – бер ел торыр. Унике бодакы – унике ай торыр. Утыз яфракы – утыз көн торыр. Бер йөзенең акы – көн торыр. Бер йөзенең карасы – кичә торыр». Бу – тапкыр һәм дөрес җавап. Әмма шунысы да бар: атна белән бәйле һичбер сүз юк. Һәм бу ни өчен алай? Ай календаре, ягъни Һиҗри ел исәбе буенча елның алты ае 30 көннән, алты ае 29 көннән гыйбарәт, ә Кояш календаренда, ягъни Милади ел исәбендә, елның 7 ае 31 көннән, 4 ае 30 көннән, февраль ае 28 көннән (дүрт елга бер тапкыр 29 көннән) тора. Һәр елда мөселманнар календаре (ягъни Һиҗри ел исәбе) 11 көнгә Европа календареннан (ягъни Миладии ел исәбеннән) калышып бара һәм 33 елдан соң бу ел исәпләренең көннәре туры килешә, очрашалар. Әмма бу вакытта Миладии ел исәбендә 32 ел гына узган була.

Габделхәлимнең җавабында болар искә алынмыйлар. Авторга монда әсәренең язылу датасына ишарәләү мөмкинлеге дә бар, әмма ул аны файдаланмый. Табышмакта елны агач белән, айларына ботакларына,

көннәрен яфракларына тиңләү кызыклы. Борынгы дәверләрдә дә, урта гасырларда да төрки халыклар, кытайлар, японнар, монголлар кебек үк, хайван исемнәре белән аталган ел циклын файдаланганнар. Бу табышмак та шуның белән бәйле бер – бер хайванга охшату рәвешендә төзелгән булса, без аның борынгы төрки бабаларыбыз тарафыннан гына уйлап чыгарылганлыгына инаныр идек, яки, һич югы, кытайларга булсын, яки монголларга бәйләр идек. Ә монда ул мөмкинлеккә урын калдырылмаган. Елны – агач, айларны – ботаклары, көннәрне – яфраклары белән янәшә куйган. Безгә агачлар белән бәйле календарьның тарихи кельт кавемнәренә караган друидларныкы булганлыгы мәгълүм. Аның беренче ае – Каен, 24-нче декабрьдән башланып, 20 январьгача дәвам итә; икенчесе – Миләш, өченчесе – Корыша (корычагач, дардар, русчасы – ясень), дүртенчесе – Зирек, бишенчесе – Тирәк, алтынчысы – Йогышма (дүләнә, камырлык, явышгы; русчасы – боярышник), җиденчесе – Имән, сигезенчесе – Очлак (русчасы – остролист), тугызынчысы – Чикләвек, унынчысы – Йөзем, унберенчесе – Сырмавык (русчасы – плющ), уникенчесе – Куралык (русчасы – тростник), унөченчесе – Карга миләше (аю баланы, русчасы – бузина). Шунысына игътибар итик: ул друидлар календарендә унөч ай. Димәк, бусы да Мәликәнең табышмагының асылын тәшкил итми. Бәлки берничә календарьдан хәбәрдарлык аркасында иҗат ителгәндер ул? Ягъни, бер мәдәни үсеш юлыннан икенчесенә күчкән чорларда иҗтимагый аңда шундый процесс бара: искечә күзаллау онытылып җитмәгән, яңачасы утырып өлгермәгән. Әгәр дә шушы мантыйкка нигезләнсәк, агач-ел белән бәйле табышмакның килеп чыгышы, эчтәлеге, мәгънәсе аңлашыла башлый да сыман.

Борынгы календарьлардан зәрдүшләр ел хисабы (Зороастр календаре) кызыклы. Анда һәр ел унике айдан гыйбарәт булган. Ә айларның һәркайсы төгәл утыз көннән торган. Алар үз фасылларына туры килеп барганнар. Шунысы әһәмиятле, зәрдүшләрдә атна төшенчәсе бөтенләй дә булмаган. Димәк, Мәликәнең табышмагының асылында шушы календарь ята. Безнең төрки бабаларыбызда да ул кабул ителгән һәм файдаланылган, ахрысы. Югыйсә татар китабында андый табышмак кайдан урын алыр иде? Габделхәлим – Төркестаннан. Ел белән агачны бәйләп җавапны ул ничек дөрес табар иде? Ә елларның исемнәрен – агач исеме, айларныкын – ботаклар аталышы дип тә булмый, андый ел һәм ай хисаплары безгә мәгълүм түгел. Әмма шунысы әһәмиятле: бу табышмакның фактологик асылы бар һәм алар халкыбызның борынгы тарихларына барып тоташа.

«Мәликә китабы»нда алга таба кыз: «Дөньяда ачылыг нә торыр?», – дип сорый, ягъни нәрсәнең ачы булуы белән кызыксына. Егет аңа ул ачылыкның юксызлык булуын әйтә. Кыз катылыкның нәрсә икәнлеген

сорый, егет аның байлык булуын әйтә. Монда барысы да аңлашыла. Юксызлык, мохтаҗлык – җанны кисә, аларны шуңа күрә дә «ачылык», дибез. Ә байлык – бәгырьне катылата, таш ясый. Ул катылыкны фетнә буларак та аңларга кирәк.

Егеттән кыз: «Дөньяның киңлеге нә торыр?», – дип сорый һәм аңардан: «Падишаһларның гаделе торыр, галимнәрнең гыйлеме торыр, байларның сәхавәте [юмартлыклары] торыр, дәрвишләрнең догасы торыр», – дигән җавап ала. «Дөньяның киңлеге»н бүгенге көндәгечә аңлау-аңлатуга күчерсәк, ирек-демократия дип кабул итәргә кирәк булыр иде. Егетнең кызга җавабында дәрвишләр дә искә алына, әмма ул «суфи-диндар» гына түгел, «фәкыйрьләр» мәгънәсендә дә килә. Моның шулай булуы байларга каршы куелуыннан дип аңлашыла башлый. Шунлыктан байларның юмартлыгы белән фәкыйрьләрнең догасы мәсьәләсе тагын да аерым мәгънәләр алалар, алар үзара бәйләнештәге төшенчәләр кебек кабул ителәләр. Ә падишаһларның гаделлеге белән галимнәрнең гыйлеме дә үзара шундый ук бәйләнешле мәгънәләрдә булырга тиешләр, югыйсә. Әмма падишаһка галим түгел, бәлки халык каршы куелганда дөресрәк булмасмы? Димәк, шушы мантыйк юлы белән килеп, монда «дәрвишләр» сүзенең «дин ияләре, динле кешеләр»не белдерер өчен кулланылуын аңларбыз. Егетнең җавабы байларга дәрвишләрне, патшаларга галимнәрне каршы кую тәртибендә түгел, бәлки аларны бер – бер артлы санап бару уңаена корылган булып чыга. Алардан тагын да шунысы аңлашыла: дөньяның киңлеге патшаларның гаделлегенә, байларның юмартлыгына, динле кешеләрнең догаларына гына түгел, галимнәрнең гыйлеменә дә бәйле икән. Ә дөньяның тараюы, шулай итеп, фәннең саегуыннан да килеп туа, димәк. Менә ни өчен ил, җәмгыять гыйльми югарылыкны тәэмин итүгә, саклауга, үстерүгә омтыла.

Сорауларын Мәликә көтелмәгәнчә бирә. Ул әле кабатлана да кебек, әле инде күптән булып узган темага кире кайтып ала сыман, әле халыкчан, гыйльми, дини, тарихи, фәлсәфи, әле хәтта сәяси темалар белән эш итә. Үз чорының һәммә фән өлкәләре белән бәйле сораулары – аның арсеналында, һәм алар кызның кызыксыну өлкәләренә карыйлар. Бу ягы белән ул үз гасырының укымышлы бөек шәхесе буларак күз алдына килә. Хикмәт аның ишеткән җавапларында гына түгел. Нәрсә хакында сорарга кирәк икәнлеген белгән кеше генә андый сорауларны бирә. Мәликәнең үзендә аларның җаваплары юк икән, егетнең хаклы яки хаксыз икәнлеген ничек бәяли алыр иде? Аның сорауларына Төркестани Габделхәлимгә кадәр һичкем җавап таба алмаган. Әмма, ничек кенә булмасын, әдип – үз чорының кешесе. Ул хәтта хыялый әсәр язсын, фонтастика юнәлешендә иҗат итсен, барыбер дә үз дәвере җитештергән күзаллау кысаларыннан читкә чыга алмый. Аның геройлары да, никадәр акыллы, батыр, белемле, тәүфыйклы күренмәсен-

нәр, әдип яшәгән дәвернең, даирәнең, шул гасырда халык җитештергән аң-белем һәм гореф-гадәтләрнең җимешләре. Борынгы ядкәрләребезне өйрәнүдә бу кагыйдәне исәптә тоту зур таяныч бирә һәм аерым әһәмияткә ия.

Игътибар итик: Мәликә алга таба алай ук кызыклы тоелмаган, әмма татар суфичылык чоры әдәбияты әсәрләрен яхшы өйрәнгән укучы өчен бөтенләй дә яңалык булмаган, XIX йөзнең беренче яртысы бөек шагыйре Һибәтулла Салиховның бүгенге укучыга мәктәп бусагаларыннан таныш «Тәндә җаным...» шигырендәге төп фикере белән аваздаш мондый сорауны бирә: «Гыймарәтме [төзекме] күп, вәйранәме [җимерекме] күп?», – дип. Сүз дөнья йөзе хакында бара. Һәм егет аңа болай дип җавап бирә: «Вәйранә күп, аның өчен – барча гыймарәтләр вәйран булыр», – дип.

Бу хакта шигырендә Һ.Салихов болайрак итеп: «Бу гыймарәт барчасы вәйран икәндер, белмәдем», – ди. Боларның хикмәте нәрсәдә? Беренчедән, дөнья йөзендә бер генә нәрсәнең дә мәңгелек түгеллегендә, ягъни дөньяда мәңгелек – юк. Икенчедән, моның шулай булуының сәбәбен Һ. Салихов наданлыктан күрә: «Дөньяда дөздем гыймарәт бары наданлык белән», – ди ул. Ә «Мәликә китабы»нда барча төзекләр җимерелә бара дигән фикер алга чыгарыла. Бүгенге зыялы кеше дөньяның туктаусыз үзгәрә баруын аның яшәү рәвеше, яшәеш кануны буларак кабул итә, әгәр дә шушы үзгәреш тукталса, яшәүнең дә бетүен белә ул, ягъни яшәү белән үлемнең даимилекне, мәңгелекне тәэмин итүче көчләр икәнлеген аңлый. Моны суфилар да, борынгы бабаларыбыз шулай дип аңлаганнар. «Мәликә китабы» һәр төзекнең дә киләчәктә вәйран булачагын күздә тота һәм бу сәбәпнең нәтиҗәсенә күз сала, «дөнья йөзендә вәйран күбрәк» дигән фикерне алга сөрә. Монда хәтта XIX йөз татар шагыйрьләреннән дә беркатлырак фикерләү рәвеше сизелеп тора. Һ.Салихов вәйранлыкны рухи халәт һәм мәгънә кысаларында күзаллый. Алай тирән фикер йөртү «Мәликә китабы»нда юк, әмма андагы конкретлык, төгәллек һәм шулар белән бәйле серләр, мәгънәләр күңелдә соклану хисләрен тудырмый калмыйлар. Ә Һ.Салиховча тоя һәм уйлый белү өчен татар акылына суфичылык дәверенә ирешү кирәк булган. Шушы фәлсәфә үзе генә дә «Мәликә китабы»ның язылуы суфичылык дәвере башларында, бәлки тарихи яктан аңа кадәрге чорда ук, булганлыгын төшенергә ярдәм итә.

Алга таба кыз нәкъ шушы соравы белән аваздаш икенчесен бирә: «Дөньяда үлекме күп, терекме?», – ди. Егетнең фикер сөреше ничек буласы әлбәттә аңлашыла. Дөньяда вәйран күп икән, димәк – үлек тә күп, диячәк ул. Аның җавабы да нәкъ шулай яңгырый: «Үлек күп торыр. Аның өчен кем, барча терекләр үлек булгучы торыр».

Әмма бу рәвешле фикер йөртү һәрвакытта да яшәмәгән. Шәрык әдәбиятларында киң таралган риваятьләрнең берсендә, мәсәлән, Искәндәр

һәм хакимнәр (акыл ияләре) турындагысында, мондый вакыйга тасвир ителә: Һиндстанны яулап алган Зөлкарнәйн (сүз Александр Макендонский хакында бара) илнең хакимнәре белән очраша һәм аларга ун төрле сорау бирә. Шулар арасында беренчесе нәкъ менә Мәликәнең Габделхәлимгә әйткәненә туры килә: «Кемнәр дөньяда күбрәк: терекләрме яки үлекләрме?» Һәм ул мондый җавап ишетә: «Терекләр, – диләр хакимнәр, – чөнки үлекләр инде юк» [Ведические притчи: 2008. С. 168].

Монда бөтенләй башка төрле җавап белән очрашабыз. Хакимнәрнең Искәндәргә әйткәннәре ачык аңлашыла. Аның мантыйгы да гади: үлгән кешеләр бу дөньяда калмый, башка дөньяга күченә. Димәк, бу дөньяда алар инде юк. Шулай итеп, терекләр һәм үлекләр мәсьәләсендә шушы рәвешле фикерләүләрдә без ике төрле мантыйк белән очрашабыз. Берсе – Искәндәр падишаһның акыл ияләренә бәйле, икенчесе – татарның үз карашы.

Искәндәргә нисбәтле ул риваятьнең кайчан барлыкка килгәнлеген белешә башласак, аның элекке заманнардан ук халыкта йөргәнлеген искәрергә тиешбез. Ни өчен дигәндә, хикмәте шунда: бу риваятьтә индусларның борынгы ышанулары, аларның дөньяга карашлары һәм тормыш-яшәешне күзаллаулары фәлсәфәсе теркәлеп калдырылган. Ә менә ул теркәлү чоры, анда төп каһарман итеп Искәндәрне алу – монысының төгәл елы ачыклана ала. Ул ислам дине таралуы белән бәйле булып, борынгыларның фикерләвен, борынгы дәверләрдә дөньяның асылын аңлау һәм аңлату фәлсәфәсен саклап калу кирәклеген төшенү чорында гына языла алган. Әгәр дә без риваятьләрне һәм гомумән дә әдәби әсәрләрне берәүнең күңеленә-башына килгән дә, ул шуларны язып куйган дигән караш белән чикләнсәк, моның белән нык ялгышырбыз. Әдәби әсәрләр юктан гына язылмыйлар. Аларның тарихи-мәдәни кыйммәте дә бер – бер сәбәп белән мәйданга чыгуларына бәйле. Һиндстанга ислам дине VIII–IX гасырларда барып ирешә, әмма таралышы берьюлы гына да һәм җиңел генә дә түгел. Искәндәр турындагы бу риваять X гасырда теркәлгән булырга тиеш. Башкача мөмкин түгел. Бу чорда аларда иске фәлсәфәнең яңасы белән алышынуы дәвере бара. Шәрыкта искедән яңага күчеш нәкъ менә X гасырга карый. Ә яңача фикерләү үсеп киткәч, иске карашлар санга алынмый башлыйлар. Төркиләр арасында XII йөздән тәмам көч алган суфичылык исә һәртөрле «искене» яңартып, аның эчендә яңа фәлсәфә буларак үстерү юлын таба. Искәндәр падишаһ хакындагы ул риваять тә хикмәтле эчтәлек төсен алып, идеясенә, фәлсәфәсенә бәя бирелмичә, мөкатдәс мөслими вакыйга төсендә яши һәм тарала, яңа чор кешесе акылына хезмәт итә башлый.

«Мәликә китабы»на күчсәк, аның төрки дөньяда киң таралыш алган ислами фәлсәфәгә корылганлыгын аңларга мәҗбүрбез. Әмма ул ислами гына да, чын мәгънәдә мөселманлык фәлсәфәсе генә дә түгел. Ис-

лам дине фәлсәфәсе үлгән кешеләрнең җаннары күккә ашуын, тәннәре, җирдә калып, туфракка әверелүен төшендерә. Суфиларча күзаллауда һәр тузан бөртегеге дә элек үлгәннәрнең күзе буларак кабул ителә. Габделхәлимнең җаваплары исә шушы кысаларга тәмам сыеп бетә дип әйтү мөмкин түгел. Ул безнең төрки халыкларның электән яшәп килгән фәлсәфәсенең чагылышы, аның китапка теркәлеп калган өлеше генә. Әмма шушы эчтәлеге белән ни суфи, ни рәсми ислам фәлсәфәләренә каршы да килми. Менә шушы үзенчәлеге аркасында ул теркәлгән хәлендә яшәп калган һәм тормыш асылларын үз кысаларында күзаллату функциясен югалтмаган. Аны бүгенге көндә халкыбызның дөньяга карашы һәм аны күзаллавы системасыннан алып ташларга мөмкин дә түгел.

Һәм менә тагын да кыз шунда егеткә сорау бирә: «Мөэминме сән, мөселманмы сән?», – ди. Аның бу соравын алдагы җаваплар белән бәйләсәк, юкка гына бирелмәгән булуын төшенербез. Габделхәлим ул сорауга каршы: «Иман килтермәк берлан – мөэминмен, Пәйгамбәр шәригатенә кермәк берлән – мөселман», – дип белдерә. Аның бу җавабы теманың үзгәрүен тәэмин итә. Укучы монда «мөэмин» дип кемнәрнең аталуын, «мөселман» дип кайсыларының йөртелүен аңлап ала. Дин тәмам ныгып, бәндәләрнең шәригатьчә яшәү рәвешләре тәэмин ителгән дәверләрдә мөэминнең-мөселманның кем булуларын аера алмый башлыйлар, икесе дә бер үк мәгънәдә икәнлеген белеп торалар. Ә ислам дине таралган, әле үсешкә ирешмәгән, ныгып барган чорлары өчен бу «мөэмин» яки «мөселман» төшенчәләренең үз функцияләре бар һәм алар бер-берсеннән мәгънәви яктан нәкъ «Мәликә китабы»нда Габделхәлим аңлатканча аерылып та торалар. Безнең татарда ислам динен киң җәелдереп үстерүдә суфичылыкның роле гаять тә зур, куәтле булган. XII йөздән төрки суфичылыкның башында Ә.Яссәви торган һәм алга таба аның өйрәтмәләре өстенлек иткән. Дөрес, аңа кадәр бездә тарикать гыйлеме таралыш алмаган дип белдерә алмыйбыз. Ә.Яссәвинең әтисе Ибраһим Яссы да суфичылык иткән. Әмма тарикать, ягъни Аллаһы тәгаләне тану һәм таныту методы-юлы сыйфатындагы төрки эчтәлектәге суфичылык өйрәтмәләрен булдыру, тарикать төзү аның улына насыйп ителгән. Болардан чыгып, Ә.Яссәвигә кадәрге дәвердә төркиләрдә ислами тәрбия нәкъ менә «Мәликә китабы» һәм шуның тибындагы әсәрләр белән алып барылган, – дияргә мәҗбүрбез. Аларның тарихи-мәдәни әһәмиятләрен аңлау, эчтәлекләрен төшенү лазем, билгеле. Шулар белән без үзебезне һәм тарихларыбызны яхшырак аңлый башлыйбыз.

XII

Хакыйкатьләрне күрү, тану, төшенү – бер хәл, аларны аңлатырга алыну – икенче, әмма башкаларны үзең күргән һәм тапкан дәрәҗәдә белемле

итү – бусы, өченчесе, иң катлаулысы. «Мәликә китабы»ның авторы моны яхшы аңлаган һәм шунлыктан, һичбер бәхәс һәм аңлатуларны куертмыйча, белгәнен сөйләп баруның уңышлы җаен тапкан. Кыз сораулар бирә тора, ә егет – аларга җавап таба. Билгеле инде, хаталанмасын, югыйсә Мәликә аны дар агачына астырачак. Моны укучы һәр бирелгән сорау саен хәтерендә яңартып тора, хәер, аның онытырга мөмкинлеге дә юк. Сораулар – кыска, төгәл, җавапларның да шундыйлары таләп ителә. Әсәр шушы ягы белән укучының күңелен һәрдаим борчый. Җитмәсә сораулар берсе икенчесеннән хәтәррәк. Аларның кайсыларына укучы үзе дә җавапны белергә тиеш. Югыйсә, ул каян Габделхәлимнең ялгышмавын бәяли алсын? Җавапларның хатасыз, төгәл, тулы икәнлегенә укучы бер бөртек тә шикләнмәскә тиеш. Ә моның өчен халыкның үз фәлсәфәсе, үз күзаллаулары, аңы, белеме, гореф-гадәтләре истә тотылу таләп ителә. Башкача икән, ул вакытта әсәр материалы, хилафлыга, хыялыйга әверелеп китеп, рациональ эчтәлектән читләшер иде. «Мәликә китабы» авторының таланты дәрәҗәсе югарылыгын бу әдәби үзенчәлекләр раслап торалар.

Һәм менә кыз яңа, 21-нче төркем сорауларга күчә һәм: «Дөньяда нәчә нәрсә бәдәл булды?», – дип сорый. Егет: «Егерме өч нәмәрсә үз фигылендин бәдәл булды», – дип җавап бирә. Мәликә аның боларны аңлатып чыгуын таләп итә.

Ә нәрсә соң ул «бәдәл» һәм, гомумән дә, фигылеңнән бәдәл булу?

Бүгенге көндә халкыбызда: «Кеше эшенә тыкшынма, борының озынаер», – яки: «Кеше серен тыңлап йөрмә, колагың зураер», – яисә: «Харамны күзләмә, күзең сукыраер», – дигән әйтем-мәкальләр азмы? Менә болар, ягъни теге яки бу гамәл аркасында «бәлале» булулар – «бәдал» дип атала да инде. Ул сүзне «алдану» мәгънәсендә дә аңларга кирәк. Әмма, барысыннан да бигрәк, «алданып әверелү» сүзенә аның мәгънәсе турырак килә. Татар халкының «Өч кыз» экиятендә әниләренең авыруы хакында хәбәр китергән тиеннән үтенечен ишетеп тә, эшләрен ана кадереннән өстен куйган кызларның берсе – үрмәкүчкә, киенчесе – бакага әверелә, ягъни гамәлләренә, эшләренә бәйле рәвештә, шул шөгыльләреннән алданып, алар бәлагә юлыгалар. Бу әверелүне яки алдануны әлбәттә борынгы мифологик күзаллауларга да, дини күзлектән карап әйткәндә – бәддогага да китереп бәйләргә ярый. Шулай да ерак тарихлардан килгән мифологик күзаллаулар бәдәлнең нигезендә ятмый мөмкин түгел.

Кызның бу соравына егетнең җавабын, күренеп торсын һәм аңлашылсын өчен әлбәттә, әсәр текстыннан аермалы буларак, берәм-берәм, саннар артында бирергә булдык. Ул боларны әйтә:

«Таушкан [озынколак, ягъни куян] – бер кеше ирде, халык арасында шайтанлык кылыр ирде»;

«Көя – бер кеше ирде. Пәйгамбәрдән гизләнде [ягъни иман китерүдән качып йөрде], йонның арасында зәгыйфәсе шул булды»;

«Аю – бер кеше ирде, бәни-исраил каумендә [ягъни яһүдиләрнең борынгы кабиләләреннән берсе. Йосыф пәйгамбәрнең этисе Ягъкуп пәйгамбәрне «Исраил» дип атап йөрткәннәр, ә балаларын-нәселен – «бәни-исраил» дип] харамлык кылыр ирде»;

«Мәймүн [маймыл] – бере кеше ирде, Гайсә галәйһис-сәламгә инанмады»;

«Дунгыз – бер кеше ирде, хараме-хур [харам ашаучы] ирде»;

«Төлке – бер кеше ирде, угрылык кылыр ирде»;

«Үрмәкүч – бер кеше ирде, мәккәрә [мәкерле], канәгатьсез хатын ирде»;

«Сыртлан [шакал] – бер кеше ирде, кәфен суйгучы [кабердәге мәетләрнең кәфенен салдырып урлаучы] ирде»;

«Әма [үрдәк] – бер кеше ирде, гайар иде, Һарут-Марут белән күккә чыкты»;

«Качыр [кечкенә ат, пони] – бер кеше ирде, артык алып, аз-ким бирер ирде»;

«Ташбака – бер кеше ирде, артык үлчәп алыр ирде, ким үлчәп бирер ирде»;

«Тутый [попугай] – бер кеше ирде, вөҗүден [үзен, барлыгын, дөньясын] халыкка күрсәтер ирде»;

«Сычкан [тычкан] – бер кеше ирде, күп сүзләр ирде»;

«Ерканат [ярканат] – бер кеше ирде, карендәшләрен гайбене әйтер ирде»;

«Фил – бер кеше ирде, надан бай ирде.

Бу кем ирсәләр үз фигылендин бәдәл булды [гамәлләре аркасында әверелмәклек]».

Шулай итеп, егет кызга егерме өч нәрсәнең үз фигыльләре сәбәпле алданулары хакында әйтсә дә, китапта аларның унбишен генә табабыз. Ә калган сигезе кая дигән сорау туа. Бу шактый түгелме?

Игътибар белән укыганда, тәртип буенча тугызынчы булып аталган «Әма» белән бәйле урында фикер һәм җөмлә барышы үзгәрешенә тап булабыз. Монда мәгънәләр дә бутала. Шушыны исәпкә алсак, текстта өзеклек килеп чыкканлыгын һәм аны тутырырга тиешле сигез хайван хакында хәбәрләр язылган булырга тиешле икәнлеген фараз кыла алабыз. Төп текстта, ягъни протографта, ул урында нәрсәләр искәртелгән иде икән – алар әһәмиятле, әлбәттә.

Тагын да шунысын онытмыйк: фигыль бәдәле аркасында теге яки бу хайванга, кошка, кортка-бөҗәккә әверелүне Коръәндәге хәбәрләргә, мөселманлыкка бәйләргә ярамый. Дөрес, «Бәкара сурәсе»нең («Сыер

сурәсе»нең) 65-нче аятендә: «و لقد علمتم الذين اعتد وا منكم قى السبت فقلنا لهم كونوا قردة خسئين».

Ягъни: «Вә ләкад галимтүмүл-ләзийнә әгътәдәү минкүм фис-сәбти фәкульнә ләһүм күнү кырадәтән хаси-ийнә», татарчасы: «Һәм чыннан да, арагыздагы шундыйларны беләсез, сәбтне [шимбә көнне эштән тыелуны] боздылар, без аларны әйттек: Чиркангыч маймыл булыгыз», – диелгән. Әмма моны «маймыл кебек булыгыз» дип аңларга тиешле. Аннары, Һарут һәм Марут исемле фәрештәләр мәсьәләсенә килгәндә, Коръәннең шул ук «Бәкарә сурәсе»нең 102-нче аятендә, аларның фетнә һәм көферлек кылмаулары хакында хәбәр килә. Әмма иске заманнарыбызда галимнәребез ул хәбәрләрне үзләренчә, үз чорларына хас карашларча аңлаткан. Ул риваятьләр мәдәниятебезнең һичшиксез игътибарга лаеклы тарихи катламы булып торалар.

Маймылга бәйләнешле мәсьәләне Коръән хәбәрләре аша бәйләгәндә генә дә «Мәликә китабы»ндагы фигыльдән бәдәл хәбәрләренең, беренчедән, халыкның борынгы ышануларына, тормышны тәртиптә тоту чараларына барып тоташалар, икенчедән, бу чаралар ислам дине килү белән юкка чыгарылмаган, бәлки дини хәбәрләр дә аларга кушылып киткән. Шайтанны искә алу, бәни-исраил халкын, Һарут-Марутны, Гайсә пәйгамбәрне ул күзаллаулар эчендә күрсәтелү хәбәрләргә хакыйкать көчен дә биргән, аларны ислами күзаллаулар белән ярәштергән. Әмма «Мәликә китабы»ндагы бу ярамас фигыльдән бәдәл ирешү мәсьәләсе һәм фикерләре ислам диненә кадәрге карашларга таянып төзелгән. Ләкин боларга карап кына ул хәбәрләрне көферлек дип атау – урынсыз. Чөнки алар булмасын, Һарут-Марут турындагы риваятьләр булмасын – иске заманнардан бирле халык йөрәгендә иманны, дини тойгыларны ныгыту һәм яшәтү өчен хезмәт иткәннәр. Әхлакый һәм әдәби әһәмиятләренә килгәндә – болары бәяләп бетерерлек түгел. Аннары шунысы да бар: «Мәликә китабы» авторын иске карашларны ислам дөньясына хәйләле һәм яшерен рәвештә кертеп калдыру өчен тырышкан икән дигән фикер һич тә чыгарылырга тиеш түгел. Ул үз чорының кешесе булган. Дини күзаллаулары нинди – әдип шуларны бәян иткән һәм үзен хаклы, белемле кеше сыйфатында күрсәткән. Әгәр дә фәнебез бүген дә акны карадан аера алырлык түгел икән – бу безнең гаеп. Тагын шунысын онытмыйк: дини күзаллауларны риваяти, хикмәти, хикәяти хәбәрләрдән аерсак, безнең белемнәр тараеп калыр иде. Алга таба мәдәни-иҗтимагый үсеш барышында фәнни хәбәрләр ул иске карашларны алыштыра барган, хакыйкатьне ачык итеп күз алдына китерү дәрәҗәсенә кадәр халыкны үстерә алган. Боларны исәпкә алмыйча һич тә мөмкин түгел.

Шулай да «бәдәл» дип әйткәндә, XIX гасырда татар халкы берәр кеше исеменнән хаҗга баруны атаган. Ул мөселманны бездә «бәдәлче» исеме белән йөртәләр. Шуннан чыгып хәтта «бәдәлчелек итү», «бәдәл сату» кебек терминнар барлыкка килгән. Хәзерге төрек телендә «бәдәл»не «түләү» мәгънәсендә кулланалар. Димәк, «бәдәл булды» дигәндә «(гамәле өчен) түләү булды» дип аңларга кирәк. Әмма теге яки бу хайванга, агачка яки үсемлеккә әверелү мәсьәләсендә ислам динендә аны «тәнасух» яисә «тәкаммус», «нәкль», «тәнәккуль», «интикаль» терминнары белән атыйлар һәм бу әверелү-инкарнацияләнүгә ышанган мөселманнарны «тәнасухийә», «әсхабе-тәнасух» дип атап йөртәләр. «Мәликә китабы»ндагы «бәдәл булу» термины кулланылмау бу очракта сәбәбен ачыклауга этәрә. Автор гүяки махсус рәвештә «тәнасух» сүзен кулланмый.

Һәм моның хикмәте чыннан да бар. Беренчедән, сөнни мәзһәбе галимнәре тәнасухны тулысынча инкарь итәләр һәм аңа ышануны бозыклык саныйлар. Без, татарлар, үзебезне Сөнни мәзһәбе мөселманнары буларак беләбез. Әгәр дә Шигыйда икәннәр, алар бу «тәнасух» сүзен таныр һәм шул термин белән эш итәр иделәр. Димәк, «Мәликә китабы» Сөнни мәзһәбе даирәсенә бәйле. Ә бу – әһәмиятле күзәтү. Ә икенчедән, Сөнниләр арасында тәнасухка ышану дәвере «фатыймыйлар чоры»нда булган. Монысы – тагын да кызыклы факт. Фатыймыйлар хәлифлеге 909-нчы елда оешып, 1171-нче елга кадәр яши. Бигрәк тә исмәгыйлийә хәлифе Әбу-Гали Әл-Мансур – аны Әл-Хәким буларак та атап йөрткәннәр – хөкемдарлык иткән заманнарда, 996–1021-нче алларда, тәнасух идеясе киң җәелү ала. Аның гаскәрләре төрки телдә сөйләшүче Идел буйлары һәм Кавказдан килгән мәмлүк-кыпчак көчләреннән торган. Кыпчакларның реинкарнацияга бәйле карашлары фатыймиларга да тәэсир иткән булса кирәк. Башкача була алмый. Чөнки өч йөз елдан артык ислам дине андый мәҗүси карашларны юкка чыгарып килә-килә дә, тиз арада алар X гасырдан Урта һәм Кече Азиядә кабат калкып чыгалар, хәтта дини күзаллаулар һәм карашлар юнәлешен алалар. Моны төркиләрнең активлашуы буларак та аңларга кирәк. Урнашакан тәнасух теориясе җанның нинди булуына бәйле аның тышкы кабыгы, ягъни тән-сынның үзгәреше, шундый ук кыяфәткә керүе белән бәйле күзаллауларга корылган. Ул реинкарнация бу дөньяда бара, теге дөньяга калдырылмый һәм дүрт төрле этапка кадәр булырга мөмкин санала. Кеше үз гамәлләренә бәйле рәвештә кыяфәтен дә үзгәртә, бу хәл гүяки кием алыштыру кебек бара. Җанның нindilеге алга таба кайсы кыфәткә керүеңне тәэмин итә. Әгәр дә надан бай икән, «Мәликә китабы»ндагыча, ул филгә әверелә. Мәсәлән, бала еш авырый икән, димәк аңа начар кешенең җаны күчкән, шунлыктан тәне газапланырга мәҗбүр [Электрон ресурс: 2017]. 1017-нче елгы рескрипты

белән хәлиф Әл-Кадыйр мөгътәзилиләрне бидгатьчеләр буларак игълан итә, 1041-нче елда шул ук хәлиф «Шарйатуль-иман»ны мәйданга куя һәм шуның белән кәлам фәлсәфәсенә бәйле һәртөрле бәхәсләрне туктата. Бу китап нигезендә төрки телдә «Иман шарты» төзелә. Безнең татарлар мәдрәсәдә укыган китап ул, димәк, ул 1041-нче елда язылган һәм аның авторы да хәлиф Әл-Кадыйр булып чыга. Бу фактлар «Мәликә китабы»-ның иҗат ителү вакытының XI гасырга караганлыгын тагын бер кат раслыйлар. Иман китерү һәм реинкарнация-нәнасух мәсьәләләре әсәрнең 1018-нче елда вафат булган философ Ад-Даразиның (Мөхәммәт ибне Исмәгыйль Ад-Даразе) идеаллары тәэсирендә язылган булуы хакында да сөйли. Бу галим тумышы белән Төркестанның Тәраз шәһәреннән (хәзерге Казахстанның Җанбул өлкәсендә), төрки нәселдән, тегүче-тукучылар гаиләсеннән булган. Фатимыйлар сараена хезмәткә алынып, тиздән хәлиф Әл-Хәкимнең (996–1021) иң якын күргән кешесенә әверелә. Мөхәммәт Тәрази илнең эчке һәм тышкы сәясәтенә үзгәрешләр кертүгә зур көч куйган сәясәтче дә булып өлгерә. Аның фикерләре мәмлүк гаскәриләре арасында яклау таба. Әмма үзен «Сәйфел-иман» («Иман кылычы») дип атап, «хәлифкә Аллаһының рухы күчкән» дигән сүзләр сөйләве аркасында бәддогага ирешә. Аның Төркестанның Тәраз шәһәреннән булуы кыпчак телле мәмлүк гаскәриләренең идеаллары һәм дөньяга карашлары формалашуда роль уйнамый калмаган, билгеле. Мисыр мәмләкәтендә Мөхәммәт Тәрази өйрәтмәләре нигезендә Друзийә мәзһәбе барлыкка килә һәм бүген дә яшәвен дәвам итә. Аларны Сөнниләр Шигыйлар буларак беләләр. Алар үзләрен «мөвәххитләр» дип йөртәләр, ягъни «бер Аллачылар» дип. «Мәликә китабы»ның Сөнниләр мәзһәбенә бәйле язылган булуы, әмма кайбер урыннарында Мөхәммәт Тәразиның реинкарнация һәм иман өйрәтмәләре чагылыш алуы — болар аның иҗат ителү датасын һаман да шул XI гасырга кайтарып калдыруга этәрә. Ә бәлки ул соңгырак чорга карыйдыр? Бусы — һич мөмкин эш түгел. Чөнки эчтәлеге әсәрне башка дәверләргә калдырырга юл бирми. Ә 1846-нчы елда аерым китап буларак басылып чыгуында һәм аннары да күп тапкырлар нәшер ителүендә татар халкының дини ышанулары, иман-игътикадлары белән андагы фикерләрнең каршылыкка килмәвеннән дип уйларга кирәк.

(Дәвамы бар)

Әдәбият

Ведические притчи. М.: Амрита-Русь, 2008. С. 168.

Электрон ресурс. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki (мөрәҗәгать итү датасы: 05.12.2017).

Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

ВАКЫЙГАЛАР ХРОНИКАСЫ / ХРОНИКА СОБЫТИЙ

23 сентябрь көнне Новосибирски өлкәсендә, тарихта беренче тапкыр, себер татарларының Хәтер көне үткәрелде. Әлеге чара Себер ханлыгының юкка чыгу тарихы белән бәйле, милләт өчен фаҗигале бу вакыйга моннан нәкъ 420 ел элек, хәзерге Новосибирск өлкәсе территориясендә була. Себер өчен соңгы сугыш тарихка «Ирмән сугышы» дип кереп кала, ул регуляр урыс армиясе һәм Күчем хан гаскәрләре арасында бара. Шушы канлы бәрелештән соң Себер ханлыгы яңадан тернәкләнеп китә алмый һәм соңгы сугыш булган көн – 1598 елның 20 августы, рәсми рәвештә Себерне Россиягә кушу көне, дип билгеләп үтелә.

Чараның беренче өлеше «Түгәрәк өстәл» җыелышыннан торды, икенче өлешендә – Коръән укып, Хәтем ашы уздырылды, соңыннан Себер ханлыгының соңгы үзәге булган урынга барып, дога кылынды. Тарих буенча мондый очрашуларны алга таба да дәвам итәргә, бу бигрәк тә яшьләр өчен әһәмиятле, дигән фикергә киленде.

Себердә уздырылган Хәтер көнендә язучы, тарих фәннәре кандидаты, танылган җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова дә катнашты.

* * *

В татарской гимназии №15 г.Казани состоялось рабочее заседание по поводу предстоящего открытия историко-этнографического музея. На заседании приняли участие главный редактор журнала «Туган җир/Родной край», доктор исторических наук Д.М.Исхаков и его заместитель, председатель РОО «Общество татарских краеведов РТ» А.А.Бурханов, первый заместитель руководителя Исполкома ВКТ Д.Ф.Шакиров и директор данного учреждения Ф.Ф.Харисов.

* * *

17 октября 2018г. главный редактор журнала «Туган җир/Родной край» Д.М.Исхаков посетил «Просветительский центр имени Ахмад Хади Максуди» (г.Казань) для участия в мероприятиях, посвященных 150-летию этого видного татарского просветителя. После выступления

он подарил данному центру журнал «Туган җир/Родной край» и сделал предложение о дальнейших контактах.

* * *

23 октября 2018 г. в Москве по инициативе РОО «Татарский культурный центр – Татарский штаб», состоялась встреча общественности. Она проходила при участии руководства краеведческого журнала «Туган җир/Родной край» (участвовали: гл.ред. данного издания докт.ист. наук Д.М. Исхаков, его зам., канд.ист. наук А.А. Бурханов, известный журналист из газ. «Ватаным Татарстан» Р.Р. Мингазов). На встрече, где присутствовали свыше 100 представителей татарской общественности (ученые, дипломаты, бизнесмены, музыканты, студенты и т. д.), было презентовано новое издание – журнал «Туган җир/Родной край», а затем состоялся обмен мнениями по созданию «Стратегии развития татарского народа». Руководителю «Штаба татар» – известному московскому бизнесмену Р.Ф. Ямалееву, от имени Исполкома ВКТ была вручена грамота за организаторские усилия по сохранению и развитию татарской идентичности в условиях столичного мегаполиса.

* * *

27 октября 2018 г. представители Всемирного конгресса татар, Общества татарских краеведов РТ и Ульяновской областной татарской национально-культурной автономии посетили могилу известного татарского поэта-лирика XIX в. Габделжаббара Кандалыя (1798–1960) на кладбище села Ертуганово. Затем гости возложили цветы к памятнику известного богослова, философа, общественно-политического деятеля, журналиста, участника Всероссийских съездов мусульман, уроженца с. Абдуллово Закира Кадыйри (Закира Халимовича Габделкадырова, 1878–1854).

* * *

27 октября 2018 г. в татарском с. Абдуллово Черданклинского района Ульяновской области состоялся большой праздник – День села. На это массовое мероприятие прибыли многие уроженцы села всех поколений и гости из Казани и Ульяновска. В рамках мероприятия была проведена презентация краеведческого издания книги «Абдуллово – наша малая Родина» (г. Ульяновск, 2018, С. 256, 16 п.л., 500 экз.).

В гостях у жителей Абдуллово побывала делегация Исполкома ВКТ и «Общество татарских краеведов РТ» – председатель этого общеста, заместитель главного редактора журнала «Туган җир/Родной край» академик АВИН РФ А.А. Бурханов, доктор исторических наук, профессор КФУ Р.В. Шайдуллин, краевед, журналист, зав. Народным музеем-библиоте-

кой им. Хади Атласи (пгт. Карабаш Бугульминского района РТ) Ф. А. Валиахметов, краевед, заслуженный учитель РТ, учитель истории Юлбатской школы Сабинского района РТ И. Ф. Сафин.

* * *

30 октября 2018 г. в татарском селе Енапаево (Янапай, Енапай) Октябрьского района Пермского края состоялась Региональная научно-практическая, краеведческая конференция «История сылвенско-иренских татар».

В работе конференции приняли участие представители сельских поселений и районов компактного проживания татар Пермского края, городов Перми, Лысьва, Кунгур и Казани, в том числе председатель РОО «Общество татарских краеведов РТ», заместитель главного редактора журнала «Туган җир/Родной край», кандидат исторических наук, профессор А. А. Бурханов, профессор Российского исламского университета, д. и. н. Ф. Г. Ислаев и корреспондент республиканской газеты «Ватаным Татарстан» Р. Р. Мингазов.

В рамках конференции все участники побывали в местной сельской школе и посетили краеведческий музей.

* * *

1 ноября 2018 г. в г. Казани, на базе Городского Дворца детского творчества им. А. Алиша состоялся Республиканский образовательный форум «Растим гражданина, воспитываем патриота: вызовы третьего тысячелетия».

В рамках Форума были проведены 5 тематических круглых столов (секций). В работе форума принял участие руководитель РОО «Общество татарских краеведов РТ», заместитель гл.ред. журнала «Туган җир/Родной край», кандидат исторических наук, профессор А. А. Бурханов.

На круглом столе «Формы, методы и актуальные проблемы гражданского и патриотического воспитания школьников» (модератор – руководитель Общегородского клуба «Юный краевед», заслуженный деятель науки А. А. Бурханов) были рассмотрены и обсуждены следующие вопросы: роль краеведения в изучении истории населенных пунктов и воспитании молодого поколения любви к родному краю; роль школьных и районных краеведческих музеев в изучении родного края и воспитании молодежи; изучение истории родного края на уроках истории; работа по составлению шеджере (родословных) как форма учебной и воспитательной работы в школе и внешкольное время; изучение жизни и деятельности выдающихся земляков как форма воспитания молодого поколения; роль внешкольных учреждений в привлечении молодежи в историко-краеведческую деятельность.

* * *

2018 елның 1 ноябрендә Яшел Үзән шәһәренең муниципаль район мәдәният йортына караган Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы инициативасы белән Клара Мәрдән кызы Филлипованың «Рухи туфрак» дип исемләнгән китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Анда БТК Милли Шурасы һәм «Туган җир/Родной край» журналы исеменнән тарих фәннәре докторы Д.М. Исхаков катнашты һәм ул хезмәтнең авторы турында җылы сүзләр әйтте.

* * *

2018 елның 3 ноябрь көнне Уфа шәһәрендә Киров районы «Ихлас» мөселман дини оешмасы оештырган «Бөек ислам галиме Морад Рәмзи: тормышы һәм гыйльми мирасы» дип аталган халыкара фәнни-практик конференциясе булды. Аның эшендә чыгышлар белән «Туган җир/Родной край» журналының баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков һәм политолог, журналист Руслан Айсин катнаштылар. Конференциядән тыш алар Уфа шәһәрендә яшәүче бер төркем татар галимнәре белән очрашып, аларның «Татар халкының үсеш стратегиясе»н булдыруда катнашулары турында фикер алыштылар.

* * *

2018 елның 16 ноябренда Казан шәһәрендә «Татар дөньясында этнотуризм һәм туган якны өйрәнү: хәзерге торышы һәм перспективалары» исемле Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды. Конференция БТК һәм Татарстан Республикасы Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте тарафыннан «Туган җир. Родной край» журналы катнашында оештырылды.

Әлеге чара кысаларында Казан шәһәре Киров районында урнашкан 15-нче татар гимназиясендә «Укучыларның милли үзаңын формалаштыру һәм үстерүдә туган якны өйрәнү музейларының роле» дип аталган семинар үткәрелде һәм Бишбалта бистәсенә (Адмиралтействога) багышланган тарихи-этнографик музей ачылды.

СӘЕТ ВАХИДИНЫҢ ТУГАН ЯКЛАРЫНДА

2018 елның 22 августында Әлки районы тарихында беренче тапкыр төбәк тарихын өйрәнүче галим-археограф, мәгърифәтче, репрессия корбаны Сәет Вахидины зурлап искә алу чаралары булып үтте.

Билгеле булганча, Сәет Вахиди шушы районның Ташбилге авылында 1887 елда дөньяга килә, башта үз авылларында, аннан Иске Рәҗәп һәм Казанның атаклы Мөхәммәдия мәдрәсәләрендә төпле белем ала. 1911 елдан башлап Сәет Вахиди үзе дә Казан губернасы татар авылларында укытучы булып эшли, аннан Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша, революциядән соң тагы мөгаллимлек эшен дәвам итә, Казанда Үзәк музейда көнчыгыш бүлеген оештыра, фән белән тирәнтен шөгыльләнә, археографик эзләнүләр алып бара, вакытлы матбугатта татар тарихы буенча күп кенә язмалары белән чыгыш ясый. Ул гарәп һәм фарсы телләрен, госманлы төрекчәсен камил белә, хезмәтләрен нигездә татар һәм рус телләрендә дә яза. Сәет Вахидиның милләтебез алдында иң зур хезмәте һәм татар тарихы өчен иң зур табышы –1912 елда хәзерге Саба районының Мамалай авылында тапкан һәм фәнни әйләнешкә керткән Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы – галим аның күчермәсен алуга ирешә, ә инде 1920 елда кыйммәтле тарихи ядкәрнең үзен дә Казанга алып кайта. Моннан тыш Сәет Вахиди даими рәвештә төбәкләрдә булып, халыктан өч меңгә якын борынгы кульъязмалар һәм китаплар җыя, аларны, шулай ук данлыклы Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгын да, бушка Казан музейларына һәм институтларга бүләк итә. Замандашлары, бигрәк тә татар һәм рус тарихчылары, Сәет Вахиди хезмәтләрен югары бәяләсәләр дә, бу фидакарь галим шәхес культының канлы тегермәненә эләгә һәм корбан була – аны, төркичелектә һәм бәйсез татар дәүләте төзергә җыенуда гаепләп, 1938 елның 5 гыйнварында атып үтерәләр. 1958 елның 9 гыйнварында гына Сәет Вахиди тулысынча аклана, гаепсез дип табыла.

Узган елның маенда Сәет Вахидиның тууына 130 ел булды, Казанда ул соңгарак калып булса да билгеләп үтелде – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты октябрь аенда Сәет Вахидига багышланган фәнни-гамәли конференция уздырды, «Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар» сериясеннән аның җыентыгын чыгарды, ахырда конференция материаллары да аерым китап булып басылып чыкты. Сәет Вахидиның иҗатын һәм тормышын яктыртуда «Мәдәни җомга» газетасы да зур өлеш кертте – әле сентябрь аенда ук язучы, тарихчы Фәүзия Бәйрәмованың «Атылган галим» дип аталган язмасы, ә ноябрь аенда журналист Хәмзә Бәдретдиновның «Үзен гаепле дип танымаган» дип аталган күләмле һәм җентекле хезмәте басылып чыккан иде. Ә менә туган якла-

рында Сәет Вахидиның юбилее билгеләнмичә үтеп киткәнлектән, шушы бушлыкны тутыру ниятеннән, Фәүзия Бәйрәмова Әлки районына килде һәм халык белән очрашулар уздырды. Бу очрашуларда шулай ук Сәет Вахидиның ерак туганы, үзе дә Әлки районының Абдул Сәлман авылында туып-үскән, хәзер Түбән Кама шәһәрендә яшәүче, туган төбәге турында күп хезмәтләр язган, Әлки районының «Мактаулы гражданы» Мансур Ганиев та катнашты.

Тарихчылар белән беренче очрашу район үзәге Базарлы Матак бистәсенең С.М.Лисенков исемендәге туган як тарихын өйрәнү музеенда булды. Очрашуда Әлки районы хакимият башлыгы урынбасары Рәшит Билалов, музей директоры Мария Платонова, шулай ук Базарлы Матак, Алпар, Түбән Әлки, Карга, Яңа Чаллы, Иске Чаллы, Бибай Чаллысы, Үргәагар, Юхмачы, Әхмәт, Иске Матак, Иске Тахталы, Түбән Кәчи, Хузангай авылларыннан татар теле һәм тарих укытучылары катнашты. Фәүзия Бәйрәмова аларга Сәет Вахиди, аның хезмәтләре, тормышы һәм язмышы турында сөйләде, галимнең Мирасханә тарафыннан чыгарылган юбилей җыентыгын бүләк итте. Ул шулай ук музейга Сәет Вахиди белән бәйле конференция материалларын, газета язмаларын да тапшырды, үзенең «Татарская Мать Чингиза Айтматова» дип аталган китабын бүләк итте.

